# ШУРА

№ 48

2025



ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

# ЭЧТӘЛЕК

Җомга хотбәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе . . . . . . . . . . . . . 9

ВӘГАЗЬЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Чапан-чалмадан йөрү – сөннәт . . . . . . . . . . . 14
Намаз укуда өч сорауга җавап . . . . . . . . . . . 18
Телебез – Аллаһының бер аяте . . . . . . . . . . . 24
Дәгъват гаиләдән башлана . . . . . . . . . . . . . 30
Бөек Җиңүгә 80 ел . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Кем ул Аллаһының әүлиясе? . . . . . . . . . . . . 40
Зөлхиҗҗә аеның фазыйләтләре . . . . . . . . . . . 47
Корбан гаетенә әзерлек. Гарәфә көне . . . . . . . . 52
Корбан гаете хотбәсенең гарәпчә укылышы . . . . . . 57
Корбан гаете хотбәсенең кириллицага транслитерациясе . . 61
Корбан гаете хотбәсенең татарчага тәрҗемәсе . . . . 64
Корбан гаете вәгазе . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Кая югалдык шул арада? . . . . . . . . . . . . . . 77
Рух ачлыгы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82
Мөхәррам ае фазыйләтләре . . . . . . . . . . . . . 86
Коръән ятлау фазыйләтләре . . . . . . . . . . . . 90
Гашурә көне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 95

СОРАУ – ҖАВАП . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101

НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН? . . . . . . . . . . . . . . 107
Декабрь-февраль . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108

**«ШУРА» дини альманах, № 48** **12+**

апрель–июнь 2025
шәввәл–мөхәррам 1446/1447

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте
420021, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бушлай таратыла.
2013 елның июленнән чыга.
Басма кварталга бер тапкыр чыга.

**БАШ РЕДАКТОР:**
Хамматов Л. Г.

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Хәмидуллин Р. Ә.
Мөбарәков Б. Р.
Фәизов И. Ә.

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**МӨХӘРРИР:**
Маннанова Р. Р.

**ДИЗАЙНЕР:**
Хәйретдинов И. Р.

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Гарифуллин И. Ф.

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Титул битендә фотода «МәшәАллаһ ләә кувватә иллә билләһ» («әл-Кәһф» сүрәсе, 18:39) дип язылган. Рәсемнең авторы: BaoCalligraphy / shutterstock.com/image-vector/mashallah-la-quwwata-illa-billah-surah-2183555741
Тышлыкта Илнур Мифтаховның фотолары кулланылды.

Альманах Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан республикасы буенча идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ № ТУ16-01077 номеры белән теркәлде.

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел.: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: izdat@huzur.ru
Сайт: huzur.ru

*Типографиянең адресы:*
*«Карти» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420095, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Химград территориясы, 201 нче йорт, 1006 нчы бина.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 10.03.2025
Чыгу көне: 07.04.2025

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый.*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аятьсүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала.*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание
на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ الَّذِي هَدَانَا لِهٰذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللّٰهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللّٰهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللّٰهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللّٰهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللّٰهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِينَا إِلَى اللّٰهِ۞ صَلَّى اللّٰهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللّٰهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللّٰهِ! ۞ اِتَّقُوا اللّٰهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللّٰهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللّٰهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ:

________________________________ ۞

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّى اللّٰهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

________________________________ ۞

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسلَامُ۞

Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمدُ لِلّٰه حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞ اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ ۞ سَيِّدِنَا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللّٰهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللّٰهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللّٰهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ ۞ وَلَذِكْرُ اللّٰهِ أَكْبَرُ وَاللّٰهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әмин» дип әйтә.

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләҙии һәдәәнә лиһәәҙәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә ән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләҙии каалә фии китәәбиһил-кәриими әстәгыйҙү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаҙәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мүʼминиинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһү. Иннәллаһә мәгал-ләҙиинәт-тәкау, вәл-ләҙиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыыйҙү билләһи: ____________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ____________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмуллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә кааләллаһу тәбәәракә вә тәгаалә фил-кәләәми. Вә иҙәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйҙү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәл-ләҙиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ҙәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл

әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мүкыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгууҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә’мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәруун. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

## Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:

Безне туры юлга күндергән Аллаһыга мактау булсын.[2] Аннан башка безне берәү дә (туры юлга) күндерә алмый.

Коръәни Кәримдә: **«Әмма Аллаһы теләми торып, сез тели алмас-сыз. Һичшиксез, Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе»**, – дип әйтүче Аллаһы – барлык кимчелекләрдән дә Пакь.

Без бердәнбер булган Аллаһыдан башка илаһның юклыгына һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның Расүле һәм колы булуына шаһитлык итәбез. Без Пәйгамбәребез, аның балалары, хатыннары,

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

[2] 3 тапкыр әйтелә.

элек яшәп киткән изгеләребез һәм һидаять юлында булган һәркем өчен, Аллаһының рәхмәтен сорыйбыз.

Һәм аның турыдан-туры хәлифәләре – мөэминнәрнең хакимнәренә: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәдән Аллаһы риза булсын. Кыямәт көнендә барлык пәйгамбәрләргә һәм табигыйннәргә Аллаһының ризалыгы һәм рәхмәте булсын.

Моннан соң Аллаһыга гыйбадәт кылучылар Аңа итагать итсен.

> **«Һичшиксез, Аллаһы –** [гөнаһлардан] **курыккан һәм** [Раббыларының ризалыгын гына өмет итеп] **игелекле гамәлләр кылган кешеләр белән».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:128

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: ____________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: ______________________________________________________________

**Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:**

Дөреслектә, иң дөрес һәм төзек сөйләм – ул Аллаһының Сөйләме. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтүенчә:

> **«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез** [Аллаһы тарафыннан] **рәхмәт ителерсез»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

> **«Һичшиксез, Аллаһы хозурында** [хакыйкый һәм кабул ителгән] **дин – Ислам** [дине генә]**».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.**

Без Аллаһыдан барыбыз өчен дә рәхмәтен иңдерүен сорыйбыз. Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәм ике дөньяда да булачак. Син – Ишетүче, Якын һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы. Пәйгамбәрләргә сәламнәр һәм Аллаһының рәхмәте булсын. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыга мактаулар булсын.

**Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:**

Аллаһыга мактаулар, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм аңа иярүчеләргә сәламнәребез һәм Аллаһының рәхмәте булсын.

Аллаһы Тәгалә Изге Китабыбызда әйткәнчә:

> **«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм** [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] **сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Йә, Аллаһы, тугры хәлифәләр: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәгә һәм җәннәт белән шатландырылган алты сәхабәгә, Расүлебезнең югары дәрәҗәдә булган абыйлары – Хәмзә бине Габделмотталиб һәм Габбас бине Габделмотталибка, шәһит булып киткән сөекле оныклары Хәсән белән Хөсәенгә рәхмәтеңне иңдер. Сәхабәләр һәм табигыйннәр өчен Кыямәт көнендә Аллаһының рәхмәтен, ризалыгын ирештер.

Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәмең ике дөньяда да булачак. Дөреслектә, Син – догаларыбызны Ишетүче һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы!

Йә, Аллаһы, динебез Исламга ярдәм итүчеләргә Син дә ярдәм ит (өч тапкыр әйтелә). Мөэминнәрне җәберләүчеләрне көчсезләндер. Безгә, галимнәргә, юлчыларга, исәннәргә һәм үлеләргә – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә тынычлык һәм тәртип билгелә.

**Иң соңыннан, «Әгууҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

**«Һичшиксез, Аллаһы** [һәрнәрсәне аңлатыр өчен, иңдергән китабында] **гадел булырга, изгелек кылырга һәм** [бигрәк тә] **якын туганнарга** [мохтаҗ булган нәрсәләрен] **бирергә** [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] **әмер итә.** [Зина кебек] **Фәхешлектән,** [көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] **тыелганнан һәм** [кешеләргә] **җәберзолым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Аллаһыны зикер итегез. Хакыйкатьтә, Ул сезнең ни кылганнарыгызны белә.

# Вәгазьләр

*11 апрель вәгазе,*

*шәввәл аеның 13 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Чапан-чалмадан йөрү – сөннәт

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Галәмнәрне юктан бар кылган Раббыбыз Аллаһы Тәгаләгә барча олуглау-мактауларыбыз булсын! Аның соңгы расүле, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салаватларыбыз ирешсен.

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Бүгенге җомга вәгазебездә еш кына игътибарсыз калган, әмма гыйбадәтебез өчен зур мәгънәгә ия булган мөһим мәсьәләгә тукталасым килә. Бу мәсьәлә – намаз укыганда ир-атларның түбәтәй, чалма киюләре. Һәм бу тышкы яктан, ягъни безнең кыяфәттә чагылган, бер гыйбадәт кенә түгел, ул безгә рухи яктан камилләшергә, тыйнаграк булырга ярдәм итә торган гамәл.

Ни өчен намаз укыганда түбәтәй, чалма кию, ягъни башны каплау мөһим соң? Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә бу тормышны Аллаһы Тәгалә белән яшәүнең, һәр намазны хошугълык белән, ягъни ихласлык белән, бирелеп, кыйммәтен белеп укуның серләрен күрсәтте. Һәм ул үти торган сөннәтләрнең берсе булып намазда башны каплау торды. Галимнәребез аңлатканча, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм намазны һәрвакыт түбәтәй-чалмадан укыган, һәм бу аның сөннәтеннән булган.

Мәшһүр мөселман галимебез Имам әл-Куртуби болай дип язган: «Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм намаз укыганда чалма

кия торган булган, һәм бу мөселманнар өчен намаз укуда үрнәк булып тора. Бу тышкы тыйнаклыкның һәм намазга хөрмәтнең әһәмиятен ассызыклый»[1].

Хәнәфи мәзһәбенең бөек галиме Имам Ибне Габидин үзенең «Радд әл-Мохтар» дип аталган хезмәтендә болай дип язган: «Эчке хошугълыгыбызның ни дәрәҗәдә тирән булуына карамастан, истә тотарга кирәк: сөннәтне дөрес үтәү һәм тәкъвалыкның тышкы чагылышы – гыйбадәтебезнең мөһим өлеше»[2].

Димәк, хөрмәтле дин кардәшләрем, бу сүзләрдән күрәбез: намаз ул – җаныбызның эчке халәте генә түгел, бу гыйбадәтнең тышкы гамәлләре дә, һәр аерым күренеше дә бик мөһим. Һәм башны каплау ул – намазга хөрмәт-ихтирам күрсәтү, рухи камиллеккә омтылуның чагылышы.

Шулай итеп, истә калдырыйк: әгәр намаз укыганда башка түбәтәй яки чалма кию мөмкинлеге бар икән, моны үтәү хуплана.

Шәфигый мәзһәбенең күренекле галиме шәех Әбү Бәкер әд-Димьяти әйткән: «Намаз вакытында башны һәм җилкәләрне ачу хупланмый, чөнки бу намазга киенү-бизәнү сөннәтенә каршы килә»[3]. Монда сүз, әлбәттә, ир-атлар турында бара. Һәм галимнең «бизәнү» дигән сүзенә игътибар итик. Ягъни намаз безнең көнебезнең мөһим өлеше, мөһим бер вакыйгасы булып торырга тиеш. Без, башка ниндидер мөһим вакыйгага киенгән, бизәнгән сыман, намазга да, тиешле таләпләрен үтәп, киенергә тиешбез.

Үзебезнең хәнәфи мәзһәбе буенча намазны түбәтәй-чалмасыз уку мәкруһ санала. Һәм бу да намазга мөнәсәбәтебезнең нинди булырга тиешлеген күрсәтә. Имам Ибне Габидин болай дигән: «Баш киемсез намаз уку мәкруһ, чөнки бу намазны ихтирам итмәүнең билгесе булып тора…»[4] Мөмкинлегебез була торып, бу мәсьәләне игътибарсыз калдырмыйк.

1 Имам әл-Куртуби, «Тәфсир әл-Җәмигъ ли әхкәм әл-Коръән».

2 Имам Ибне Габидин, «Радд әл-Мохтар», 2 т., 391 б.

3 «Иганәтү-т-талибин», 1/226.

4 Имам Ибне Габидин, «Радд әл-Мохтар», 2 т., 391 б.

Мәшһүр галим Мулла Гали әл-Карый Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең чалма турындагы күп кенә хәдисләрен китерә. Мәсәлән: «Чалма белән (укылган) ике рәкәгать чалмасыз (укылган) җитмеш рәкәгатьтән яхшырак»[1].

Хөрмәтле дин кардәшләрем, димәк, чалма ул – кием генә түгел, гыйбадәтнең дә мөһим бер өлеше һәм мөселман мәдәниятендә тирән мәгънәгә ия. Ул бер гореф-гадәткә иярү генә түгел. Уйлансак, чалма безгә гомеребезнең кыскалыгын, һәрдаим рухи камилләшү юлында булырга тиешлегебезне, һәр гамәлебезнең Аллаһы ризалыгы өчен булырга тиешлеген искә төшереп тора бит. Чалма кәфенлектән тора һәм үлемне искә төшереп тора.

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Бүгенге дөньяда күп кенә гореф-гадәтләр югалып, кыйммәтләр онытылып бара. Әмма без түбәтәй-чалма киюнең дә, башка дини горефләребезнең дә тирән мәгънәгә ия булуын истә тотарга һәм сакларга тиешбез. Моның тышкы билге генә булмыйча, рухи камиллек, Аллаһы каршында хошугълыкның бер юлы булуын онытмыйк.

Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Минем сөннәтләремне саклаган кеше җәннәт юлында булыр», – дип әйткән. Сөннәтне үтәү ул – Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең гамәлләрен кабатлау гына түгел, ә алар аша калебләребездә Аллаһы Тәгаләгә карата ихтирам, күндәмлек, ихласлык кебек хис-тойгыларны арттыру.

Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, сәхабәләр, бөек галимнәребез намазларына ничек киенгән? Алар, Аллаһы Тәгалә белән сөйләшер өчен, мәчеткә барыр өчен, булган иң матур, яхшы, пөхтә киемнәрен сайлап, ислемайлар сөртеп, иң күркәм рәвештә киенә торган булганнар. Ир-атның намазга футболка урынына озын җиңле кием сайлавы дөрес, яхшы була, чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гадәттә кия торган өс киеме ул бүген без чапан дип атый торган кием кебек булган. Димәк, чапан белән чалма яки түбәтәй ул муллалар киеме түгел. Һәр мөселман ир-ат, сөннәтне үтәү нияте белән, озынчарак күлмәк яки чапан, киң

[1] Дәйләми, Суюты, «Җәмигъ әл-Кәбир».

чалбар, түбәтәй яки чалма кияргә тырышырга тиеш. Моны намазга мәчеткә барганда, яки инде җомга намазына, яки гает намазына булса да үтәргә тырышсак иде. Элек бабаларыбызның ничек киенгәнен карасак, аларның киеме тулысынча сөннәткә туры килгәнен күрәбез, бу бит бер мода гына булмаган.

Динебезне ныгыта торган, безне Аллаһы Тәгаләгә якынайта торган горефләребезгә кайтсак иде. Дин кардәшләрем, мөмкинлеге булган һәр ир-ат намаз укыганда тиешенчә киенсен, түбәтәй-чалмасын кисен, шулай намазына ихтирамын арттырсын.

Аллаһы Тәгалә Үзенә якынайта торган гамәлләр кылырга, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең юлыннан барырга һәм башкалар өчен үрнәк булырга насыйп итсен! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Данис хәзрәт Бәһаветдинов,*
*Питрәч районы Яңа Шигали авылының*
*Габдрахман бине Гауф исемендәге мәчете имам-хатыйбы*

*18 апрель вәгазе,*

*шәввәл аеның 20 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Намаз укуда өч сорауга җавап

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барлык мактау-олыглауларыбыз бар галәмнәрне тәрбияләүче, рәхмәтле, Кыямәт көне хуҗасы булган Аллаһы Тәгаләгә! Яраткан пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм туры юлдан баручыларга Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте һәм сәламе булсын!

Хөрмәтле мөселман кардәшләребез, без, гади мөселманнар, үзебезнең көнебезгә карасак, аның иртән эшкә бару, вакытында намазларыбызны уку, садакалар бирү, хәйриячелек белән шөгыльләнү, мәчет каршында яки мәдрәсәләрдә гыйлем алу һәм башка шундый эшләр белән сугарылганын күрербез. Һәрбер фән өлкәсендә үзенең зур галимнәре булган кебек, динебездә дә андый галимнәр бар. Һәм алар, үзләренең гомерләрен гыйлемгә багышлап, безнең өчен тормышның калган өлкәләрен алып баруны җиңеләйттеләр. Шуңа да без 20–40 елыбызны гыйлем алуга, дәлилләр эзләүгә түгел, ә алдарак искә алган гамәлләргә багышлый алабыз.

Әмма, һәр проблема үзе турында еш кына искә төшереп торырга яраткан кебек, безнең җирлектә дә гасырлар буе килгән тәртипне бозу, фетнә кертү галәмәтләрен күрә алабыз. Һәм еш кына бу фетнәчеләрнең лозунгы болайрак яңгырый: «Синең галимгә, мәзһәбкә яки инде Пәйгамбәребезгә иярәсең киләме?»

Әлбәттә, мондый сүзләр әзер булмаган акыллар өчен бик тә куркыныч кебек тоелырга мөмкин. Шуңа да вәгаземне Татарстан Диния нәзарәте чыгарган «Ислам дине нигезләре» китабыннан өзекләр белән дәвам итәм, чөнки төрле мәзһәбләр ул – төрле фикерләр дигән сүз. Галимнәребез бу фикерне ничек аңлата: «Фикерләр үзгәлеге – Аллаһының бер рәхмәтедер. Аллаһы Тәгалә тарафыннан соңгы пәйгамбәр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән бөтен кешелек өчен яраклы шәригать күндерелгән. Әмма кешеләрнең яшәү шартлары һәм яшәү урыннары төрле булганлыктан, кешеләр берберсеннән холыклары, аң-белем дәрәҗәләре һәм физик үзенчәлекләре белән аерылып торганлыктан, шәригатьнең кайбер күрсәтмәләрендә зур булмаган аерымлыкларның сакланып калуы кирәк булган. Һәм нәкъ менә иң төп мәсьәләләрне чишүдәге мондый иркенлек динебезгә үзенчәлекле холык бирә һәм аңа бөтен шартларда да яшәп килергә һәм үсәргә, җирдәге һәрбер кеше өчен ачык булып калырга мөмкинлек бирә дә инде.

Мөхәммәд пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм төрле вакытларда бер үк дини йолалаларны зур булмаган аермалыклар белән башкарган, бер үк сорауга җавап итеп төрле киңәшләр биргән, кешеләрне бер үк төрле хәлләрдә төрлечә хәрәкәт итәргә өйрәткән. Ләкин мөһим һәм иң төп нәрсә бер булган һәм гел үзгәрешсез калган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең биргән барлык киңәшләре һәм вәгазьләре, китергән мисаллары барлык очракта да дөрес булган.

Ислам галимнәре Коръәнне һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Сөннәтен тирәнтен өйрәнеп, бөтен охшашлыкларны һәм аермалыкларны искә алып, тупланган белемнәрне дини-хокукый мәктәпләр – мәзһәбләр – рәвешендә системалаштырган. Ислам диненең беренче гасырларында уннан артык мәзһәб булган. Алга таба аларның күбесе яшәвен туктаткан, чөнки аларның үсешен дәвам иттерерлек кешеләр табылмаган. Шунлыктан, объектив сәбәпләр аркасында, дүрт рәсми танылган мәзһәб калган. Аларның һәрберсе шул мәзһәбне коручы имамның исемен йөртә:

Әбү Хәнифә, әш-Шәфигый, Мәлик, Хәнбәл – Аллаһы Тәгалә аларның барсынннан да разый булсын!»

Шушы мәзһәбләр арасында төп мәсьәләләрдә аерымлыклар булмаса да, кайбер кечкенә мәсьәләләрдә аларны күрергә мөмкин, әлбәттә. Һәм галимнәребез бу аерымлыкларны Раббыбызның рәхмәте дип тә әйтеп узды! Безнең Татарстан җирлегендә элек-электән олуг галим Әбү Хәнифә нигез салган юл бара. Шуңа күрә намазларыбызны, уразаларыбызны һәм башка гыйбадәтләребезне шушы юл галимнәре өйрәтеп калдырган рәвештә башкарабыз.

Бүгенге көндә кайбер кешеләрнең намазда «Фатиха» сүрәсеннән соң «әмин» сүзен кычкырып әйтергә, кулларны башкача тотарга кирәк дигән кебек фикерләрен ишетергә мөмкин. Шуңа да бүген кыскача шушы мәсьәләләргә тукталып үтәрбез.

Беренчесе – «Фатиха» сүрәсеннән соң кычкырып «әмин» дип әйтү. Бу ислам галимнәре төрле фикердә булган мәсьәләләрнең берсе. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәләренең һәм хәнәфи мәзһәбе галимнәренең бу мәсьәлә буенча карашын, хәдисләр белән ныгытып, карап китик.

Хәнәфи һәм мәлики мәзһәбләре буенча, «әмин»не тыныч, пышылдап эчтән әйтергә кирәк. Бу мәсьәләдә мәзһәб галимнәре юкка гына шундый фикергә килмәгәннәр. Хәзрәти Вәгыйль бине Һуҗер радыяллаһу ганһе сөйләгәнчә, ул Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән бергә намаз укыган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм «гайриль магъдууби галәйһим вәләд-дааалиин» дигән сүзләргә килеп җиткәч, тавышын төшереп «әмин» дигән[1].

Мәшһүр галим, табигыйн Галькамә рәхимәһуллаһ үзенең әтисеннән радыяллаһу ганһе җиткергән, ә аның әтисе Аллаһының Расүле галәйһиссәлам белән бергә намаз укыган. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам «гайриль

[1] «Нәсбур-Райә», 1 том, 494 бит.

магъдууби галәйһим вәләд-дааалиин» дигән сүзләргә җиткәч, тыныч кына «әмин» дигән[1].

Шулай ук әлеге мәсьәләдә сәхабәләребезнең дә фикерләрен карарга кирәк. Әбү Вәгыйль рәхимәһуллаһ җиткергәнчә, хәзрәти Гали радыяллаһу ганһе һәм Габдуллаһ бине Мәсгуд радыяллаһу ганһе «Бисмилләһ», «Әгузү билләһ» һәм «әмин»не тавыш белән әйтмәгәннәр[2]. Шулай ук Әбү Вәгыйль җиткергәнчә, хәзрәти Гомәр һәм Гали радыяллаһу ганһүмә «Бисмилләһ» һәм «әмин»не башкалар ишетерлек итеп әйтмәгәннәр[3].

Имам Габдерраззак рәхимәһуллаһ үзенең «әл-Мүсәннәф» китабында һәм имам Мөхәммәд рәхимәһуллаһ «Китабүл-Әсәр»дә мәшһүр табигыйн Ибраһим ән-Нәхагыйның рәхимәһуллаһ сүзләрен җиткергәннәр: «Имам биш нәрсәне тыныч әйтә: «Сүбхәнәкә-ллаһүммә...» («Сәнә» догасы), «Әгузү билләһ», «Бисмилләһи...», «әмин» һәм «Раббәнә ләкәл-хәмд».

Шулай ук икенче мәсьәлә булып намазда һәр рәкәгатьтә тәкбир вакытында кулларны күтәрү тора. Хәнәфи мәзһәбе буенча, кулларны күтәрү беренче тәкбирдә (тәкбирүл-ихрам) генә башкарыла, намазның башка хәрәкәтләрендә, мәсәлән, рөкүгъка киткәндә һәм аннан торганда, куллар күтәрелми. Бу фикер хәдисләр һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәләре сүзләренә нигезләнгән.

Мәсәлән, хәзрәти Габдуллаһ бине Мәсгуд радыяллаһу ганһенең мондый сүзләре тапшырыла: «Мин Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең, Әбү Бәкернең һәм Гомәрнең артыннан намаз укыдым. Алар беренче тәкбирдән кала башка вакытта кулларын күтәрмәделәр». Шулай ук хәзрәти Әсвәд радыяллаһу ганһенең мондый сүзләре тапшырыла: «Мин Гомәр бине әл-Хаттабның беренче тәкбирдә ике кулын күтәргәнен күрдем, ә калганнарында күтәрмәде».

1 «Мөснәд Әхмәд», «Мөстәдрәк әл-Хаким».

2 «Мәҗмәгүз-Зәваид».

3 «Игля’ус-Сүнән».

Бу сорауда табигыйннәр фикерен дә карап китәргә була. Шәгъби, Ибраһим ән-Нәхагый һәм Әбү Исхак кебек мәшһүр табигыйннәр, намаз башланганда кул күтәреп, башка күтәрмәгәннәр.

Галимнәребезнең тикшеренүенә караганда, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм башлангыч чорларда намазның төрле өлешләрендә кулларын күтәргән, әмма соңрак бу бетерелгән, һәм ул беренче тәкбир вакытында гына кул күтәрү белән чикләнгән. Шулай итеп, хәнәфи мәзһәбе бу дәлилләргә нигезләнеп, кулларны кереш тәкбире вакытында гына күтәрү турындагы фикердә тора, кулларның алга таба күтәрелүен мәкруһ дип саный.

Һәм бүген карап китәсе өченче мәсьәлә – намазда имам артыннан Коръән уку. Хәнәфи мәзһәбендә намазны имамга оеп укыганда, җәмәгатьнең «Фатиха»ны һәм башка Коръән аятләрен укуы мәкруһ санала. Бу фикер хәдисләргә һәм сәхабәләрнең кайбер дәлилләренә нигезләнгән.

Мәсәлән, хәзрәти Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе тапшырган хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә: «Имам аның артыннан иярсеннәр өчен куелган. Шуңа күрә, ул тәкбир әйткәндә тәкбир әйтегез; ул укыганда тыңлагыз һәм дәшмәгез». Шулай итеп, бу хәдис намазда аятьләр укылган вакытта имамны тыңлау һәм дәшмәү кирәклеген күрсәтә.

Хәзрәти Җәбир бине Габдуллаһ радыяллаһу ганһе тапшырган хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Имам артыннан укучының кыйраәте булып имамның кыйраәте тора». Кыйраәт ул – Коръән аятьләрен уку. Димәк, бу имамның Коръән укуының аңа ияреп намаз кылучылар өчен дә җитәрлек булуын күрсәтә. Шулай ук хәзрәти Габдуллаһ бине Мәсгуд һәм Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмә кебек кайбер сәхабәләр имам артыннан намаз кылучылар сүрәләрне үзләре укымыйча, имам укуын тыңларга тиеш дигән фикердә булганнар.

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Хәнәфи мәзһәбе ул – Имам Әбү Хәнифәнең шәхси иҗаты түгел. Инде күргәнсездер, ул сәхабәләрнең һәм табигыйннәрнең гамәлләренә корылган бер мәктәп. Бүгенге көндә фикһта 4 мәзһәб билгеле,

һәм без аларның барысын да хөрмәт итәбез. Аларга карата бәхәсләрне калдыру юлын сайлыйк. Өммәт бердәмлеге шәхси каршылыклардан мөһимрәк.

Намазда да беренче урында хошугълык булып, аны артык хәрәкәтләрсез, сүзләрсез, ихлас Аллаһы ризалыгы өчен дип уку булса иде.

Раббыбыз безгә динне дөрес аңлау бүләк итсен! Безне ахыргы көнебезгә кадәр намаз кылучылардан кылса иде, мөселманнарның йөрәкләрен берләштерсә иде! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Данис хәзрәт Баһаветдинов,*
*Питрәч районы Яңа Шигали авылының*
*Габдрахман бине Гауф исемендәге мәчете имам-хатыйбы*

*25 апрель вәгазе,*

*шәвввәл аеның 27 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Телебез – Аллаһының бер аяте

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне юктан бар кылучы, шул галәмнәрне тәрбия кылып һәм Үзенең төрле нигъмәтләре белән бүләкләп торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед-сәналәребез, олуглауларыбыз булса иде. Безне хак юлга күндерүче, барчабызга иң күркәм үрнәк булучы сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә күңелләребезнең түрләреннән чыккан сәламнәребез, салават-шәрифәләребез һәм һәртөрле изге догаларыбыз ирешсә иде!

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримнең «Бүлмәләр» сүрәсендә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّا خَلَقْنَاكُم مِّن ذَكَرٍ وَأُنثَىٰ وَجَعَلْنَاكُمْ شُعُوبًا وَقَبَائِلَ لِتَعَارَفُوا ۚ إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ ﴿١٣﴾

**«Ий кешеләр! Һичшиксез, Без сезне** [Адәм исемле] **бер ирдән һәм** [Хава исемле] **бер хатыннан яраттык.** [Һәммәгезнең дә ата-анасы бер булганга күрә, нәсел-чыгыш белән мактануның ни мәгънәсе бар?] **Без сезне** [бер-берегезгә уйламый-нитми теләсә ни сөйләр өчен түгел] **танышуыгыз өчен кавемнәр һәм кабиләләр иттек. Аллаһы**

**хозурында иң кадерлегез –** [иң асыл нәселдән булганнарыгыз түгел, Аллаһы Тәгаләнең харамнарыннанан сакланган] **бик тә тәкъвалык иясе булганыгыз. Һичшиксез, Аллаһы –** [һәрнәрсәне] **Белүче,** [һәрнәрсәдән] **Хәбәрдар».**

«Әл-Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:13

Аятьтә искә алынганча, Аллаһы кешеләрне халыкларга бүлде һәм һәр милләткә аерым тел бирде. Аллаһы Тәгалә бу төрлелекне хәтта «аять» дип атый. Ягъни аять ул – Аллаһының кодрәтен исбатлаучы бер күренеш:

وَمِنْ آيَاتِهِ خَلْقُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَاخْتِلَافُ أَلْسِنَتِكُمْ وَأَلْوَانِكُمْ ۚ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَاتٍ لِّلْعَالِمِينَ ﴿٢٢﴾

**«Күкләрне һәм җирне яратуы да, телләрегезнең һәм төсләрегезнең төрлелеге дә – Аның билгеләреннән (аятьләреннән). Һичшиксез, монда** [Аллаһы Тәгаләнең бөек сыйфатларын яхшы] **белгәннәр өчен билгеләр (аятьләр) бар».**

«Әр-Рум / Румлылар», 30:22

Бу аятьне аңлатканда, мәшһүр тәфсир галиме Ибне Кәсир (1301–1373) хәзрәтләре болай ди: «Болары – гарәп телле, ә болары – татар, аларның теле башка, болары – гөрҗи (грузин), ә болары – румлылар, франклар, бәрбәрләр, хәбәшиләр, һиндиләр, сәкалибәләр, хәзәрләр, әрмәннәр, көрдләр һәм башкалар. Аллаһы Үзе генә белә торган төрле тел ияләре бар».

Аллаһы Тәгалә беренче кеше итеп атабыз Адәм галәйһиссәламне бар кылган, аннары аңа иптәшкә анабыз Хаваны бар иткән. Алардан балалар туып, җир шарында кешелек дөньясы таралган. Әлбәттә, алар үзара сөйләшкән, аңлашканнар.

Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәламгә һәр нәрсәнең исемнәрен, атамаларын өйрәткән. Аллаһы Тәгалә Коръәндә бу хакта болай дип әйтә:

وَعَلَّمَ آدَمَ الْأَسْمَاءَ كُلَّهَا

**«Ул** [фәрештәләргә Адәм галәйһиссәламнең өстенлеген күрсәтер өчен, мәхлукатлар ия] **исемнәрнең** [һәм ни сәбәпле яратылганнарын] **барчасын аңа** [атабыз Адәм галәйһиссәламгә] **өйрәтте...»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:31

Кайбер гыйлем ияләре Аллаһы Тәгалә Адәмгә 72 тел өйрәткән дип әйтәләр. Алар кешеләр сөйләшкән бөтен телләрнең нигезләре булып торалар. Бүгенге көндә кешеләр бик күп телләрдә сөйләшәләр. Мәсәлән, Һиндстанда гына 447 тел, 2000 диалект бар диләр. 2024 елда җир шарында 7 164 төрле тел бар дип саналган.

Һәр халык үз телендә сөйләшә, аның кагыйдәләрен өйрәнә, телен сакларга тырыша. Шуңа күрә, дәүләт яки милләт күләмендә аны саклар өчен, туган тел көннәре дә билгеләнә ала. Татарстанда 26 апрель Туган тел көне буларак билгеләнгән. Ул Габдулла Тукайның туган көненә туры килә.

Тарихыбыздан без беләбез, мәшһүр галимнәребез, хәзрәтләребез дә туган телебезне саклау һәм үстерү турында бик борчылган. Мәсәлән, бөек галимебез Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәт һәр нәрсәдә мөселманлык вә татарлыкны күрергә сөйгәнлегеннән, һәр нәрсәнең милли булуына әһәмият биргән икән. Кибетләргә элеп куелган ләүхәләр (элмә librarytakталар) мөселманча (татарча) язылмаса яки мөселманча түбән генә язылса, эче пошкан: «Ник мөселманча язмыйсыз? Хөкүмәт тарафыннан тыючы булмастан! Шулай ук мөселманча язарга һәм мөселманчаны түбән-кечкенә генә түгел, ачык итеп, өскә язып куярга кирәк», – дип әйтә торган булган. Ул русча өйрәнүне тыймаган, шул ук вакытта милләттәшләре белән татар телендә генә сөйләшкән.

Аллаһы биргән телне саклау милләтне саклау була. Ләкин милләтне саклау телне саклауга гына калмаса иде, динебезне саклар өчен бер чара булса иде.

Башка чит телләрне өйрәнүне дин тыймый, чөнки тел ул – Аллаһының бер нигъмәте, иң зур нигъмәтләрнең берсе. Кеше башка кешеләр белән ара-

лаша, ул аларга мөрәҗәгать итә, алар белән элемтәгә керә, алар җиткергән мәгълүматны аңларга тырыша. Кеше мәгълүматны биш тойгы аркылы кабул итә. Алар: ис сизү, тәм тою, тотып карау, ишетү, күрү. Аларның өчесе белән аралашып булмый: ис сизү, тәм тою һәм тотып карау аркылы. Әлбәттә, искәрмә дә була ала. Мәсәлән, Брайль шрифты. Луи Брайль 1824 елда сукырларга нокталардан торган «әлифбасын», шрифтын тәкъдим итте. Алар шул вакыттан башлап бармак аркылы укый алалар.

Күз белән без язылганнарны укый алабыз һәм кешеләрнең башы, тәне белән кылган ишарәләрне күрәбез. Ләкин ул якты вакытта гына безгә файда китерә. Төнлә, караңгыда күреп булмаганда, язу, ишарә кылу, күрсәтү файда китерми.

Шуңа күрә колак аркылы мәгълүматны кабул итү иң уңайлысы, иң җиңеле, һәм сөйләшү дә җиңел әйбер: без сулаганда үпкәгә һава (кислород) керә, углекислоталы газ чыга, һәм һава чыкканда авазлар әйтәбез. Ә язу өчен язу әсбаплары, каләм, кәгазь кирәк. Шуңа күрә сөйләшү ул – Аллаһы биргән иң зур нигъмәтләрнең берсе.

Телләрне күбрәк белгән саен, кеше күбрәк белә башлый, күбрәк аңлый башлый. Хәзрәти Габдуллаһ бине әз-Зөбәер радыяллаһу ганһенең йөз колы булган, һәм ул, аларның күңелен күрер өчен, һәрберсе белән аның телендә сөйләшкән. Шәригать күзлегеннән ирләргә дә, хатын-кызларга да телләрне өйрәнү рөхсәт ителә. Кешеләргә үз төбәгендә таралган телләрне белү файдалы була, чөнки алай ул һәрбер кеше белән аның телендә сөйләшә ала, башкалар сөйләшкәндә сүзнең нәрсә турында барганын аңлый, имин була. Димәк, тел ул – аралашу чарасы.

Аллаһының илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәти Зәйд бине Сәбит радыяллаһу ганһегә яһүдиләрнең телен өйрәнергә куша, чөнки аларга ышанып бетмәгән була. Хәзрәти Зәйд (Мәдинә) яһүдиләренең телен ике атна эчендә өйрәнә. Аннан соң Пәйгамбәребез аларга хат язса яки алардан хат алса, Зәйдне чакыра торган була[1].

---

[1] Имам әт-Тирмизи, 2715; Әбү Давыд, 3645.

Әмма туган телдән дә өстенрәк тел була ала. Ул – дин теле. Аллаһы Тәгалә Үзенең белеме һәм хикмәте белән ахыр заман пәйгамбәрен гарәпләр арасыннан сайлап алган һәм аңа, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, Үзенең сүзе булган Коръәни Кәримне гарәп телендә иңдергән. Аллаһының илчесе әйтеп калдырган хәдисләр, аның Сөннәте шулай ук гарәп телендә сакланган.

Хәлифә Гомәр бине әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе хәзрәти Әбү Муса әл-Әшгари радыяллаһу ганһегә язган хатында болай ди: «Һәм шуннан соң Сөннәтне өйрәнегез, гарәп телен өйрәнегез һәм Коръәнне гарәпләр укыган кебек дөрес укыгыз, чөнки ул гарәп телендә (иңгән)»[1].

Икенче риваятьтә хәзрәти Гомәр бине әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе: «Гарәп телен өйрәнегез, чөнки ул – сезнең динегез, мирас бүлү хөкемнәрен өйрәнегез, чөнки ул – сезнең динегезнең бер өлеше», – дип әйткән.

Коръәни Кәрим, хәдисләр, шәригать гыйлеме китаплары – барысы да гарәп телендә. Гарәп теле – динебез теле. Гарәп телен камил рәвештә белмичә, Коръән аятьләрен һәм хәдисләрне аңлап булмый. Дини китаплар да гарәп телендә язылганнар.

Төп гыйбадәт булган намазны без гарәп телендә укыйбыз, намазга чакыручы азанны гарәп телендә әйтәбез. Башка телгә тәрҗемә итеп азан әйтергә яки намазны башка телдә укырга ярамый.

Имам әш-Шәфигый (Аллаһының рәхмәтендә булсын): «Бу динне торгызу, гыйбадәтләрне кылу гарәп телен белүгә бәйле. Шәригать гарәп телен мөселманнар теле дип таныды һәм аны өйрәнүне мәҗбүри кылды», – дип әйткән.

Күп галимнәребез җомга хотбәсе дә гарәп телендә булырга тиеш дигәннәр. Мәсәлән, дүрт мәзһәбебезне карасак, шәфигый мәзһәбе галимнәре моны ассызыклап әйткәннәр. Хәнбәли мәзһәбе галимнәре гарәп телен белгән кеше башка телдә хотбә укыса, җомга дөрес булмый дигәннәр. Мәлики

[1] Әбү Бәкер бине Әбү Шәйбә китерә.

мәзһәбе буенча хотбәнең гарәп телендә булуы шарт булып тора. Безнең хәнәфи мәзһәбе галимнәре дә моны искә алганнар.

Мәшһүр татар галимебез Әхмәтһади Максуди болай дип язган: «Һәр мөселманга гарәпчә белү ляземдер, чөнки динебезнең башы булган Коръәни Кәрим вә хәдис-шәрифләр гарәбидерләр. Дин китапларының олуглары вә хотбәләребезнең һәммәсе гарәпчәдер». Шуңа күрә ул гарәп телен өйрәтә торган бик күп дәреслекләр язган, урыны җәннәттә булсын!

Элек галимнәребез, имамнарыбыз берничә, хәтта дүрт-биш тел белгәннәр. Мәдрәсәдә алар фарсы телен, гарәп телен өйрәнгәннәр. Фарсы телендә язылган китапларны укыганнар, хәтта фарсы телендә шигырьләр язганнар. Туган телләрендә аралашып, рус телен дә белгәннәр. Безгә дә алардан үрнәк алып, туган телебезне камил белергә, күбрәк татарча китаплар укырга, үзара ана телендә аралашырга, ә Коръәнне аңлар өчен гарәп телен өйрәнергә тырышырга кирәк!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рәйхан хәзрәт Нәҗметдинов,*

*Түбән Кама шәһәренең «Ак каен» мәчете имам-хатыйбы*

*2 май вәгазе,*

*зөлкагъдә аеның 4 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Дәгъват гаиләдән башлана

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Газиз дин кардәшләрем, Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا قُوا أَنفُسَكُمْ وَأَهْلِيكُمْ نَارًا وَقُودُهَا النَّاسُ وَالْحِجَارَةُ

**«Ий иман китерүчеләр!** [Әмерләрне тотып, тыюлардан тыелып] **Үзүзләрегезне һәм гаиләләрегезне уттан саклагыз,** [башка утларның ягулыгы утын булса] **аның ягулыгы** [кяфер] **кешеләр һәм** [бик тиз кабынып, бик күп яндыра торган күкерт] **ташлар».**

«Әт-Тәхрим / Тыю», 66:6

Бу аятьтә Аллаһы Тәгалә беренче чиратта үзебезне, ә аннан соң гаилә әһелләребезне җәһәннәм газабыннан сакларга өнди. Ә гаиләне җәһәннәмнән ничек сакларга була соң? Бу хакта Имам әл-Әлуси үзенең тәфсирендә болай дигән: «Гаиләне уттан саклау ул – аларны нәсыйхәтләү һәм тәрбияләү аша һидаять юлына юнәлдерү».

Хәзрәти Гомәр радыяллаһу ганһе болай дигән: «Бу аять иңдерелгәннән соң, мин Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Ий Расүлуллаһ, без үзебезне саклый алабыз. Әмма ничек итеп якыннарыбызны, гаиләбезне, туганнарыбызны сакларга соң?» – дип сорадым. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Аллаһы Тәгалә сезгә тыйган әйберләрне аларга тыегыз һәм Ул сезгә әмер

иткәннәрне аларга үтәргә әмер итегез. Һәм бу алар белән ут арасында киртә булыр», – дип җавап кайтарды».

Ибне Мүнзир, әл-Хәким һәм башкалар хәзрәти Гали радыяллаһу ганһенең бу аять хакында әйткән мондый сүзләрен тапшыра: «Үзегезне һәм якыннарыгызны мәрхәмәтлелеккә (изгелеккә) өйрәтегез һәм әдәп өйрәтеп тәрбияләгез». Димәк, газиз дин кардәшләрем, монда да күрәбез, якыннарыбызны уттан саклау өчен, аларны изгелеккә өйрәтергә кирәк.

Бер хәдистә болай диелгән: «Якыннарына: «Намаз укыгыз, ураза тотыгыз, зәкят түләгез. Аллаһы Тәгалә сезне бергә җәннәттә җыйсын өчен, үз йортларыгызны, ятимнәрне һәм күршеләрегезне кайгыртыгыз!» – дип әйткән кешедән Аллаһы Тәгалә разый булсын». Димәк, бу хәдистә гаиләсен, туганнарын шулай дип нәсыйхәтләгән кешедән Раббыбыз канәгать, риза булсын диелә, шундый кеше мактала.

«Рух әл-бәян» һәм Имам әл-Әлуси тәфсирләрендә язылганча, Кыямәт көнендә иң авыр газапка тартылачак кешеләрнең берсе ул – үз якыннарын санга сукмаган, игътибар итмәгән кеше. Ягъни, якыннарын уттан сакларга теләп, аларга нәсыйхәт ясамаган кеше.

Башка аятьтә Раббыбыз болай дип әйтә:

وَأَنذِرْ عَشِيرَتَكَ الْأَقْرَبِينَ ﴿٢١٤﴾

**«**[Расүлем! Иң башта] **Син иң якын туганнарыңны** [ширек сәбәп булган газаплардан] **кисәт».**

«Әш-Шүгәра / Шагыйрьләр», 26:214

Газиз дин кардәшләрем, Раббыбыз безгә беренче чиратта иң якын кешеләребезне, иң якын туганнарыбызны дингә, гөнаһларны калдырырга чакырырга куша.

Башка аятьтә болай диелгән:

وَأْمُرْ أَهْلَكَ بِالصَّلَاةِ وَاصْطَبِرْ عَلَيْهَا ۖ

**«Гаиләңә** [һәм өммәтеңә] **намазны әмер ит. Үзең дә сабырлык белән аны үтә».**

«Та Һа», 20:132

Димәк, монда да күрәбез, без якыннарыбызны гыйбадәткә, изгелеккә чакырырга тиешбез. Хәдисләрдә хәбәр ителгәнчә, бу аять иңдерелгәннән соң, сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәр иртә белән кызы Фатыйма белән кияве Гали радыяллаһу ганһүмә йортына барып: «Намаз, намаз! (ягъни намаз вакыты керде)» – дия торган булган. Шулай ул аларны иртәнге намазга уятырга дип йөргән. Бер тәфсирдә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам шулай сигез ай дәвамында көн саен йөргән диелә. Бу инде әлбәттә башка мөселманнарга, безгә үрнәк күрсәтү максатыннан булган. Ә Гали белән Фатыйма радыяллаһу ганһүмәләр намазга тора алмаган дигән сүз түгел. Шулай итеп Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә йөкләнгән җаваплылыкны күрсәткән. Билгеле хәдистә әйтелгәнчә: «Һәр кеше ул – көтүче, һәм һәрберегез үз көтүе өчен җаваплы».

Хәзрәти Гомәр бине әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе үз йорт әһелләрен, гаиләсен төнге намазга уята һәм шушы **«Гаиләңә намазны әмер ит»** аятен укый торган булган. Хөрмәтле дин кардәшләрем, күрәбез, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам дә, сәхабәләр дә, үзләре гыйбадәт кылудан тыш, башкаларны дингә, изгелеккә чакыруга зур игътибар биргән, һәм беренче чиратта алар якыннарын нәсыйхәтләгәннәр. Бу безнең өчен үрнәк булса иде.

Газиз дин кардәшләрем, беренче укыган аятебездә Аллаһы Тәгалә башта «قُوا أَنفُسَكُمْ» ди, ягъни әүвәл **«үз-үзләрегезне саклагыз»** – үзегездән башлагыз. Монда да зур хикмәт бар: һәрберебез яхшылыкны, гыйбадәтне үзеннән башларга тиеш. Беренчедән, без шуны аңларга тиешбез: әгәр кеше үз-үзен газаптан, җәһәннәмнән коткара алмый икән, ул башка кешеләрне дә коткара алмаячак, башка кешеләрне дә изгелеккә чакыра алмаячак. Кеше сөйләгән сүзенә үзе туры килмәсә, аңа кем иярсен инде? Әгәр без якыннарыбызның, гаиләбезнең

безнең нәсыйхәтләребезгә, дәгъватыбызга колак салуын теләсәк, без әүвәл үзебез шушы юлда ихлас булырга, әүвәл үзебезне нәсыйхәтләргә, шуны үтәргә тиешбез. Менә игътибар иткәнегез бардыр: очкычта очканда, бортпроводниклар пассажирларга инструкция биргәндә, нәрсә ди? Башта битлекне (масканы) үзегез киегез, аннан соң гына балагызга кигезегез ди алар. Шушы дөньяви хәлдә дә күрәбез бит – әгәр без башта үз-үзебезгә ярдәм итмәсәк, үзебезне коткармасак, без башкаларны коткара, файда китерә алмыйбыз.

Безнең элекке чорларда яшәгән тәкъва дин кардәшләребез, галимнәребез әйтә торган булган: «Мин үз хатынымның яки атымның, дөямнең үз-үзен тотышыннан үземнең Аллаһыга карата мөнәсәбәтемне аңлый идем». Ягъни, хатынымның, балаларымның, хәтта атымның миңа мөнәсәбәте, миңа карата күрсәткән кирелеге яки, киресенчә, күндәмлеге ул – минем Раббыма карата мөнәсәбәтемнең чагылышы, ди алар. Аллаһы Тәгалә белән аралары ерагайса, алар шуның чагылышын якыннары белән мөнәсәбәтләрдә күрә белгән. Аллаһы Тәгаләнең әмерләрен тиешенчә үтәсәм, Ул якыннарымны да төзәтә иде, дигәннәр.

Бер җәмәгать эшлеклесенең, гомере буе җәмгыятькә хезмәт иткән кешенең, кабер ташында шундый сүзләр язылган булган: «Мин дөньяны үзгәртергә тырыштым. Әмма моның мөмкин булмавын аңладым. Мин үзем яшәгән илне генә үзгәртергә булдым. Әмма аннан соң моның да мөмкин булмавын аңладым. Мин торган шәһәремне үзгәртә башладым. Аннан соң шәһәрне үзгәртүнең дә көчемнән килмәвен аңладым. Урамымны үзгәртә башладым. Аны да үзгәртә алмавымны аңладым. Шуннан соң мин туганнарымны үзгәртеп карадым. Һәм моның мөмкин булмавын аңладым. Аннан соң гаиләмә тотындым. Бу да көчемнән киләрлек булмады. Ахырда гына мин үз-үземне үзгәртергә кирәклеген аңладым. Әгәр мин үземне үзгәрткән булсам, гаиләм дә үзгәрер иде. Гаиләм үзгәргәч, туганнарым да үзгәрер иде. Алар белән урам, аннан соң шәһәр, аннан соң илебез һәм бар дөнья да үзгәрер иде. Әмма мин моны бик соң, үлем түшәгендә ятканда гына аңладым».

Хөрмәтле дин кардәшләрем, Аллаһы Тәгалә әйтә бит:

إِنَّ اللَّهَ لَا يُغَيِّرُ مَا بِقَوْمٍ حَتَّىٰ يُغَيِّرُوا مَا بِأَنفُسِهِمْ ۗ

**«Һичшиксез, алар** [кешеләр] **үз нәфесләрендә булганны алмаштырмый торып, Аллаһы кешеләрдә булганны алмаштырмый».**

«Әр-Рагъд / Күк күкрәү», 13:11

Димәк, үзгәрешләр әүвәл үзебездән башлана. Кеше гаиләсе өчен җаваплылык ала икән, Аллаһы каршында үзе һәм гаиләсе өчен җавап бирәчәген аңлый икән, шул вакытта гына ул, беренчедән, үзе динне өйрәнә башлаячак, икенчедән, хатынын һәм балаларын дингә өйрәтәчәк. Әгәр ул үзе дин нигезләрен белми икән, ул гаиләсенә аларны өйрәнү өчен бар шартлар тудырырга тиеш. Менә шул үзебезне һәм гаиләләребезне уттан саклау булыр, иншәАллаһ.

Аллаһы Тәгалә ризалыгына ирешеп, үзебезне дә, гаилә әһелләребезне дә ут газабыннан саклый алган мөэминнәрдән булырга насыйп булсын! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*ТР МДН Дәгъват бүлеге*

*9 май вәгазе,*

*зөлкагъдә аеның 11 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Бөек Җиңүгә 80 ел

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхәәбиһи әҗмәгыйн.

Әлхәмдүлилләһ, газиз дин кардәшләрем, бүген без гадәттәгечә якты, чиста, җылы мәчетләребезгә җыелдык. Ә аңарчы шушы мөбарәк җомга көннәрендә иртән тыныч кына уянып, намазларыбызны кылдык, мул өстәлләребез артына утырып ашадык, исән-сау булган якыннарыбызны, күршеләребезне сәламләдек, хәлләрен белештек... Безнең өчен шушы гади, көн дә башкарыла торган эшләр бер дә ниндидер зур, әһәмиятле булып тоелмый. Әмма, әгәр уйлансак, боларның нинди зур нигъмәт, Аллаһының бер бүләге булуын аңлар идек! Әле ничә еллар элек кенә әби-бабаларыбызның мондый төрледән-төрле ризыклары, киемнәре, җиһазлары – берсе дә юк иде бит. Алар кечкенәдән сугыш, ятимлек ачысын да, ачлыкны да, авыр хезмәтнең дә нәрсә икәнен күреп үскән. Безнең күбебез моны китаплардан укып кына белә. Күп-күп шөкер кылычулардан булсак иде!

Хөрмәтле дин кардәшләрем, инде җомгабыз шундый тарихи көнгә туры килгән икән, бүгенге вәгазебез халкыбыз һәм гомумән бар кешелек тарихында тирән эз калдырган сугышларның берсе турында булыр. Бөек Ватан сугышы халкыбыз өчен зур сынау булып, батырлык, бердәмлек һәм ватанпәрвәрлек мисалы булып калды. Барыбыз да беләбез, быел илебез бу вәхшәттән котылуның 80 еллыгын билгеләп үтә.

Бу сугыш һәрберебезнең гаиләсенә кагылган, югалтулар бик күп булган, үзебезнең Татарстан җирлегебездән дә әтиләребез, бабаларыбыз – миллионнарча ир-ат – үз җирләре, гаиләләре, диннәре өчен шул сугыш кырында ятып калган. Аллаһы Тәгалә аларның барысыннан да разый булса иде. Без, бүгенге буын кешеләре, бу сугышта катнашкан, иребез өчен көрәшкән бабаларыбызның, тылда булган әбиләребезнең батырлыгын онытмаска тиешбез. Аларның корбаннары, аларның батырлыгы булмаса, бүгенге көндә тыныч һәм азат яшәү мөмкин булмас иде. Без аларның хәтерен мәңге сакларга, алар өчен һәрвакыт догада булырга тиешбез.

Бөек Ватан сугышы вакытында батырлык һәм фидакярлек фронтта гына түгел, ә тылда да күрсәтелә. Тылда калган хатын-кызлар, картлар, балалар сугышның авыр елларында Ватан өчен зур эшләр башкара. Үзләре ач-ялангач, авыр эшләрдә (заводларда, басуда, госпитальләрдә) эшләп, алар бар булганын диярлек фронттагы сугышчыларга җибәреп барган. Тарихка күз салсак, сугышның беренче дүрт аенда гына да Татарстанның җиңел сәнәгате фронтка 2 миллион тирәсе формалы кием, плащ-палаткалар, миллионнан артык пар аяк киеме җибәргән. Республикабыз, СССРның башка күп төбәкләре кебек үк, мөһим тыл үзәге булган. Моннан фронтка корал, азык-төлек, кием-салым һәм башка кирәк-яраклар җибәрелеп торган. Әле зуррак буын хәтерлидер, авылларда элек сугыш чорында тракторист, комбайнер булып көн-төн басуда эшләгән әбиләр исән иде әле. Ул вакытта алар яшь кенә кызлар булган, әмма ир-атлар булмагач, бу авыр эшне дә кемгәдер башкарырга кирәк булган.

Шуңа күрә, тылдагы батырлык ул – көн саен авырлыкларга каршы тору, үз-үзеңне, үз нәфесеңне онытып, җиңү өчен эшләү булган. Димәк, тылдагы балалар, хатыннар, картлар фронттагы солдатлар кебек үк батырлар булган, кеше гомере өчен көрәшкән, Аллаһы Тәгалә аларга хәерле әҗерләрен насыйп итсен!

Сугыш башланганнан соң, Советлар Союзы мөселманнары, үткән үпкәләрне онытып, барысы да Ватаныбызны яклауга өлешләрен керткән.

Алар армиягә дә булышкан, фронтка акча җибәргән, солдатларга ашар ризык, дошманга каршы торырга кораллар тапкан. 1942 елның маенда Уфада ислам дин әһелләре съезды була. Анда чыгыш ясап, мөселманнарның Үзәк Диния нәзарәте рәисе мөфти Габдрахман Расулев болай дип әйтә: «Бүген Ватаныбызны яу кырында кулларына корал тотып, тылда фабрика һәм заводларда үз хезмәте белән җиңү эшенә ярдәм итмәгән бер генә кеше дә юк... Фронтка баручы сугышчыга кораллану белән ярдәм сугышта катнашуга тиң. Фронтка киткән сугышчыларның эш урыннарын алган ирләрнең һәм хатын-кызларның тыныч хезмәте сугышта катнашуга тиң». Менә шундый фикерле имамнарыбыз халыкны һәрдаим куәтләп торган.

Бөек Ватан сугышы безгә бердәмлекнең, дуслыкның һәм Ватанны сөюнең кыйммәтен күрсәтте. Хәзерге заманда без бу вакыйгаларны искә алып, яңа буынга тынычлыкны саклауның, Ватанны сөюнең һәм башка милләт кешеләренә хөрмәт күрсәтүнең әһәмиятен аңлатырга тиешбез.

Бүгенге көндә дә безнең егетләребез батырлык, каһарманлык һәм ватанпәрвәрлек күрсәтеп, махсус хәрби операциядә илебезнең иминлеген, бәйсезлеген һәм киләчәген саклау өчен көрәшә. Безнең егетләр – безнең каһарманнар. Алар авырлыкларга чыдамлылык белән каршы торалар, Ватанны яклау өчен үзләрен оныталар. Аларның һәр хәрәкәте, һәр карары – илебезнең һәм халкыбызның киләчәге өчен бер көрәш булып тора. Без бүгенге көндә дә бабаларыбызның һәм аталарыбызның батырлыгын дәвам итүче буын булып торабыз. Бөек Ватан сугышы вакытында кебек үк, бүген дә егетләребез Ватанны саклау өчен үзләрен фида кылалар.

Шулай ук, районнарда һәм авылларда гуманитар ярдәм оештыру – хәзер дә бик мөһим һәм кирәкле эш. Авылларда һәм шәһәрләрдә гуманитар йөкләр җыеп җибәрү халыкның бердәмлеген, дуслыгын һәм бер-беренә ярдәм итүен күрсәтеп тора. Бу эшләрдә бар ил катнаша: район җитәкчеләре, волонтерлар, мөфтият вәкилләре, имамнарыбыз, мәчетебезгә йөри торган мөселман кардәшләребез дә. Шунысы да бик мөһим, бу гуманитар йөкләрне

мөфтиятебез үзе үк алгы сызыкка барып, солдатларның кулларына тапшыра алды. Мөфтият вәкилләре алгы сызыкка барып, ничә тапкыр гуманитар йөкләрне илтте – бу аеруча җаваплы эш. Бу дини җәмәгатьнең һәм бөтен халыкның бердәмлеген күрсәтә. Аларның тырышлыгы һәм фидакярлеге безнең бөтен җәмгыять өчен мисал булып тора. Сугышчылар янына күп кенә имамнарыбыз, шул исәптән мөфти Камил хәзрәт, берничә тапкыр барып кайта алды, алгы сызыкка хезмәт итәргә 4 полк имамы җибәрелде.

Хөрмәтле мөселманнар! Без бүген мәчетләрдә җыелып җомга намазларын укый алабыз. Алгы сызыкка барып кайткан имамнарыбыз сүзләренә караганда, анда мөселман егетләребез окопларда «мәчетләр» ясап, шундый җирдә дә намазларын калдырмыйлар. Аллаһы аларга җиңеллекләр бирсә иде һәм ошбу вакыйгаларны тиз арада җиңү белән әйләндерсә иде. Әмин!

Хөрмәтле мөселман кардәшләрем, инде бик аз калсалар да, әле бүген дә 80 ел элек илебезгә җиңү алып кайткан исән-сау ветераннарыбыз, тыл ветераннары бар. Аларны гел искә алып, алар өчен догалар кылып, ярдәм кирәк булса, ярдәм итеп торырга кирәк. Үзебез шушы мәчетләрдә утырганда, кулларыбызны догага күтәрә алганда, әйдәгез, иренмик, Раббыбыздан илкөннәребезгә тынычлык, бәрәкәт, аяз күк йөзе бирүен сорап дога кылыйк. Мөселманнар яшәгән башка илләрдә, җирләрдә тынычлык урнашсын иде, золым бетсен иде дип ялварып торыйк.

Дин кардәшләрем, май аенда көтелгән, мөселманнар өчен әһәмиятле булган тагын бер вакыйга турында игълан ясап китәсем килә. Ел саен май аенда мәркәзебез Казанда «Россия – Ислам дөньясы» дип аталган зур форум уза. Һәм шушы халыкара форум белән беррәттән Болгар шәһәрендә без яхшы белгән Изге Болгар җыены узачак. Ел саен бу җыенга Татарстаныбыздан, чит төбәкләрдән килгән меңләгән мөселман кардәшләребез тарихыбызны искә төшерергә, бергә намаз һәм догалар кылырга җыела.

Аллаһы Тәгалә бар догаларыбызны кабул кылып, барчабызга иман байлыгы, ихласлылык белән яшәргә насыйп кылса иде. Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*ТР МДН Дәгъват бүлеге*

*16 май вәгазе,*

*зөлкагъдә аеның 18 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Кем ул Аллаһының әүлиясе?

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Хәзрәти Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шундый хәдисен тапшыра: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте: «Кем Минем әүлиямә (дустыма, якыныма) дошманлык күрсәтсә, Мин аңа сугыш игълан итәрмен. Колым, Мин аңа йөкләгән фарызларны үтәмичә, Миңа бернәрсә белән дә якыная алмас. Әгәр колым Миңа нәфелләр (өстәмә гыйбадәтләр) белән дә якынаерга теләсә, Мин аны яратырмын. Әгәр Мин аны яратсам, Мин аның ишетүче колагы булырмын, күрүче күзе булырмын, тотучы кулы булырмын, атлаучы аяклары булырмын. Әгәр Миннән нидер сораса, бирермен, әгәр Миңа сыенса, сыендырырмын».[1]

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу хәдистә Аллаһының сүзләрен китерсә дә, бу Коръән дәрәҗәсендәге Аллаһының сүзләре түгел. Бу хәдиснең сүзләре тәҗвид кагыйдәсе белән көйләп тә укылмыйлар, һәм һәрбер хәреф өчен ун әҗер дә бирелми. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең хәдисләрендә үз сүзләре белән Аллаһының сүзләрен күп китерә. Бу хәдисләр кодси хәдисләр дип атала.

Әлеге хәдис бай эчтәлекле һәм үз эченә күп кенә мәсьәләләрне ала. Аны өлешләргә бүлеп карарбыз.

[1] Имам әл-Бохари.

## Кем ул әүлия?

Иң элек хәдистә: «Кем Минем әүлиямә (дустыма, якыныма) дошманлык күрсәтсә, Мин аңа сугыш игълан итәрмен», – дип әйтелә. Әүлия ул – Аллаһының дусты, ул Аллаһыга якын булган кеше. Ул Раббысының кушканнарын үти һәм тыйганнарыннан тыела. Ул Раббысына өметләнә, Аны ярата, Аңа сыена һәм Аннан курка. Ул Раббысына кайтасын белеп, бу көнгә әзерләнеп яшәүче мөэмин. Шуңа күрә Раббысы аны Үзенә якын итте.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә алар турында болай дип әйтә:

أَلَا إِنَّ أَوْلِيَاءَ اللَّهِ لَا خَوْفٌ عَلَيْهِمْ وَلَا هُمْ يَحْزَنُونَ ﴿٦٢﴾ الَّذِينَ آمَنُوا وَكَانُوا يَتَّقُونَ ﴿٦٣﴾ لَهُمُ الْبُشْرَىٰ فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا وَفِي الْآخِرَةِ ۚ لَا تَبْدِيلَ لِكَلِمَاتِ اللَّهِ ۚ ذَٰلِكَ هُوَ الْفَوْزُ الْعَظِيمُ ﴿٦٤﴾

> **«Һичшиксез, Аллаһының вәлиләренә** [башкалар куркуга калган чакта] **бернинди курку да булмас, һәм** [кешеләр өмет иткән нәрсәләренә ирешмәгәннәре өчен хафага калганда] **алар хәсрәт чикмәс. Алар –** [Аллаһы Тәгалә тарафыннан килгән бөтен хакыйкатьләргә] **иман китергән һәм** [саклануы кирәк булган бөтен нәрсәләрдән сакланган] **тәкъвалык ияләре. Дөнья тормышында да, Ахирәттә дә бөтен сөенечле хәбәрләр –** [матур төшләр, мактаулар, фәрештәләрнең илтифаты, мәгъфирәт вәгъдәләре һәм җәннәт кебек нигъмәтләр] **алар өчен генә. Аллаһының** [мөэминнәргә вәгъдә иткән сөенечле хәбәрләрен белдергән] **сүзләрен үзгәртү** [һәм бу сүзләр урынына башкаларны әйтү] **юк. Бу –** [рәвештә ике җиһан сөенеченә лаек булу] **бик зур уңыш».**
>
> «Юныс», 10:62–64

Аллаһының әүлиясенә карата явызлык кылу аеруча зур гөнаһ булып санала. Әлбәттә, кемгә генә булмасын, ул нинди генә диндә булмасын, аңа карата явызлык кылу гөнаһлы, харам булып тора. Чөнки Аллаһы каршында

кеше – хөрмәтле зат, һәм башка мәхлуклар кешегә хезмәткә куелды. Әмма мөселман кешегә явызлык кылу аеруча тыела, чөнки ул Раббысына иман китергән һәм Аңа буйсынган. Менә шушы иманы аны аеруча зур дәрәҗәгә күтәрә. Әлеге хәдистә дә моңа басым ясала: «Кем Минем әүлиямә (дустыма, якыныма) дошманлык күрсәтсә, Мин аңа сугыш игълан итәрмен», – дип кисәтә безне Аллаһы Тәгалә.

Әгәр дә Аллаһы Тәгалә бу явызга сугыш игълан итсә, ул уңышка ирешә алмас, ул җиңелер. Бу икенче көнгә аның куллары корыр, паралич сугар дигәнне аңлатмый. Күп очракта аның тормышында бәлки бер әйбер дә үзгәрмәс. Ул үзенең язылган ризыгын алып, үз гомерен яшәп бетерәчәк. Әмма аның өчен бу дөнья уены беткәч, гомере ахырына якынайгач, Раббысы аны каты итеп тотып алып Үзенә кайтарыр һәм аны каты газапка дучар итәр. Менә бу аның җиңелүе булыр. Бу вакытта аның янында ирешкәннәре, дәрәҗәсе, ярдәмчеләре дә инде булмас. Моны бер Аллаһы Үзе генә белә. Бу дөнья – сыналу мәйданы, кешегә сайлау иреге һәм сайлаганын башкарырга көч бирелгән. Һәм бервакыт барысы да бетәчәк, һәм кеше Раббысы каршына хисапка килеп басачак.

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

لَا يَغُرَّنَّكَ تَقَلُّبُ الَّذِينَ كَفَرُوا فِي الْبِلَادِ ﴿١٩٦﴾ مَتَاعٌ قَلِيلٌ ثُمَّ مَأْوَاهُمْ جَهَنَّمُ ۚ وَبِئْسَ الْمِهَادُ ﴿١٩٧﴾

«[Ий Мөхәммәд өммәтеннән булу шәрәфенә ирешкән кеше!] **Кяфер булган кешеләрнең** [күп мөмкинлекләргә ия булып, иминлек һәм байлык эчендә] **шәһәрләрдә йөрүләре сине алдамасын.** [Аларның ахирәттә мәхрүм ителәчәк бу мөмкинлекләре мөэминнәр өчен әзерләнгән нигъмәтләргә нисбәтле] **Бик аз файдаланырлык нәрсә. Соңыннан сыеначак урыннары – җәһәннәм. Ул – нинди яман түшәк!»**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:196–197

Әмма мөселман – Аллаһының әүлиясе, аңа ни генә булмасын, ул гел отышта кала. «Авырлык килсә, ул сабыр итәр, уңыш килсә, ул шөкер итәр», – диде Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм. «Кем Аллаһыга һәм Аның Расүленә буйсынса, ул зур уңышка иреште», – диде Аллаһы Раббыбыз Коръәндә. Менә бу – чын отыш, менә бу – чын җиңү.

## Фарызларны үтәү

Аллаһы Тәгалә һәрбер кешегә бик якын. Якын Заты белән түгел, ә рәхмәте, күрүе, ишетүе, белеме белән якын. Ул кешене чолгап алган, аның күңелендәге серләрен, яшерен ниятләрен белүче. Аллаһы кешегә аның үз-үзеннән караганда да якынрак. Кеше үзе хакында бик күп нәрсәләрне белми, әмма Раббысы аның хакында барысын да белүче.

Әгәр кеше изгелек кылса, һәм аның изгелеге аның иманлы булуыннан чыкса, бу изгелек кешене Аллаһыга якынайта. Әмма кеше Аллаһыга чын якынаю белән якыная алмас, әгәр дә ул аңа йөкләнгән фарызларны үтәмәсә.

«Колым, Мин аңа йөкләгән фарызларны үтәмичә, Миңа бернәрсә белән дә якыная алмас», – дип әйтә Аллаһы Тәгалә әлеге хәдистә. Болар: биш вакыт намаз, Рамазан аенда ураза, байлыгы булса зәкят түләү һәм мөмкинлеге булса хаҗга барып кайту. Шулар арасында иң олысы булып намаз тора.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә нинди гамәл Аллаһыга иң сөкле дип сорау бирелгәч, ул: «Вакытында укылган намаз», – дип җавап биргән. Бу фарызларны бернәрсә белән дә алыштырып булмый, хәтта кеше тау кадәр алтынны садака итеп бирсә дә.

## Нәфел гыйбадәтләр

Фарызларга өстәлеп килгән сөннәт-нәфел гыйбадәтләрне үтәү дә киңәш ителә. Болар бигрәк тә биш намазның сөннәтләре, өстәмә уразалар, садакалар һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм киңәш иткән башка изгелекләр.

Әгәр дә мөселман, фарызларны үтәгәннән соң, үз теләге белән шушы нәфелләрне дә үтәсә: «Мин аны яратырмын», – диде Аллаһы Тәгалә. Әгәр дә ул явызлыклар, гөнаһлар кылып йөрмәсә, бу кешене Аллаһы Үзенә тагы да якын итә һәм ул Аллаһының әүлиясе (дусты) була. Әгәр диндар мөселман кеше, Аллаһы әмер иткән фарыз-вәҗибләрне үтәп барса, ул үзенең бурычын үтәгән булыр. Әмма ул бары тик фарызлар белән генә чикләнергә тиеш түгел, фарызларга өстәп нәфел гыйбадәтләрне дә (Пәйгамбәребез галәйһиссәлам кушкан сөннәтләрне, мөстәхәбләрне) үтәп барырга тиеш. Һәр фарыз булган намазның, зәкятнең, уразаның, хаҗның үз нәфелләре бар.

Без инде көндәлек биш вакыт намаз укыгач, намазның сөннәтләре хакында искә алып китми булмас. Фарыз намазларга (иртәнге, өйлә, икенде, ахшам, ястү) беркетелгән 12 рәкәгать намаз бар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларны гел үтәгән һәм сирәк вакытларда гына калдырган. Намаз укучыга бу намазлар билгеле. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Кем Аллаһы ризалыгы өчен көн саен өстәмә 12 рәкәгать намаз укып барса, Аллаһы аңа җәннәттә йорт салыр»[1].

Әгәр кеше фарыз намазын укыса, бурычы үтәлгән булыр, әмма сөннәтен укымыйча, аның намазы тәмам төгәлләнеп, камилләшеп бетмәгән булыр. Шуңа күрә хәнәфи мәзһәбендә сөннәтне үтәгәч кенә тәсбих тартыла. Шулай ук фарыз белән сөннәт намазлары арасын дөнья эшләре, сәүдә итү һәм ашап-эчүләр белән аеру дөрес булмас.

Кеше өчен иң кадерле нәрсә – ул аның күңелендәге иманы. Мөселман өчен иң куркыныч әйбер – иманын югалтып көферлеккә чыгуы. Көферлеккә чыгу кешене Аллаһының рәхмәтеннән мәхрүм итә. Без үзебезнең иң кадерле, иң кыйммәтле нәрсәбезне «җиде йозак» астында саклыйбыз. Әгәр бездә кыйммәтле бер асылташ булса, без аны ышанычлы сейфка салып саклыйбыз. Бу сейф бүлмәдә бикләнгән, бүлмә йорт эчендә бикләнгән, ә йорт биек диварлар белән уратылган, сигнализация дә куелган булыр иде. Әмма иман

---

1 Имам Мөслим.

белән чагыштырганда, бу бик кыйммәтле асылташ та берни түгел. Тик шулай да кайберәүләр иманнарын бик аз нәрсәгә дә сатып җибәрергә әзерләр.

اشْتَرَوْا بِآيَاتِ اللَّهِ ثَمَنًا قَلِيلًا فَصَدُّوا عَن سَبِيلِهِ ۚ إِنَّهُمْ سَاءَ مَا كَانُوا يَعْمَلُونَ ﴿٩﴾

**«Болар – Аллаһының аятьләрен юк бәягә сатканнар һәм Аның юлыннан язганнар. Аларның кылган нәрсәләре нинди яман!»**

«Әт-Тәүбә», 9:9

Бу аятьтә сүз дөнья байлыгына алданып Коръәнне ташлаучылар, аннан ваз кичүчеләр хакында бара. Күңелдәге иман – иң кадерле нәрсә, шуңа күрә ул нык сак астында булырга тиеш. Иманның иң нык сакчысы ул – фарыз гамәлләрне үтәү. Фарызларны вәҗибләр саклый. Вәҗибләрне – сөннәтләр, ә аларны мөстәхәб гамәлләр саклый. Боларның барысын да дини гыйлем ныгыта. Менә мондый сак астында иман сакланып, нык булып торыр. Әмма гамәлләр булмаса, иман зәгыйфь булыр, сүнәргә дә мөмкин. Коръәндә шайтан Аллаһыга болай дип әйтә:

قَالَ فَبِمَا أَغْوَيْتَنِي لَأَقْعُدَنَّ لَهُمْ صِرَاطَكَ الْمُسْتَقِيمَ ﴿١٦﴾ ثُمَّ لَآتِيَنَّهُم مِّن بَيْنِ أَيْدِيهِمْ وَمِنْ خَلْفِهِمْ وَعَنْ أَيْمَانِهِمْ وَعَن شَمَائِلِهِمْ ۖ وَلَا تَجِدُ أَكْثَرَهُمْ شَاكِرِينَ ﴿١٧﴾

**«Ул әйтте: «Мине аздырганың өчен, мин Синең туры** [Ислам] **юлыңда, һичшиксез, аларга каршы** [киртә булып] **утырачакмын. Аннары мин аларга – алларыннан һәм артларыннан, уңнарыннан һәм сулларыннан** [вәсвәсәләр бирер өчен, һәр дүрт тарафларыннан] **киләчәкмен, һәм Син аларның күпчелеген шөкер итүчеләр булարак тапмаячаксың».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:16–17

Бигрәк тә кеше үлем түшәгендә ятканда, көчсез булганда, шайтан аны алдап, үзенә авыштырыр. Хәбәрләрдә килгәнчә, имам Әхмәд үлем түшәгендә ятканда: «Юк әле, юк әле», – дигән сүзләр кабатлый. Соңыннан янындагылар аннан бу хакта сорагач, ул: «Минем яныма шайтан килде һәм: «Син мине җиндең, әй Әхмәд», – диде. Ә мин аңа: «Юк әле, юк әле», – дип җавап бирдем», – дип әйткән. Ягъни, әле җан чыкмыйча, беркем дә шайтанның фетнәсеннән имин түгел.

## Әүлиянең тормышы

Шуннан соң хәдистә: «Әгәр Мин аны яратсам, Мин аның ишетүче колагы булырмын, күрүче күзе булырмын, тотучы кулы булырмын, атлаучы аяклары булырмын. Әгәр Миннән нидер сораса, бирермен, әгәр Миңа сыенса, сыендырырмын», – дип әйтә Аллаһы Тәгалә, шул мөэминнең тоткан дәрәҗәсен белдереп. Ягъни, аның гөнаһлы сүзләрне тыңлыйсы килмәс һәм тыңламас, гөнаһлы күренешләргә карыйсы килмәс һәм карамас, аның гөнаһлы җиргә күңеле тартмас һәм анда бармас, һәм гөнаһлыга, харамга кулын сузмас һәм аңа кагылас.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Марат хәзрәт Сәйфетдинов,*
*Балтачның Үзәк мәчете имам-хатыйбы*

*23 май вәгазе,*

*зөлкагъдә аеның 25 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Зөлхиҗҗә аеның фазыйләтләре

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барлык галәмнәрне юктан бар кылган, барыбызга да төрле нигъмәт, сынау, саулык бирүче Аллаһы Тәгаләгә мактауларыбыз ирешсен. Һәм сөекле Пәйгәмбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребез түреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсен.

Газиз дин кардәшләрем, тиздән, 28 нче майдан, без бик фазыйләтле һәм зур гыйбадәтләр ае булган зөлхиҗҗә аена басачакбыз. Зөлхиҗҗә аеның атамасы «хаҗ» сүзеннән алынган, һәм бу айда миллионнарча дин кардәшләребез хаҗ гыйбадәтен үти.

Шулай ук зөлхиҗҗә һиҗри календарьнең соңгы ае булып тора. Зөлхиҗҗә ае соңгы ай булу сәбәпле, без тулы бер елга йомгак ясап, киләсе елга кергәндә гөнаһлардан чистарынып, тәүбә кылып, яңа максатлар куярга тиешбез. Аллаһы Тәгаләнең безгә җибәргән бер рәхмәте, бәрәкәте бу. Елыбыз изге хаҗ кылына, корбан чалына торган зөлхиҗҗә ае белән тәмамлана.

Белүебезчә, Ислам динендә аерым айлар «харам айлар» дип зурлап аерып алынган. Бу хакта Коръәни Кәримдә әйтелгән:

إِنَّ عِدَّةَ الشُّهُورِ عِندَ اللَّهِ اثْنَا عَشَرَ شَهْرًا فِي كِتَابِ اللَّهِ يَوْمَ خَلَقَ السَّمَاوَاتِ
وَالْأَرْضَ مِنْهَا أَرْبَعَةٌ حُرُمٌ ۚ ذَٰلِكَ الدِّينُ الْقَيِّمُ ۚ فَلَا تَظْلِمُوا فِيهِنَّ أَنفُسَكُمْ ۚ

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында айларның саны Аллаһының күкләрне һәм җирне яраткан көндәге** [катгый карарын белдергән] **язуында** [Ләүхелмәхфүздә] **– унике. Шуларның дүртесе – харам** [айлар]**. Бу –** [рәвешле елның унике ай булып, шуларның дүртесенең харам кылынуы турындагы хөкем Ибраһим һәм Исмәгыйльдән галәйһимәссәлам калган] **хак дин.** [Моннан соң бернинди айда да, бигрәк тә] **Боларда** [гөнаһ эшләү һәм гыйбадәтләрне кире кагу белән җаныгызны җәһәннәмгә атып] **үз-үзегезгә золым итмәгез».**

«Әт-Тәүбә», 9:36

Зөлхиҗҗәнең беренче ун көне аеруча да фазыйләтле. Аллаһы Тәгалә Үзенең Изге Китабында шул көннәр белән ант иткән:

وَالْفَجْرِ ﴿١﴾ وَلَيَالٍ عَشْرٍ ﴿٢﴾

**«**[Иртән агарып килгән] **Таң белән ант итәмен!** [Зөлхиҗҗәнең башындагы] **Ун төн белән дә** [ант итәмен]**!»**

«Әл-Фәҗр / Таң», 89:1–2

Бу көннәрдә кылынган игелекле гамәлләр иң яхшылары булып исәпләнәләр, бу хакта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Аллаһы бу ун көндә кылынган игелекле эшләрне башка көннәрне кылынган игелекле эшләргә караганда ныграк ярата…»[1]

Зөлхиҗҗәнең шушы беренче ун көне арасында елның иң яхшы ике көне бар. Алар – Корбан гаете (зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көне) һәм Гарәфә көне (зөлхиҗҗә аеның 9 нчы көне).

Корбан гаетенә килгәндә, хәзрәти Габдуллаһ бине Курт әс-Сүмәли әл-Әзди радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шундый сүзләрен тапшырган: «Аллаһы Тәгалә каршында иң бөек көннәр булып Корбан бәйрәме һәм әл-Карр көннәре тора» дигән[2].

[1] Имам әл-Бохари, әт-Тирмизи.

[2] Имам Әбү Давыд.

Әл-Карр көне ул – зөлхиҗҗә аеның унберенче көне, ул гарәп теленнән тәрҗемә иткәндә «урнашу» дигәнне аңлата. Чөнки хаҗ кылучылар бу көнне хаҗның бар йолаларын да башкарып бетереп, корбаннарын чалып бетереп, Мина үзәнлегендә булалар, шунда урнашалар.

Зөлхиҗҗә аенда күбрәк саваплар алырга теләсәк, нинди гыйбадәтләр кыла алабыз соң?

1. Беренчедән, бу көннәрдә иң яхшы эшләр булып хаҗ һәм гомрә кылу санала.

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кем хатынына якын килмичә һәм гөнаһ кылмыйча бу Йортка хаҗ кыла, ул аннан анасы тудырган көндәге кебек булып кайта»[1].

2. Икенчедән, «Аллаһу әкбәр» дип тәкбир әйтү, Аллаһыны зикер итү бик саваплы гамәлләрдән исәпләнә.

Хәзрәти Ибне Гомәр радыяллаһу ганһедән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шундый сүзләрен тапшыралар: «Бу көннәрдә ешрак «Ләә иләәһә илләә-Ллааһ» дип тәһлил, «Аллаһу әкбәр» дип тәкбир, «Әлхәмдүлилләһи» дип тәхмид әйтегез».

3. Өченчедән, бу тугыз көндә ураза тоту – иң яхшы эшләрнең берсе.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Аллаһы бу ун көндә кылынган игелекле эшләрне башка көннәрдә кылынган игелекле эшләргә караганда ныграк ярата». Ә ураза – иң яхшы, иң игелекле, иң зур саваплы эшләрнең берсе. Аннан тыш, Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм кешеләрне ураза тотарга өндәгән. Мәсәлән, үзенең хәдисләренең берсендә ул шулай дигән: «Аллаһы ризалыгы өчен тоткан бер көн ураза Аллаһы колының йөзен тәмуг утыннан җитмеш еллык ераклыкка читләтер»[2].

---

[1] Имам әл-Бохари.

[2] Имам әл-Бохари, Мөслим.

Бу көннәрнең тагын бер үзенчәлеге шунда: тугызынчы көндә – ул көн Гарәфә көне дип атала – хаҗда булмаганнар өчен ураза тоту аеруча фазыйләтле гамәл булып тора. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән Гарәфә көнендә ураза тоту турында сорагач, ул: «Бу көн уразасы үткән һәм киләчәк ел гөнаһларының гафу ителүенә сәбәп булып тора», – дип әйткән[1].

Гарәфә көнне хаҗ кылучылар Гарәфәт дип аталган үзәнлектә дога кылып, хаҗ гамәленең зур гыйбадәтен үти. Хаҗга бара алмаучыларның да Аллаһының рәхмәтенә ирешү мөмкинлеге бар – аның өчен әлеге көнне ураза тотып гыйбадәттә үткәрү мөһим. Бу көндә Аллаһы ризалыгын алыйм дип, шушы хәдис буенча гамәл кылсак иде.

4. Дүртенчедән, гает намазын уку һәм вәгазь тыңлау өчен мәчеткә иртәрәк килергә тырышырга кирәк. Гает намазы – Исламның олуг йолаларының берсе.

5. Бишенчедән, бәйрәм көнне яки тәшрикъ көннәрендә корбан чалырга. Корбан чалу гыйбадәте ул – бөек пәйгамбәребез Ибраһим галәйһиссәләмнең сөннәте.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә әйтә:

فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ ﴿٢﴾

**«Раббың өчен намаз укы һәм** [Аның исеме белән] **корбан чал** [да, корбан итләрен юксылларга тарат]**».**

«Әл-Кәүсәр / Муллык», 108:2

Хөрмәтле дин кардәшләрем, Аллаһы Тәгалә барчабызга да зөлхиҗҗә аеның беренче ун көненең фазыйләтләрен истә тотып, изге гамәлләрне, гыйбадәтләребезне арттырырга насыйп итсә иде! Нинди генә ай булмасын, белеп торыйк, Аллаһы Тәгәлә – Күреп торучы, Ишетүче. Аллаһы Раббыбыз беребезне дә Үзенең чиксез рәхмәтеннән аермаса иде. Әмин.

[1] Имам Мөслим.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Салават хәзрәт Мортазин,*

*Мөслим авылының «Нур» мәчете имам-хатыйбы*

*30 май вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аеның 3 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Корбан гаетенә әзерлек. Гарәфә көне

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Газиз дин кардәшләрем, без сезнең белән мөбарәк вакытта яшибез, ул – зөлхиҗҗә аеның беренче 10 көне. Әлеге көннәрнең өстенлеге һәм фазыйләте хакында хәзрәти Габдуллаһ бине Габбас радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шундый хәдисен тапшыра: «Аллаһы каршында әлеге ун көндә кылынган изге гамәлдән дә сөеклерәк гамәл юктыр» [1]. Ягъни, шушы көннәр эчендә эшләнгән изгелекләр өчен Аллаһы Раббыбыз савапларны тагы да арттыра.

Һәм шушы көннәрнең берсе, аеруча дәрәҗәле һәм фазыйләтле көн ул – зөлхиҗҗә аеның 9 нчы көне – Гарәфә көне. «Гарәфә» атамасы Мәккә шәһәреннән якынча 22 чакрым ераклыкта урнашкан Гарәфәт җирлегенә бәйле. Шушы Гарәфәт үзәнлегендә динебезнең 5 нигезенең берсе булган хаҗ гамәлен кылучылар зөлхиҗҗәнең 9 нчы көнендә җыелып, кояш баеганчыга кадәр Раббыбызны олылап, мактап, догалар белән мөрәҗәгать итәләр. Шушы зур гыйбадәткә бәйле рәвештә без бу көнне «Гарәфә көне» дип атыйбыз.

Гарәфә көне хакында мөэминнәрнең анасы Гайшә радыяллаһу ганһә мондый хәдис тапшыра: «Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгалә Үз колларын уттан иң күбе Гарәфә көнендә коткара», –

[1] Имам әл-Бохари.

дип әйтте»[1]. Ягъни Гарәфә көне ул – җәһәннәм газабыннан котылуга ирешү көне.

Бу көнне, әйткәнемчә, хаҗиларыбыз изге урыннарда хаҗ гамәлләрен кылалар. Без изге җирләрдә булмасак та, Аллаһы Тәгалә бу бөек көндә безне дә әҗер-савап алудан, мәгъфирәт-кичерү табудан мәхрүм итмәде.

Хәзрәти Әбү Катәдә радыяллаһу ганһе сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый хәдисен тапшырган: «Гарәфә көнендә тотылган ураза үткән һәм киләчәк елда булган гөнаһларны ярлыкауга сәбәп булыр»[2].

Шуңа да бу көннәрдә, аеруча Гарәфә көнендә, гамәл-гыйбадәтләребезне арттырып, Аллаһы Раббыбызга якынаерга һәм тәмуг утыннан котылучылардан булырга тырышыйк.

Шулай ук, Гарәфә көне керү белән, тәшрикъ тәкбире көннәре башлана. Гарәфә көненең иртәнге намазыннан башлап һәм зөлхиҗҗәнең 13 нче көнендәге икенде намазына хәтле Аллаһы Раббыбызны зурлап тәкбирләр әйтү вәҗиб (тиешле) булып тора. Ягъни 5 нче июньнең иртәнге намазыннан алып, 9 нчы июньнең икенде намазын кертеп, һәрбер фарыз намаздан соң, ике якка сәлам бирү белән, без тәкбир әйтәчәкбез. Бу хакта Аллаһы Раббыбыз «Әл-Бәкара» сүрәсенең 203 аятендә әйтте:

وَاذْكُرُوا اللَّهَ فِي أَيَّامٍ مَّعْدُودَاتٍ ۚ

**«**[«Тәшрикъ көннәре» дип беленгән] **Санаулы көннәрдә** [намазларыгыздан соң һәм шайтанга таш атканда, тавыш белән тәкбир әйтеп] **Аллаһыны зикер итегез!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:203

«Санаулы көннәр» дип шушы көннәр искә алына.

1 Имам Мөслим.

2 Имам Мөслим.

Тәкбир әйтү тәртибе:

الله أكبر الله أكبر، لا إله إلا الله والله أكبر، الله أكبر ولله الحمد

«Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, ләә иләһә иллә Аллаһу вә Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр вә лилләһи-л-хәмд».

Аның мәгънәсе: «Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка гыйбадәткә лаек зат юк һәм Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга барча мактаулар!»

Ир-атлар тәкбирне тавыш белән, хатын-кызлар үзләре ишетерлек итеп кенә, кычкырмыйча әйтә.

Гарәфә көне узу белән, динебездә каралган ике олуг гаетнең берсе – «Гыйд әл-әдха» – Корбан бәйрәме керә. Һәм, белгәнебезчә, безнең динебездә бәйрәм көннәре Аллаһыга сөекле булган гамәл-гыйбадәтләрне үтәү һәм бер-береңә изгелек кылу белән үткәрелә. Вә Корбан гаетендә Аллаһы Раббыбыз Үз колларына махсус гыйбадәт үтәүне йөкләде, ул – Корбан чалу. Аның хакында күбебез намазга басканда беренчеләрдән итеп өйрәнгән «Әл-Кәүсәр» сүрәсендә Аллаһы Раббыбыз әйтә:

فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ ﴿٢﴾

**«Раббың өчен намаз укы һәм** [Аның исеме белән] **корбан чал** [да, корбан итләрен юксылларга тарат]**».**

«Әл-Кәүсәр / Муллык», 108:2

Шуңа да Корбан гаете көннәрендә үз акылында булган, балигълык яшенә җиткән, ирекле булган, сәфәрдә дип исәпләнмәгән һәм корбан көннәре җиткәндә малы нисабка ирешкән һәрбер мөселманга үзе өчен корбан чалу вәҗиб булып тора. Һәм корбан ул гомергә бер генә чалынмый, ә ел саен, әйтелгән шартлар үтәлгән очракта, чалынырга тиешле. Шуңа да: «Былтыр үзем өчен чалган идем инде, быел берәр туганым өчен чалам», – дип әйтү

дөрес дип исәпләнми, мөмкинлеге булган кеше ел да иң элек үзе өчен чалырга бурычлы.

Һәм Корбан бәйрәме дигәндә, газиз дин кардәшләрем, без ул көнне чыннан да бәйрәм итеп үткәрүебез хәерле: бер-берләребезне тәбрикләү сүзләре һәм изге-теләкләр белән котлап, туганнар-дусларыбыз белән бергә бәйрәм табыннары алдында җыелып, бер-беребезгә бүләкләр бирешеп. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтеп калдырган: «Бүләк бирешегез – бер-берегезне яратырсыз»[1]. Һәм безнең бүләкләребезгә иң элек якын туганнарыбыз, тормыш иптәшебез һәм балаларыбыз лаеклы, шуңа да бүләк бирүне алардан башлыйк.

Балаларыбыз дигәндә, алар – Аллаһының зур бүләге, ләкин шулай ук бу зур җаваплылык та. Безнең өстебездә аларны саклау, кирәк-яраклар белән тәэмин итү һәм аларга дөрес тәрбия бирү бурычы тора. Вә шушы бәйрәм көннәрендә бу җаваплылык турында онытмыйк, инде үзләрен тәртипле тота белгән балаларыбызны иртән уятып, үзебез белән гает намазына алып килик, гаеттән соң чалыначак корбан итләрен мескен-фәкыйрьләргә өләшкән чакта да үзебез белән ияртеп барыйк, күңелләренә динебезнең йолалары, рухи тәрбия яшьтән үк сеңеп калсын.

Аллаһы Раббыбыз барчабызга да киләчәк олуг Корбан гаетен исән-имин каршы алырга, өстебездә булган зур гыйбадәтләрне тиешле рәвештә башкарып чыгарга насыйп итсен. Корбан чалырга ниятләгәннәргә кабул корбаннар чалырга, хаҗиларыбызга кабул хаҗлар кылып, яшәгән җирләренә исән-имин әйләнеп кайтырга насыйп әйләсен! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә

[1] Имам әл-Бохари, «Әл-Әдәб әл-мөфрад».

дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Булат хәзрәт Баһаветдинов,*

*Түбән Кама шәһәре «Җәмигъ» мәчетенең икенче имам-хатыйбы*

## Корбан гаете хотбәсенең гарәпчә укылышы

### خُطْبَةُ عِيدِ الاَضْحَى

### الْخُطْبَةُ الْاُولَى

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ تَقَدَّسَ ذَاتُهُ عَنِ الشِّرْكِ وَالزَّوَالِ وَنَطَقَتِ الْاَدِلَّةُ بِاَوْصَافِهِ الْجَلاَلِ وَالْجَمَالِ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ تَحَيَّرَ فِي كُنْهِ ذَاتِهِ الْعُقُولُ وَالْاَفْهَامُ وَعَجزَ عَنْ اِدْرَاكِ صِفَاتِهِ الرَّاسِخُونَ الْاَعْلاَمُ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ اَكْرَمَ عِبَادَهُ الْمُؤْمِنِينَ بِالشُّهُورِ وَالْاَيَّامِ فِصَالِ. وَاَوْجَبَ فِي هَذِهِ الْاَيَّامِ عَلَى الْاَغْنِيَآءِ الْحَجَّ وَالطَّوَافَ بِالْبَيْتِ الْمُكَرَّمِ عِنْدَ الْكَبِيرِ الْمُتَعَالِ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لآَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. نَحْمَدُ اللَّهَ الَّذِي لَمْ يَتَّخِذْ صَاحِبَةً وَلاَ وَلَدًا وَلَمْ يَكُنْ لَّهُ شَرِيكٌ فِي الْمُلْكِ وَلَمْ يَكُنْ لَّهُ وَلِيٌّ مِّنَ الذُّلِّ وَكَبِّرْهُ تَكْبِيرًا وَاَشْهَدُ اَنْ لَّا اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ

وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَاَشْهَدُ اَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ شَفِيعُ الْعُصَاةِ فِي يَوْمِ الْجَزَاءِ بِاَمْرِ اللَّـهِ الْكَرِيمِ الْمُتَعَالِ.

صَلَّى اللَّـهُ تَعَالَى وَسَلَّمَ عَلَيْهِ وَعَلَى ءَالِهِ وَاَصْحَابِهِ الْمَوْصُوفِينَ بِاَحْسَنِ الْاَخْلاَقِ وَاَطْيَبِ الْاَحْوَالِ.

يَا اَيُّهَ النَّاسُ. اِعْلَمُوا اَنَّ يَوْمَكُمْ هَذَا يَوْمٌ شَرِيفٌ وَعِيدٌ لَّطِيفٌ لِّلْخَوَاصِّ وَالْعَوَامِّ يَوْمٌ عَظِيمٌ قَدَرُهُ لِلْاَنَامِ، عَظِّمُوا هَذَا الْيَوْمَ بِالْاِنْعَامِ وَالْاِحْسَانِ وَاِيْصَالِ الْاَرْحَامِ. اِنَّ اللَّـهَ تَبَارَكَ وَتَعَالَى اَوْجَبَ عَلَيْنَا النَّحْرَ بِقَوْلِهِ وَانْحَرْ، وَاَمَرَ خَلِيلَهُ بِذَبْحِ وَلَدِهِ الْاَشْهَرِ وَاُفْدِيَ بِكَبَشٍ مِّنَ الْجَنَّةِ بِوَاسِطَةِ الْمَلَكِ الْمُقَرَّبِ وَلاَ يَجِبُ عَلَى الْفَقِيرِ عَلَى الْقَوْلِ الْمُعْتَبَرِ الْبُدْنَةُ عَنْ سَبْعَةٍ وَالضَّأْنُ وَالْمَعْزُ عَنْ وَاحِدٍ مُجْزِأَةٌ وَلاَ يَجُوزُ الْعَجْفَآءُ وَالْعَرْجَآءُ وَمَقْطُوعَةُ الْاُذُنِ وَالْاِلْيَةِ وَالَّذِي لاَ يَمْشِي عَلَى الْمَنْسَكِ عِنْدَ الْمَذْهَبِ الْمُعْتَبَرِ.

ضَحُّوا عَنْ اَطْيَبِ اَمْوَالِكُمْ وَعَظِّمُوهَا امْتِثَالاً لِّاَمْرِ رَسُولِ اللَّـهِ الْمُقَرَّرِ كَمَا قَالَ رَسُولُ اللَّـهِ صَلَّى اللَّـهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: عَظِّمُوا ضَحَايَاكُمْ فَاِنَّهَا عَلَى الصِّرَاطِ مَطَايَاكُمْ. وَاِنَّ اللَّـهَ تَعَالَى اَوْجَبَ عَلَيْنَا تَكْبِيرَ التَّشْرِيقِ عَقِبَ الْفَرْضِ مِنْ فَجْرِ يَوْمِ عَرَفَةَ اِلَى اخِرِ اَيَّامِ التَّشْرِيقِ بِقَوْلِهِ تَعَالَى: وَاذْكُرُوا اللَّـهَ فِي اَيَّامٍ مَّعْدُودَاتٍ. اَعُوذُ بِاللَّـهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ، بِسْمِ اللَّـهِ الرَّحْمَنِ

الرَّحِيمِ: يَآ اَيُّهَ الَّذِينَ ءَامَنُوا اتَّقُوا اللَّـهَ وَلْتَنْظُرْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ لِغَدٍ وَاتَّقُوا اللَّـهَ اِنَّ اللَّـهَ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ.

بَارَكَ اللَّهُ لَنَا وَلَكُمْ فِي الْقُرْءَانِ الْعَظِيمِ وَنَفَعَنَا وَاِيَّاكُمْ بِالْاَيَاتِ وَالذِّكْرِ الْحَكِيمِ وَاَسْتَغْفِرُ اللَّـهَ الْغَفَّارَ لِي وَلَكُمْ وَلِسَائِرِ جَمَاعَةِ الْمُسْلِمِينَ الْحَاضِرِينَ اَجْمَعِينَ اِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ الْجَوَادُ الْكَرِيمُ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ.

## الْخُطْبَةُ الثَّانِيَةُ

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ نَحْمَدُهُ وَنَسْتَعِينُهُ وَنَسْتَغْفِرُهُ وَنُؤْمِنُ بِهِ وَنَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَنَعُوذُ بِاللَّهِ مِنْ شُرُورِ اَنْفُسِنَا وَمِنْ سَيِّئَاتِ اَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللَّهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَمَنْ يُضْلِلْهُ فَلاَ هَادِيَ لَهُ. وَاَشْهَدُ اَنْ لَا اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَاَشْهَدُ اَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ.

اِنَّ اللَّهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ. يَآ اَيُّهَا الَّذِينَ ءَامَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا.

اَللَّـهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى ءَالِ مُحَمَّدٍ بِعَدَدِ مَنْ صَلَّى وَصَامَ.

اَللَّـهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى ءَالِ مُحَمَّدٍ بِعَدَدِ مَنْ قَعَدَ وَقَامَ.

صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَيْهِ وَعَلَى جَمِيعِ الْاَنْبِيَاءِ وَالْمُرْسَلِينَ وَعَلَى مَلاَئِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ وَعَلَى اَهْلِ طَاعَتِكَ اَجْمَعِينَ مِنْ اَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَالْاَرَضِينَ. وَارْحَمْنَا وَاحْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ الْاَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْاَمْوَاتِ اِنَّكَ اَنْتَ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ وَمُنْزِلُ الْبَرَكَاتِ وَرَافِعُ الدَّرَجَاتِ وَقَاضِيُ الْحَاجَاتِ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

اَللَّهُمَّ ارْحَمِ الْخُلَفَاءَ الرَّاشِدِينَ وَالْاُمَرَاءَ الْمَاضِينَ الَّذِينَ قَضَوْا بِالْحَقِّ وَكَانُوا يَعْدِلُونَ.

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ وَاهْدِ مَنْ خَذَلَ الدِّينَ.

عِبَادَ اللَّهِ، اِنَّ اللَّهَ يَاْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْاِحْسَانِ وَاِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ.

اُذْكُرُوا اللَّهُ الْعَلِيَّ الْعَظِيمَ الْحَيَّ الْقَيُّومَ يَذْكُرْكُمْ وَاشْكُرُوهُ يَزِدْكُمْ وَاسْتَغْفِرُوهُ يَغْفِرْ لَكُمْ وَلَذِكْرُ اللَّهِ تَبَارَكَ وَتَعَالَى اَعْلَى وَاَوْلَى وَاَعَزُّ وَاَجَلُّ وَاَعْظَمُ وَاَتَمُّ وَاَكْبَرُ.

# Корбан гаете хотбәсенең кириллицага транслитерациясе

## Беренче хотбә

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллаһү әкбәр вә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мән тәкаддәсә ҙәәтүһү ганиш-ширки вәззәүәәл. Вә нәтакатил-әдилләтү би әүсаафиһил-җәләәли вәл-җәмәәл.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр, вә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мәң тәхәййәра фии күнһи ҙәәтиһил-гукуулү вәл-әфһәәм, вә гаҗәзә ган идрааки сыфәәтиһир-раасихуунәл-әгъләәм.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр вә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мән әкрамә гыйбәәдәһүл-мүэминиинә бишшүһүүри вәл-әййәәмил-фисааль. Вә әүҗәбә фии һәәҙиһил-әййәәми галәл-әгънийәәил-хәҗҗә вәт-таүәәфә бил-бәйтил-мүкәррами гыйндәл-кәбиирил-мүтәгааль.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр вә лилләһил-хәмд. Нәхмәдүллааһәл-ләҙии ләм йәттәхыйҙ саахибәтәү-үә ләә вәләдә, вә ләм йәкүнләһү шәриикүң фил-мүлки, вә ләм йәкүнләһү вәлиййүн-минәҙ-ҙүлли вә кәббирһү тәкбиираа. Вә әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһү вәхдәһүү ләә шәриикә ләһ. Вә әшһәдү әннә сәййидәнәә Мүхәммәдән габдүһүү вә расүүлүһү шәфиигуль-гусаати фии йәүмил-җәзәә’и би әмрилләәһил-кәриимил-мүтәгааль. Салләллааһү тәгааләә вә сәлләмә галәйһи вә галәә әәлиһи вә әсхәәбиһил-мәүсууфиинә би әхсәнил-әхъләәкый вә әтъйәбил-әхүәәл.

Йә әййүһән-нәәс! Игъләмүү әннә йәүмәкүм һәәҙәә йәүмүн шәриифүн вә гыйидүн ләтыйифүн лил-хаүәәссый вәл-гаүәәмм. Йәүмүн гаҙыймүң кадәруһү лил-әнәәм. Гаҙҙыймүү һәәҙәл йәүмә бил-ингаами вәл-ихсәәни вә

иисаалил-әрхәәм. Вә иннәллааһә тәбәәракә вә тәгәәлә әүҗәбә галәйнән-нәхра би каулиһи вәнхәр. Вә әмәра халииләһүү би ҙәбхи вәләдиһил-әшһәри вә үфдийә би кәбәшин минәл җәннәти би вәәситатил-мәләкил-мукарраб, вә ләә йәҗибү галәл-фәкыйри галәл-каулил-мүгьтәбәр. Әл-бүднәтү ган сәбгә-тин вәд-да'нү вәл-мәгзү гән вәәхидин мүҗзиәтү вә ләә йәҗүүзүл-гәҗфәәә'ү вәл-гарҗәәә'ү вә мәкътуугәтүл-үҙүни вәл-илйьәти вәлләзии ләә йәмшии галәл-мәнсәки гиндәл-мәҙһәбил-мүгътәбәр.

Даххүү ган әтъйәби әмүәәликүн вә гаҙҙыймүүһәәмтиҫәәлән лиәмри расүүлилләәһил-мүкаррар. Кәмәә каалә расүүлүллааһи салләллаһү галәйһи вә сәлләм: «Гәҙҙыймүү дахәәйәәкүм фәиннәһәә гәләс-сыйраати мәтаайәәкүм». Вә иннәллааһә тәгәәләә әүҗәбә галәйнәә тәкбиират-тәш-риикый гәкыйбәл-фәръды мин фәҗри йәүми гарафәтә иләә әхыйри әййәәмит-тәшриикый би каулиһи тәгалә: «үәҙкүруллааһә фии әййәәмим-мәгъдүүдәәт». Әгүүҙү билләәһи минә шәйтаанир-раҗиим: Йәә әййүһәл-ләҙиинә әәмәнүт-тәкуллааһә вәлтәңҙур нәфсүм-мәә каддәмәт лигаад. Вәттакуллааһә иннәллааһә хабиирум бимәә тәгъмәлүн.

Бәракә Ллаһу ләнә вә ләкум фил-Куръәнил-гаҙыйм, вә нәфәганәә вә ийәкүм бил-әәйәәти вәҙ-ҙикрилхәкиими вә әстәгъфируллаһәл-гаффәәра лии вә ләкүм вә лисәә'ири җәмәәгәтил-мүслимиинәл-хәәдыйриинә әҗмәгыйн. Иннәһү һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүс-сәмиигуль-гәлиим.

## Икенче хотбә

Әлхәмдү лилләәһи нәхмәдүһү вә нәстәгинүһү вә нәстәгъфируһү вә нү'минү биһи үә нәтәүәккәлү гәләйһи вә нәгүүҙү билләәһи мин шүруури әңфүсинәә вә мин сәййиәәти әгмәәлинәә мән-йәһдиһил-Лләәһү фәләә мүдыйллә ләһү вә мән-йүдълилһү фәләә һәәдийә ләһ. Вә әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһү вәхдәһү ләә шәриикә ләһү вә эшһәдү әннә Мүхәммәдән гәбдүһү вә расүүлүһ.

Иннәллаһә вә мәләәикәтәһүү йүсаллүүнә галән-нәбий. Йәә әййүһәл-ләӟиинә әәмәнү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимәә. Аллаһүммә салли галәә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәдин бигадәди мән салләә вә саам. Аллаһүммә салли галәә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәдин бигадәди мән кагәдә вә каам.

Саллии вә сәллим гәләйһи вә гәләә җәмиигиль-әнбийәә’и вәл-мүрсә-лиин. Вә галәә мәләәикәтикәл-мүкаррабиинә вә галәә әһли таагәтикә әҗмәгиин мин әһлис-сәмәәүәәти вәл-әрадыыйн. Вәрхәмнәә вәхшүрнәә мәгәһүм бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимин.

Аллаһүммә-гъфир лилмү’миниинә вәл-мү’минәәт, вәл-мүслимиинә, вәл-мүслимәәт, әл-әхъйәә’и минһүм вәл-әмьүәәт, иннәкә әнтә мүҗиибүд-дәгәүәәт вә мүнзилүл-бәракәәт, вә раафигуд-дәраҗәәт, вә каадыйүл-хәәҗәәт, бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин.

Аллаһүммәр-хәмил хуләфәә’әр-раашидиинә вәл-үмәрааа’әл-мәдый-нәл-ләӟиинә кадау билхәккы вә кәәнүү йәгъдилүүн. Аллаһүммән-сурмән нәсараддиинә вәһди мән хаӟәләддиин. Гибәәдәллааһ, иннәллааһә йәъ’мү-рү бил-гадли вәл-ихсәәни вә ийтәәәи ӟил-курбәә вә йәнһәә ганил-фәхш-әәәи вәл-мүнкәри вәл-бәгъйи йәгыйиӟукум ләгәлләкүм тәӟәккәрүүн. Үӟкүруллааһәл-галийййәл-гаӟыымәл-хәййәл-каййүүм, йәӟкүрүкүм вәш-күрүүһү йәзидкүм, вәстәгъфируүһүү йәгъфир ләкүм вә ләӟикруллааһи тәбәәракә вә тәгәәләә әгләә вә әүләә вә әгәззү вә әҗәллү вә әгӟамү вә әтәммү вә әкбәр.

## Корбан гаете хотбәсенең татарчага тәрҗемәсе

## Беренче хотбә

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Ширек һәм юкка чыгу кебек сыйфатлар каршында мөкатдәс булган Аллаһының Заты барча кимчелекләрдән пакьтер. Аллаһының матурлыгына һәм олуглыгына барлык мәхлүкълар дәлил булып тора.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Аллаһының үзенчәлегенә (Аның рәхмәтле Зат булганына) акыл ияләре хәйран калды.

Аның сыйфатларына төшенүдән тирән белем ияләре гаҗиз калды.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Мөэмин колларына карата айлар һәм көннәр аша юмартлык күрсәткән Зат барча кимчелекләрдән пакьтер. Бу көннәрдә байларга хаҗны, Олуг Аллаһы каршында изге йорт булган Кәгъбәтуллаһны тәваф кылырга йөкләгән Зат барча кимчелекләрдән пакьтер.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Үзенә тормыш иптәше алмаган, балалар тудырмаган, падишаһлыгында тиңдәше булмаган, кимсетелүдән коткаручы дустына мохтаҗ булмаган Аллаһыны мактыйбыз һәм Аңа тәкбир әйтегез. Аллаһыдан башка бернинди илаһ булмаганлыгы турында гуаһлык бирәм, Ул — бердәнбер, Аның тиңдәше юк, пәйгамбәребез Мөхәммәд – Аның колы һәм расүледер. Ул (Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм) – җәза алу көнендә гөнаһлылар өчен юмарт булучы һәм Олуг Аллаһының әмере белән шәфәгать кылучыдыр.

Аллаһы Тәгалә аңа, аның гаиләсенә, иң күркәм әхлак һәм иң яхшы әхвәл белән сыйфатланган сәхабәләренә салават һәм сәлам ирештерсен.

Әй кешеләр! Белегез ки, сезнең бу (бәйрәм) көнегез — хөрмәтле көндер, байлар һәм ярлылар өчен юмартлык бәйрәмедер, бу көннең кадере халыклар өчен бөектер, бу көнне изгелек, ихласлылык, туганлык мөнәсәбәтләрен ныгыту аша бөекләгез. Чынбарлыкта, безгә Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә корбанны: «Корбан чал!» – дип йөкләде. Шулай ук Үзенең хәлиленә (Ибраһим галәйһиссәламгә) иң танылган баласын корбан итәргә боерган. Якын фәрештә (Җәбраил галәйһиссәлам) аша җәннәттән куй бирелгән. Иң могтәбәр сүзгә таянсак, фәкыйрь корбан чалырга тиеш түгел. Эре терлек – җиде кешедән, сарык вә кәҗә бер кешедән йөкләмәне төшерә. Могтәбәр мәзһәб буенча, сукыр, аксак, колагы киселгән, җенес әгъзасы өзелгән, мөгезе сынган һәм корбан чалу урынына үзе бара алмаслык дәрәҗәдә хәлсез булган терлек корбанга ярамас.

Корбаннарыгызны иң яхшы малларыгыздан чалыгыз, һәм Аллаһы Расүленең әмеренә буйсынып, корбаннарыгызны хөрмәт итегез (чалганда йомшаклык күрсәтегез). Аллаһының Расүле (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) болай дип әйткән: «Корбанлыкларыгызны хөрмәт итегез, ник дисәгез, алар – Сират күперендә сезнең утырып чыга торган хайваннарыгыздыр». Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә безгә фарыз намазларыннан соң тәкбир тәшрикъне Гарәфә көненең иртәнге намазыннан алып, Тәшрикъ көненең ахырына кадәр Үзе йөкләгән: «Саналган көннәрдә Аллаһыны искә алыгыз», – дигән. Таш белән атылган шәйтаннан Аллаһыга сыенам. Рәхимле, Шәфкатьле Аллаһы исеме белән.

Аллаһы Коръәндә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَلْتَنظُرْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ لِغَدٍ ۖ وَاتَّقُوا اللَّهَ ۚ إِنَّ اللَّهَ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ ﴿١٨﴾

**«Әй иман китергән кешеләр! Аллаһыдан куркыгыз һәм һәр җан иясе иртәгәсе көн өчен нәрсә әзерләгәнен күрсен. Аллаһыдан куркыгыз, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә эшләрегездән хәбәрдар».**

«Хәшер / Сөреп Чыгару», 59:18

Аллаһы безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Гөнаһларны гафу итүче Аллаһы каршында үзем һәм сезнең өчен, шулай ук башка мөселман җәмәгатьләренең бөтенесе өчен, истигъфар кылам (ярлыкау сорыйм). Чынбарлыкта Ул (Аллаһы) — Гафу итүче, Рәхимле, Данлы, Юмартлык иясе, Ишетүче һәм Белүче.

## Икенче хотбә

Аллаһыга мактау булсын, Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, истигъфар кылабыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Нәфесләребезнең начарлыгыннан һәм гамәлләребезнең кабахәтлегеннән Аллаһыга сыенабыз. Кемгә Аллаһы һидаять бирсә — аны адаштыручы булмас, кемне адаштырса — аңа беркем дә һидаять бирә алмас. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд Аның колы һәм хак Расүле булуына гуаһлык бирәм.

«Шик юктыр ки: Аллаһы да, фәрештәләр дә Пәйгамбәргә күп салаватлар әйтә. Әй, иман китергән адәмнәр, сез дә аңа салават әйтегез һәм сәламнәрегезне күндерегез».

Аллаһым, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гаиләсенә намаз укучыларның һәм ураза тотучыларның саны кадәр салават ирештер.

Аллаһым, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гаиләсенә утырган һәм басып торган кемсәләрнең саны кадәр салават ирештер.

Аңа салават һәм сәлам ирештер, шулай ук бөтен пәйгамбәрләргә һәм илчеләргә (расүлләргә), якын булган фәрештәләреңә, шулай ук күкләрдә һәм җирләрдә яшәүче Сиңа итагать әһелләренә салават һәм сәлам ирештер. Шулай ук, безгә карата рәхимле бул һәм безне алар белән бергә Мәхшәр мәйданында җый. Синең рәхмәтең белән, йә, рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

Аллаһым, мәгъфирәтең белән мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, аларның исәннәрен дә, үлгәннәрен дә гафу ит. Чынбарлыкта, Син – догаларны кабул итүче, бәрәкәт иңдерүче, дәрәҗәләрне күтәрүче, хаҗәтләребезне үтәүче. Синең рәхмәтең белән, йә, рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

Аллаһым, тугры хәлифәләргә һәм хак белән казыйлык иткән вә гаделлек кыла торган булып үткән әмирләргә карата рәхимле бул.

Аллаһым, кем дингә ярдәм итә, шуңа ярдәм ит һәм кем динне кимсетә, шуңа һидаять бир.

Аллаһының коллары! Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә гаделлек, ихсан, якыннар белән йөрешүне әмер итә һәм фәхешлекне, кире кагылган нәрсәләрне, чиктән чыгуны тыя. Аллаһы сезне вәгазьли, шаять, сез искә алырсыз.

Бөек, Олуг, Тере, Уяу булган Аллаһыны зикер итегез – Ул сезне зикер итәр, Аңа карата шөкер итегез – Ул арттырыр. Аның каршында тәүбә-истигъфар кылыгыз – Ул мәгъфирәте белән гафу итәр. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләне зикер итү – иң бөек, иң гүзәл, иң олуг, иң җәләләтле, иң камил, иң зур гамәл.

*6 июнь вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Корбан гаете вәгазе

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Күңелләребезне иман нуры белән нурландырган Аллаһы Тәгаләгә мактауларыбыз һәм шөкраналарыбыз булса иде. Бөтен пәйгамбәрләрнең имамы булган, безне бу дөньяда һәм ахирәттә бәхетле булырга өйрәткән сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Хөрмәтле мөселманнар! Елга бер мәртәбә була торган бөек бәйрәмебез – изге Корбан гаете – барчаларыбызга мөбарәк һәм хәерле булсын! Аллаһы Тәгалә ил-көннәребезгә иминлек, күңелләребезгә тәүфикъ, җаннарыбызга тынычлык, тәннәребезгә исәнлек-саулык биреп, һәркайсыбызга хәерле һәм бәрәкәтле тормышлар насыйп итсә иде! Мөкатдәс Корбан бәйрәме көннәрендә ихлас күңелдән изге гамәл-гыйбадәтләр кылып, корбаннарыбызны чалып Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына барчабызга да ирешергә насыйп булса иде!

Һәркайсыбыздан догага мохтаҗ, бу дөньядан иманлы булып киткән барлык мәрхүмнәребезнең һәм мәрхүмәләребезнең гөнаһларын, хатакимчелекләрен Аллаһы Раббыбыз гафу итеп, рухларын шат кылса иде.

Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә ышанып, Аның кушканнарын үтәп, тыйган гамәләреннән тыелып яшәү кешенең төп вазифасы булып тора. Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә кешене бу дөньяга

нәкъ менә шуның өчен җибәрде дә. Һәрбер мөселман үзенең Раббысына омтылырга, Аны искә алырга, һәрбер гамәлне Аның ризалыгы өчен кылырга тиеш, чөнки ул бары тик Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте аркасында яши. Кайвакыт кеше үз Раббысын онытып, хаталар, гөнаһлы гамәлләр кыла, үзен һәлакәт чокырына ташлый, калебен каралта. Шушы гөнаһлардан, хатакимчелекләрдән пакьләнү, Аллаһы Тәгаләгә якынаю юлларының берсе – хаҗ гыйбадәте. Бөтен Ислам галимнәренең уртак фикере буенча, хаҗ гыйбадәте һәрбер хәлле мөселман өчен фарыз (тиешле) гамәл булып тора. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَلِلّٰهِ عَلَى النَّاسِ حِجُّ الْبَيْتِ مَنِ اسْتَطَاعَ إِلَيْهِ سَبِيلاً

**«Юл үтеп аңа** [җитәргә] **көч тапкан кешеләр Аллаһы өчен** [әл-Харам мәчете булган] **Бәйткә хаҗ кылырга тиеш».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:97

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер мөбарәк хәдисендә болай дип әйткән: «Әгәр берәү хаҗ кылып, бозыклык кылмаса, өенә анасы тудырган көндәге кебек гөнаһсыз булып кайтыр» [1].

Бүген, ягъни зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көнендә, хаҗилар хаҗ гыйбадәтенең төп гамәлләрен тәмамлап, ихлас күңелләре белән Кәгъбәтуллаһка юнәлеп, тәлбия сүзләрен әйтәләр. Газиз дин кардәшләрем! Төрле илләрдә яшәүче ничәшәр йөз миллион мөселманнар кебек, без дә бүген изге Корбан гаетенә шатланып, тәһарәт-госелләр алып, пакь матур киемнәр киеп, хушбуйлар сөртеп, тәкбирләр әйтеп, Аллаһы йортына – мәчетләребезгә – җыелдык.

«Корбан» сүзе нәрсәне аңлата соң? Ул гарәпчәдән «якынаю», «якын булу» дип тәрҗемә ителә. Без бу мөбарәк бәйрәмдә гает намазын укып, Аллаһы ризалыгы өчен корбаннар чалып, игелекле гамәлләр кылып, сафлана-

[1] Имам әл-Бохари, Мөслим, Нәсәи.

быз һәм Аллаһының рәхмәтенә якынаябыз, шуңа күрә бу олы бәйрәмебезне шатланып каршы алабыз.

Корбан гаете барлык мөселманнарны берләштерә, якынайта, аларның күңелләре сөю, хөрмәт, бер-береңә миһербанлык һәм шәфкать хисләре белән тула. Бу мөбарәк көнне нәфрәт һәм ачулар юкка чыга, дошманлык һәм үпкә хисләре бетә.

Хөрмәтле мөселманнар! Аллаһының рәхмәтенә якынайта торган изге Корбан бәйрәме тирән мәгънәгә ия. Гарәпчә бу бәйрәм «Гыйд әл-әдха» дип атала. «Әдха» сүзе корбан чалу дигәнне аңлата. Мәгълүм булганча, корбан чалу йоласы безгә Ибраһим галәйһиссәлам белән Исмәгыйль галәйһиссәламнән калган. Корбан бәйрәме тарихын искә төшерик.

Ибраһим пәйгамбәр галәйһиссәламнең озак еллар баласы булмаган. Аллаһының рәхмәте белән аның улы туган, балага Исмәгыйль исеме кушылган. Берничә ел үткәч, Ибраһим галәйһиссәлам Мәккә шәһәрендә булган вакытта, төшләр күрә башлаган. Ул төшләрдә Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламгә улы Исмәгыйльне корбан итеп чалырга кушкан…

Әлбәттә, Аллаһы Тәгалә кеше канын түгүче түгел, шул рәвешле Ул бары Ибраһим пәйгамбәрне сынаган, Исмәгыйль галәйһиссәлам үзе дә сынатмаган. Әтисе аны корбан итеп чалырга алып барганда, шайтан аны котыртып маташкан: «Сине атаң кунакка алып бармый бит, ул сине чалырга алып бара бит», – дигән.

Яшь кенә Исмәгыйльнең иманы бик нык була. Ул бу хәлдә: «Әгәр бу Аллаһының әмере булса, без аны үтәячәкбез», – дип, шайтанны ташлар атып куып җибәргән. Ибраһим пәйгамбәр белән улы Исмәгыйль галәйһимәссәлам арасында булган сөйләшүне Аллаһы Тәгалә Коръәндә китерә:

فَلَمَّا بَلَغَ مَعَهُ السَّعْيَ قَالَ يَا بُنَيَّ إِنِّي أَرَىٰ فِي الْمَنَامِ أَنِّي أَذْبَحُكَ فَانظُرْ مَاذَا تَرَىٰ ۚ قَالَ يَا أَبَتِ افْعَلْ مَا تُؤْمَرُ ۖ سَتَجِدُنِي إِن شَاءَ اللَّهُ مِنَ الصَّابِرِينَ ﴿١٠٢﴾

**«Ул аның белән бергә** [эшләрендә] **тырышлык куюга** [мөмкинлек биргән унөч яшьләргә] **җиткәч** [атасы аңа]**: «Ий улым! Һичшиксез, мин** [берничә төн рәттән] **төшемдә сине чалганымны күрдем. Син ни уйлаганыңны кара», – диде. Ул: «Ий әтием! Сиңа әмер ителгән нәрсәне** [һич уйлап тормыйча] **үтә. ИншәАллаһ, мине сабыр итүчеләрдән табачаксың», – диде».**

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:102

Уйлап карагыз әле, җәмәгать, Исмәгыйль галәйһиссәламгә ул вакытта нибары 13 яшь кенә була! Ибраһим галәйһиссәлам улын бугазлыйм дип торганда, Җәбраил фәрештә галәйһиссәлам килеп, аны бугазлатмаган, Аллаһы Тәгаләнең әмере белән улы урынына бер куй (сарык) китереп, шуны корбан итеп чалырга кушкан.

Җәбраил фәрештә шушы куйны китергәч: «Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр», – дип әйткән. Ибраһим галәйһиссәлам тәкбирне ишеткәч: «Ләә иләһә илләллааһу вәллаһу әкбәр», – дип әйткән, һәм аннан соң Исмәгыйль галәйһиссәлам өстәгән: «Аллаһу әкбәр вә лилләәһил хәмд». Бүгенге көндә мөселманнар бу сүзләрне Гарәфә көнендә һәм Корбан гаете көннәрендә һәрбер фарыз намаздан соң кабатлыйлар.

Ибраһим галәйһиссәлам улын азат итеп, Җәбраил фәрештә алып килгән куйны чалган. Шул вакыттан бирле бу йола безгә бәйрәм булып кала.

Без корбан чалганда шуны аңларга тиеш: Аллаһы Тәгаләгә корбанның ите дә, каны да кирәк түгел, Аңа безнең тәкъвалыгыбыз гына ирешә. Бу хакта Аллаһы Раббыбыз Коръәндә Үзе әйтә:

لَن يَنَالَ اللَّهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَاؤُهَا وَلَكِن يَنَالُهُ التَّقْوَى

**«Аларның итләре дә, каннары да Аллаһыга ирешәчәк түгел. Аңа сездән бары тәкъвалыгыгыз гына ирешә».**

«Әл-Хаҗ», 22:37

Тәкъва булган, Аллаһыны чын күңелдән сөйгән кеше корбанны Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен чалып, гаиләсен, килгән кунакларын һәм күршеләрен, фәкыйрьләрне һәм мескеннәрне хөрмәт итә, аларның күңелләрен күтәрә. Шулай итеп, ул Аллаһының ризалыгына ирештерә торган гамәлләр кыла. Изге Коръәндә болай дип әйтелгән:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَابْتَغُوا إِلَيْهِ الْوَسِيلَةَ وَجَاهِدُوا فِي سَبِيلِهِ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ ﴿٣٥﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Аллаһыдан куркыгыз** [һәм Аның колларын җәфаламагыз], [әмерләрен тоту, тыюларыннан качу һәм Аның дусларын сөю кебек гамәлләр белән] **Аңа якынаю юлларын эзләгез һәм Аның юлында тырышлык куегыз, бәлки, сез** [дөньяда һәм ахирәттә бәхеткә һәм] **уңышка ирешә алырсыз».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:35

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Әгәр без Аллаһының газабыннан котылырга һәм Аның рәхмәтенә ирешергә, бәхетле булырга телибез икән, алдагы аятьтә әйтелгәнчә, Ислам юлында тырышырга, ягъни Корбан бәйрәме көннәрендә генә түгел, ә һәр көнне гөнаһлардан сакланып, Аллаһыга шөкрана кылып, күбрәк игелекле гамәлләр эшләп яшәргә тиешбез.

Аллаһы Тәгалә «Әл-Бәкара» сүрәсенең 29–30 нчы аятьләрендә болай дип әйткән:

هُوَ الَّذِي خَلَقَ لَكُم مَّا فِي الْأَرْضِ جَمِيعًا ثُمَّ اسْتَوَىٰ إِلَى السَّمَاءِ فَسَوَّاهُنَّ سَبْعَ سَمَاوَاتٍ ۚ وَهُوَ بِكُلِّ شَيْءٍ عَلِيمٌ ﴿٢٩﴾

وَإِذْ قَالَ رَبُّكَ لِلْمَلَائِكَةِ إِنِّي جَاعِلٌ فِي الْأَرْضِ خَلِيفَةً ۖ قَالُوا أَتَجْعَلُ فِيهَا مَن يُفْسِدُ فِيهَا وَيَسْفِكُ الدِّمَاءَ وَنَحْنُ نُسَبِّحُ بِحَمْدِكَ وَنُقَدِّسُ لَكَ ۖ قَالَ إِنِّي أَعْلَمُ مَا لَا تَعْلَمُونَ ﴿٣٠﴾

**«Ул** [Аллаһы] **Җирдә булганнарның бөтенесен сезнең** [мәнфәгатегез] **өчен яратты, шуннан** [Үзенең Кодрәте белән] **күкне** [яратуга күчте]**. Һәм аны** [бернинди кимчелексез] **җиде** [кат] **күк рәвешенә китерде. Ул –** [һәрнәрсәне] **Белүче.**

**Менә Раббың фәрештәләргә: «Һичшиксез, Мин җирдә хәлифә** [итеп Адәм галәйһиссәламне] **яратачакмын!» – дип әйткәч, алар** [каршы төшү максаты белән түгел, ә хикмәтен белер өчен]**: «Әллә җирдә бозыклык кылучыны һәм кан коючыны яратачаксыңмы? Без бит һәрвакыт Сиңа мактау белән тәсбих әйтәбез, олылыйбыз», – диделәр. Ул: «Һичшиксез, Мин сез белмәгәннәрне беләм!» – диде».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:29–30

Шул рәвешле, Аллаһы Раббыбыз адәм балаларын күркәм сурәттә яратып, акыл биреп, барлык мәхлуклардан өстен кылган. Аллаһы Тәгалә җир өстендә һәм астында булган байлыкларны, нигъмәтләрне, диңгезләрдәге хисапсыз күп балыкларны, төрле мәхлукларны безгә буйсынучы итеп яраткан. Безгә, адәм балаларына, бернинди мәхлукка бирелмәгән хәлифә дәрәҗәсе бирелгән. Инде Аллаһы Раббыбыз безне шундый олы нигъмәтләр белән бүләкләгәннән соң, безгә зур гына вазифалар, бурычлар йөкләгән. Коръәни Кәримнең «Әт-Тәхрим» сүрәсенең 6 нчы аятендә адәмнәр өстендәге олы

вазифаларның кайберләре искә алына. Шул вазифаларны үтәмәүчеләр каты газапка дучар булачаклары турында белдерелә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا قُوا أَنفُسَكُمْ وَأَهْلِيكُمْ نَارًا وَقُودُهَا النَّاسُ وَالْحِجَارَةُ

**«Ий иман китерүчеләр!** [Әмерләрне тотып, тыюлардан тыелып] **Үзүзләрегезне һәм гаиләләрегезне уттан саклагыз,** [башка утларның ягулыгы утын булса] **аның ягулыгы** [кяфер] **кешеләр һәм** [бик тиз кабынып, бик күп яндыра торган күкерт] **ташлар».**

«Әт-Тәхрим / Тыю», 66:6

Шулай итеп, Аллаһы Раббыбыз бу аять белән безгә белдерәдер ки, үзебезне һәм гаиләбезне дөнья, ахирәт бәхетсезлегенә сәбәп булган начар эшләрдән тыеп, җәһәннәм газабыннан сакларга куша. Өстебездә булган зур бурычларыбыз хакында Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән: «Ий бәндә, синең өстеңдә Раббыңның хакы, нәфесең һәм әгъзаларыңның хакы бар һәм гаиләңнең хакы бар, һәрбер хак иясенә хакларын бир, вазифаңны (бурычларыңны) үтә».

Һәм, хәдистә беренче булып аталган, һәр адәм баласының тормышындагы төп бурычы ул – Аллаһы Тәгаләнең хакларын хаклау, Аның каршында булган бурычларыбызны үтәү, ягъни дөньяны, бөтен галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһыны тану, Ул биргән барлык нигъмәтләргә шөкрана кылып, һәрвакыт, һәр җирдә Аллаһы хозурына барып, хисап бирәчәгебезне истә тоту.

Бөек Раббыбыз әйтә:

وَلِلَّهِ غَيْبُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ ۚ وَمَا أَمْرُ السَّاعَةِ إِلَّا كَلَمْحِ الْبَصَرِ أَوْ هُوَ
أَقْرَبُ ۚ إِنَّ اللَّهَ عَلَىٰ كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ ﴿٧٧﴾ وَاللَّهُ أَخْرَجَكُم مِّن بُطُونِ
أُمَّهَاتِكُمْ لَا تَعْلَمُونَ شَيْئًا وَجَعَلَ لَكُمُ السَّمْعَ وَالْأَبْصَارَ وَالْأَفْئِدَةَ ۙ لَعَلَّكُمْ
تَشْكُرُونَ ﴿٧٨﴾

**«Күкләрдәге һәм җирдәге гаиб – Аллаһыныкы гына. Сәгатьнең** [Кыямәтнең кисәктән] **җитүе – күз ачып йомганчы яки тагын да якынрак. Һичшиксез, Аллаһы – һәрнәрсәгә Кодрәтле.**

**Аллаһы сезне берни белмәгән хәлегездә аналарыгызның карыннарыннан чыгарды, сезгә колаклар, күзләр һәм** [аң-зиһен үзәге булган] **күңелләр бирде. Бәлки, сез** [үзегезгә насыйп булган нигъмәтләрнең зурлыгын аңлап, аларның бәясен белерсез һәм] **шөкер итәрсез».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:77–78

Газиз дин кардәшләрем! Вәгазь ахырында бер риваять сөйләп китәсем килә.

Бөек галим Җөнәйд әл-Багдадига (Аллаһы аны Үзенең рәхмәтеннән аермаса иде) 7 яшь булганда, абыйсы Сәрий әс-Сәкати аны үзе белән хаҗ гыйбадәтен кылырга алып барган. Әл-Харам мәчете эчендә, ягъни Кәгъбәтуллаһ янында, төрле мәсьәләләр буенча сөйләшүләр барган, шуларның берсе шөкрана кылу турында булган. Анда катнашкан һәр шәех бу хакта үз белем-тәҗрибәләре белән уртаклашкан. Сәрий әс-Сәкати Җөнәйдкә борылып, аңа шөкрана турында үз фикерен белдертергә тәкъдим иткән. Бераз уйлагач, 7 яшьлек Җөнәйд түбәндәге гаҗәеп матур җавабын биргән: «Шөкрана кылу ул – Аллаһы Тәгалә каршында гөнаһлы булмау, Аның нигъмәтләрен файдаланып, шулар белән гөнаһ кылмау».

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Бу җаваптан күренгәнчә, Аллаһыга шөкрана кылу, Аңа рәхмәт әйтү намаз уку, ураза тоту, Коръән уку кебек гыйбадәтләр белән генә чикләнми. Без Аллаһы Раббыбыз биргән әгъзаларыбыз белән дә гөнаһ эшләмәскә тиеш. Күзебезне – харам булган нәрсәләрдән, телебезне гайбәттән, ялганнан, яла ягудан, буш сүзләрдән саклыйк. Телләребез белән күбрәк Аллаһыны искә алыйк, файдалы, дөрес сүзләр сөйлик. Карыныбызны харам ризыклардан, кулларыбызны гөнаһлы гамәлләрдән, аякларыбызны Аллаһының ачуын китерә торган җирләргә ба-

рудан саклыйк. Хәдис-шәрифтә болай диелгән: «Файдасыз эшләрдән качу – яхшы мөселманның билгесе»[1].

Аллаһы Тәгалә барчабызга да ихлас шөкрана кылучылардан булырга, күңелләребездә булган барлык изге ниятләребезгә, максатларыбызга ирешергә, чалыначак корбаннарыбызның бәрәкәтен күрергә, бу дөньяда һәм ахирәт томышында да бәхетле булырга насыйп итсә иде! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Нияз хәзрәт Сабиров,*

*Казанның «Апанай» мәчете имам-хатыйбы*

1 Имам әт-Тирмизи.

*6 июнь вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Кая югалдык шул арада?

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, мөселман өммәтенә карата без «әһле Сөннәт вәл-җәмәга» дигән сүзләрне кулланабыз. Бу атама нәрсәне аңлата? «Әһле» ул – кешеләр, әһелләр, ягъни без. «Сөннәт» – инде пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышы, аның әйткән сүзләре, кылган гамәлләре, ә «җәмәга» – җәмәгать сүзеннән, ягъни күпчелек кешеләр төшенчәсе. Димәк, без, мөселманнар, – Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең Сөннәте һәм килешүдә яшәүче халык.

Бүген мөселманнарның төрлеләре бар: намаз укучылар һәм, кызганыч, әлегә укымаучылар, ураза тотучылар һәм тотмаучылар, корбан чалучылар һәм чалмаучылар һәм башкалар. Әмма ничек кенә булмасын, мөселманнарның күпчелеге намазын укый, уразасын тота, корбанын чала, гомрәсен, хаҗын кыла. Һәм, аерып әйткәндә, күпчелек мөселман халкы нишли? Без бүген кайда җыелыштык? Әйе, мәчеттә. Күпчелек мөселман халкы үзенең калебен мәчеткә бәйли.

Газиз дин кардәшләрем, бүген, Аллаһы теләсә, без мәчеткә йөрү, гает намазларында, җомгаларда һәм һәрдаим тормышыбызны мәчеткә бәйләү хакында сөйләшербез.

Мәчетләр динебездә бик зур әһәмияткә ия. Аллаһы Тәгалә аларны Коръәни Кәримдә 18 тапкыр искә ала. Аларны хөрмәт итәргә һәм дәрәҗәләрен аңларга кирәк.

Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мәчетләргә кагылышлы берничә хәдис-шәрифен карап китик:

1. Мөэминнәрнең анасы Гайшә радыяллаһу ганһә болай дип хәбәр итә: «Расүлуллаһ галәйһиссәлам (кешеләргә) үз авылларында мәчетләр (гыйбадәтханәләр) төзергә һәм аларны (мәчетләрне) чисталыкта тотып, шул изге урыннарда гыйбадәт кылырга кушкан».

2. Мәшһүр сәхабә Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребезнең мондый сүзләрен тапшыра: «Иң зур савапка мәчетләрдән ерак яшүчеләр ия». Бу хәдиснең мәгънәсе нинди? Ягъни мәчеттән ераграк яшәгән мөселман анда барып җитү өчен күбрәк ара уза, күбрәк вакытын сарыф итә. Шушы узган юл өчен ул мәчеткә якын яшәгән кешедән күбрәк саваплар ала. Шулай ук мәчеткә ерактан бер намазга килгән кеше, икенче намазга кадәр китмичә, аны монда көтеп утырырга мөмкин. Аның мәчеттә уздырган шушы вакыты да әҗер-савапсыз калмый.

3. Янә хәзрәти Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе тапшыра: «Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Аллаһы Тәгаләнең җирдә иң яраткан урыннары – Аның мәчетләре, ә Аллаһы иң яратмаган урыннар ул – базарлар». Бу хәдистән Раббыбыз өчен җир йөзендәге иң яхшы булган, Ул иң яраткан урыннарның мәчетләр булуын күрәбез, чөнки анда намазлар укыла, Аллаһы зикер ителә (искә алына), файдалы гыйлем таратыла, кешеләргә динебездә әһәмиятле булган бар нәрсәләр өйрәтелә.

4. Бер хәдисендә Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһының Гареше күләгәсеннән башка күләгә төшмәгән көнне (ягъни Кыямәт көнендә) җиде кеше күләгә астында булачак», – дип, шушы җиде төрле кешене саный. Һәм аларның берсе ул – «йөрәге мәчетләргә бәйләнгән кеше».

Элекке вакытларда мәчетләребез бөтен мәхәллә өчен төп урын, үзәк булып торган. Аларда гыйбадәт кылынган, мәхәллә тормышына кагылган зур җыелышлар узган, мохтаҗларга ризык таратылган, сугышлар булса, халык мәчеттә дога укып чыгып китә торган булган, беренче белем алу урыны да

мәчет булган. Бүген инде мәчетләр бездә күбрәк гыйбадәт йортлары гына булып калды. Әмма, хәзер без кабат аларның эшен киңәйтергә тырышабыз, Раббыбыз күбрәк дәресләр, файдалы чаралар уздырырга насыйп итсен.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, мәчеттә уздырган вакытыбыз нәфел игътикәф вакыты булып санала, монда үткәргән һәр минутыбыз өчен Аллаһыдан савап языла, монда күңелләребез тынычлана. Игътикәф төшенчәсен кыска гына карап китик. Ул ике төрле була. Беренчесе – сөннәт игътикәф. Ул Рамазан аеның соңгы 10 көнен Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен мәчеттә уздыру. Игътикәф кылучы ир-атлар бар көнен мәчеттә уздыра, монда йоклый, авыз ача, күпчелек вакытын гыйбадәттә уздыра, намазлар укый. Игътикәфнең максаты – дөнья эшләреннән ерак тору, гыйбадәткә бирелеп, Раббыңа якынаю. Мондый игътикәфне һәр кеше дә башкара алмый, безнең гаиләләребез, эшләребез бар.

Әмма игътикәфнең икенче төре бар ул – нәфел игътикәф. Нәфел сүзен без нәфел ураза, нәфел намазлар дигәннән беләбез. Ул «өстәмә» дигәнне аңлата, ягъни ул фарыз да, сөннәт тә түгел, кеше үзе теләгәнгә күрә өстәмә гыйбадәт кылып, өстәмә савапларга ирешә. Шулай булгач, нәфел игътикәф ул – Аллаһы ризалыгы өчен мәчеттә күпмедер вакыт уздыру. Аның озынлыгы да, шул айның шул көнендә кылына дигән чикләре дә юк, шуңа ул нәфел дә. Мәсәлән, мәчет яныннан узганда, мәчеткә кереп, дога кылып чыгыйм әле дип, 3 минутка мәчеткә кереп торсагыз, ниятегез өчен игътикәф савабы аласыз. Димәк, газиз дин кардәшләрем, мәчеттә 5 минут, 10 минут, ярты яки бер сәгать – хәлебездән килгәнчә, уздырган вакытыбыз саваплы булыр, иншәАллаһ.

Без укыган хәдисләрдән мәчетләрнең Аллаһы Тәгалә һәм Аның Илчесе каршында нинди зур, бөек мәгънәгә ия булуын күрдек.

Шулай да, бүген бездә мәчетләр саны күп булуга карамастан, аларның ачык булуына карамастан, без нәрсә күрәбез? Кызганыч, күпчелек мәчетләребездә көндәлек 5 вакыт намазга беренче рәт көчкә тула.

Ни өчен без гаетләргә сафларны тутырып, оныкларыбызны, улларыбызны җитәкләп, башларына түбәтәй кигезеп, мәчеткә алып барабыз, ә шул ук ир-атларга фарыз булып торган җомгаларга күзебезне йомабыз?

Җомга намазы хакында Аллаһы Тәгалә «Җомга» сүрәсенең 9 нчы аятендә болай ди:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِذَا نُودِيَ لِلصَّلَاةِ مِن يَوْمِ الْجُمُعَةِ فَاسْعَوْا إِلَىٰ ذِكْرِ اللَّهِ وَذَرُوا الْبَيْعَ ۚ ذَٰلِكُمْ خَيْرٌ لَّكُمْ إِن كُنتُمْ تَعْلَمُونَ ﴿٩﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Җомга көнне намаз өчен** [азан әйтелеп] **чакырылгач, Аллаһыны искә алырга ашыгыгыз һәм сәүдәне ташлагыз. Бу –** [сәүдәнең вакытлы файдасыннан] **сезнең өчен яхшырак. Әгәр дә белсәгез иде** [мәңгелек алыш-бирешне сайлар идегез]**».**

«Җомга», 62:9

Хөрмәтле дин кардәшләрем, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Сезнең берегез дә үз кардәшенә үз-үзенә теләгәнне теләмичә, камил иман иясе булмас», – дип әйткән. Ягъни без үзебезгә гадәттә ни телибез? Дөрес, иң яхшысын, иң дәрәҗәлесен, иң хәерлесен генә телибез. Димәк, кеше үз мөселман кардәшенә үзенә теләгәнне теләми икән, ул тулаем рәвештә, мөкәммәл рәвештә иман китерми ди сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәлам.

Ни өчен бу хәдисне искә алдым? Мәчеткә килеп, җәмәгать белән намаз уку җәмәгатьсез укылган намаздан 27 мәртәбә саваплырак. Алда әйтелгәнчә, мәчеткә йөрүчеләр Кыямәт көнендә күләгәдә булачаклар. Без боларны үзебезгә телибезме? Телибез, әлбәттә. Ә ни өчен соң без, мөселман дусларыбызны, туганнарыбызны, бергә эшләгән хезмәттәшләребезне җомга саен үгетләп, исләренә төшереп: «Әйдә бүген җомгага бергә барабыз», – дип әйтмибез, мәчетләребезне тутырмыйбыз соң?

Башка бер хәдистә: «Яхшылык турында искә төшерүче яхшылыкны кылучы кебек савап ала», – диелгән. Димәк, әгәр дә без берәр мөселман

кардәшебезне мәчеткә чакырабыз икән, ул кеше мәчеткә килсә, без үзебез өчен дә, аның өчен дә савап алабыз.

Мөхтәрәм мөселман кардәшләрем, дусларым! Ихлас күңелемнән Аллаһыдан шушы вәгаземнең күңелләрегезгә үтеп керүен сорыйм.

Кардәшләрем, без барыбыз да интернеттан күреп тордык: Фәләстыйнда халык җимерелеп беткән, келәмсез, салкын, манаралары ауган мәчетләргә җыелып, куркыныч янаганда да җәмәгать белән намаз укып торды. Ә безгә җып-җылы булган, уңайлы тәһарәтханәле, матур келәмле, чиста, якты булган мәчетләрне буш калдыру гөнаһ булмасмы?!

Аллаһы Тәгаләнең йортлары – мәчетләр – безнең өчен һәрчак ачык, җылы һәм якты. Барыбыз өчен дога белән бетерәсем килә. Кулларыгызны күтәрегез: «Йә Раббым Аллаһы, безнең мәчетләребезне һәрчак саклап тот, безнең юлларыбызны мәчеткә илтә торган итеп яса, калебләребезне мәчетләргә бәйлә һәм гөнаһларыбызны гафу ит, ярлыкагыл!» Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Галим хәзрәт Хисаметдинов,*
*Россиядагы Ислам банклары белән үзара эшләр*
*«АПМ Финанс» оешмасының ислам финанс*
*продуктларын үстерү бүлеге җитәкчесе*

*13 июнь вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аеның 17 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Рух ачлыгы

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне, безне бар кылган, калебләребезне иман нуры белән нурландырып, безне мөселман өммәтеннән кылган Рәхмәтле һәм Рәхимле Раббыбыз Аллаһы Тәгаләгә барча мактауларыбыз, олыглауларыбыз булсын! Галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән соңгы пәйгамбәр, Аллаһының хак илчесе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салаватларыбыз ирешсә иде.

Газиз дин кардәшләрем! Вәгазебезне Ибне Гатаулла әс-Сикәндәри исемле галимнең мондый сүзләре белән башлыйсым килә: «Аллаһыга якынаер өчен, Аның никадәр безгә якын булуын аңларга кирәк», – дип әйткән ул.

Безнең, мөселманнарның, беребезнең дә Раббыбыз бу дөньяны, безне юктан бар кылуында, Аллаһы Тәгаләнең һәр җирдә, һәр мизгелдә булып торган бар хәлләр, күренешләрнең белеп торуында һич шигебез юк. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә һәрберебезнең, һәр кешенең күңелендә һәм уенда булган әйберләрне белеп тора. Ул безнең бәхетле, шатлыклы мизгелләребез турында да, башыбызга кайгы, газап, курку төшкән вакытлар турында да белеп тора.

Коръәни Кәримдә болай диелгән:

وَلَقَدْ خَلَقْنَا الْإِنسَانَ وَنَعْلَمُ مَا تُوَسْوِسُ بِهِ نَفْسُهُ ۖ وَنَحْنُ أَقْرَبُ إِلَيْهِ مِنْ حَبْلِ الْوَرِيدِ ﴿١٦﴾

**«Кешене Без яраттык һәм нәфесенең аңа нәрсәләр пышылдаганын беләбез. Без** [гыйлемебез белән] **аңа муен тамырларыннан да якынрак».**

«Каф», 50:16

Шушы аятьтә Аллаһы Тәгалә Үзе үк һәр кешегә якын булуы турында әйтеп китә. Газиз дин кардәшләрем, бу якынлык нинди соң, без аны ничек күрәбез, ничек аңларга тиешбез?

Беренчедән, Аллаһы Тәгалә – бар булган әйберләрне яратучы, барлыкка китерүче. Ул зур-зур океаннарны, таулар, вулканнарны, һәр үсемлекне, җанварны, микробларны, күзәнәкләрне... – һәммәсен Ул бар кылучы. Шуңа күрә безнең әйләнә-тирәдәге бар хәлләр, вакыйгалар Аның күзәтүе астында. Безнең тормышыбызның һәр мизгеле, секунды, һәр сулышыбыз, тәнебезнең һәр хәрәкәте – боларның барысына да көч һәм рөхсәт бирүче – Аллаһы Тәгалә генә. Ул безне кайдандыр күзәтеп торучы гына түгел, юк, Ул – безнең тормышларыбызга юнәлеш биреп, көч биреп торучы Зат.

Икенчедән, газиз дин кардәшләрем, шуны онытмасак иде – Аллаһы Тәгалә бар нәрсәдән дә хәбәрдар, белеп торучы. Аңа безнең һәр уебыз да, теләгебез дә, хисебез, күңелләребездәге тойгылар да билгеле. Без башкалардан яшерергә тырышкан уйларыбызны Аллаһы Раббыбыздан яшерә алмыйбыз. Әгәр без шушыны аңласак, Аңа билгеле булмаган бер генә әйбернең дә була алмаганына төшенсәк, ниятләребезне, гамәлләребезне пакьләргә ныграк тырышыр идек.

Өченчедән, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә һәр догабызны, Аннан сораган һәр мөрәҗәгатебезне ишетә. Раббыбыз Үзе адәм балаларына Аңа догалар кылып ялварырга кушты, бу хакта Ул болай дип әйтә:

وَقَالَ رَبُّكُمُ ادْعُونِي أَسْتَجِبْ لَكُمْ ۚ

**«**[Ий кешеләр!] **Раббыгыз әйтте: «Миңа дога** [һәм гыйбадәт] **кылыгыз,** [сораганнарыгызны үтәп] **сезгә җавап** [һәм савап] **бирим».**

«Гафир / Гафу итүче», 40:60

Әйе, без Аллаһы Тәгаләдән сорасак, Ул һәрвакыт җавап бирә. Хәтта бу җавап без көткәннән соңрак килсә дә, хәтта бу без көткән җавап булмаса да, әмма бары Аллаһы Тәгалә генә нәрсәнең хәерлерәк икәнен белүче. Шуны беркайчан да истән чыгармасак иде: безнең Раббыбызга кылган догабыз – Аңа якынаюда ярдәм итә торган иң көчле коралларыбызның берсе.

Һәм, газиз дин кардәшләрем, әлбәттә, Аллаһы Тәгалә – Рәхимле һәм Гафу итүче. Хәтта без ялгышсак та, гөнаһ кылсак та, без ихластан тәүбә кылып, исигъфар кылабыз икән, бөек Раббыбыз безне гафу итәргә әзер. Шул рәхим-шәфкать һәм ярлыкау – Аллаһының безгә якын булуының тагын бер чагылышы. Дөреслектә, Раббыбыз безне бәхетле һәм имин хәлдә күрергә тели.

Шулай булгач, кардәшләрем, Раббыбызның безгә ни рәвешле якын булуын аңлавыбыз безне дөрес тормыш алып барырга, тәкъвалырак булырга, Ул кушканнарны үтәп, аңа һәрдаим гыйбадәттә, догада булып яшәргә этәрергә тиеш. Аның рәхмәтен яхшырак аңлаган саен, без ныграк Аңа якынаерга, Аның әмерләре буенча яшәргә тырышачакбыз.

Аллаһы Тәгалә шушы юлда безгә көч һәм сабырлык биреп, кылган догаларыбызны, гыйбадәтләребезне кабул кылсын! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел

тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Алмаз хәзрәт Шәрәфетдинов,*
*Питрәч районы Яңа Шигали авылының*
*Габдрахман бине Гауф исемендәге мәчете мөгаллиме*

*20 июнь вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аеның 24 нче көне, һиҗри исәп буенча 1446 ел*

# Мөхәррам ае фазыйләте

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Галәмнәрне юктан бар кылып, аларны Үзенең хикмәте белән тәрбияләп торучы, безне шушы дөньяга төрле сынаулар белән сыналыр өчен җибәргән Аллаһы Тәгаләгә дан-мактауларыбыз булса иде. Шул сынауларны дөрес итеп үтәргә өйрәтер өчен җибәрелгән, мөэминнәрне җәннәт белән сөендергән, имансыз һәм монафикъларны җәһәннәм белән кисәткән хак Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез булса иде.

Һиҗри календарь буенча, ягъни мөселманнарда кабул ителгән ай календаре буенча, ел исәбе (яңа ел) мөхәррам аеның беренче көненнән башлана. Ул сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үзенең сәхабәләре белән Мәккә шәһәреннән Мәдинәгә күченгән ай булып чыга. «Һиҗрәт» сүзе ул гарәпчәдән күченү дип тәрҗемә ителә дә. Быел мөхәррам ае керү белән, һиҗри 1447 ел башланып китәчәк (быел 26 июнь көненнән). Димәк, 1447 ел элек Пәйгамбәребез галәйһиссәлам Мәдинәгә һиҗрәт кылган булган дигән сүз бу.

Ислам дине барлыкка килгән чорда мөселманнарның үз календаре булмаган, һәм тора-бара бу мәшәкатьләр тудыра башлаган. Соңрак, күп галимнәребез бу хәзрәти Гомәр бине әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе хәлифә булган чорда ди, сәхабәләр үзара киңәшләшеп, ел исәбен һиҗрәт вакыйгасыннан

саный башларга килешкән. Ни өчен алар мондый фикергә килгән? Чөнки Мәдинә шәһәренә һиҗрәт кылганнан соң, мөселманнар өчен яңа тормыш башлана: дөньяда беренче мәчет төзелә һәм беренче Ислам дәүләте барлыкка килә һ. б.

Мәккә шәһәрендә Ислам динен кабул итеп, зур сынаулар күтәреп, соңыннан Мәдинә шәһәренә күченгән сәхабәләрне «мөһаҗирләр» дип атыйбыз. Бу сәхабәләрнең һиҗрәте дә бөтен мөселманнар өчен ныклык һәм тәкъвалык мисалы булып тора. Сәхабәләр туган йортларын, туганнарын, якыннарын, малларын калдырып, Аллаһы ризалыгы өчен дип, динебез Исламны куәтләү нияте белән, Мәдинә шәһәренә күченәләр.

Димәк, һиҗри елның иң беренче ае – мөхәррам ае. Шушы айның фазыйләтен, өстенлеген күрсәтеп, Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Рамазаннан соң иң хәерле ураза – Аллаһының ае булган мөхәррам уразасы»[1].

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә болай дип әйтә:

إِنَّ عِدَّةَ الشُّهُورِ عِندَ اللَّهِ اثْنَا عَشَرَ شَهْرًا فِي كِتَابِ اللَّهِ يَوْمَ خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ مِنْهَا أَرْبَعَةٌ حُرُمٌ ۚ ذَٰلِكَ الدِّينُ الْقَيِّمُ ۚ فَلَا تَظْلِمُوا فِيهِنَّ أَنفُسَكُمْ ۚ

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында айларның саны Аллаһының күкләрне һәм җирне яраткан көндәге** [катгый карарын билдергән] **язуында** [Ләүхелмәхфүздә] **– унике. Шуларның дүртесе – харам** [айлар]**. Бу –** [рәвешле елның унике ай булып, шуларның дүртесенең харам кылынуы турындагы хөкем Ибраһим һәм Исмәгыйль галәйһимәссәламнән калган] **хак дин.** [Моннан соң бернинди айда да, бигрәк тә] **Боларда** [гөнаһ эшләү һәм гыйбадәтләрне кире кагу белән җаныгызны җәһәннәмгә атып] **үз-үзегезгә золым итмәгез».**

«Әт-Тәүбә», 9:36

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Хәзрәти Әбү Бәкрат радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзләрен китергән: «Елда унике ай бар. Аларның дүртесе – тыелу айлары. Өчесе рәттән килә: зөлкагъдә, зөлхиҗҗә, мөхәррам һәм дүртенчесе – җөмәдәл-ахыр белән шәгъбан арасында булган раҗәб ае»[1]. Бу айларны без «харам айлар», «тыелу айлары» дип атыйбыз. Әгәр дә ел буена гөнаһ, харам гамәлләр эшләү тыелган икән, бу дүрт айда аларның харамлыгы, гөнаһлылыгы тагы да арта.

Мөхәррам аенда сөннәт булып торган гамәлләрнең берсе – ураза тоту. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгалә өчен Рамазан аенда тотылган уразадан соң иң хәерлесе – мөхәррам аеныкы», – дип әйткән. Монда ул мөхәррам аеның өстенлеген билгеләп үткән.

Шулай ук мөхәррам аеның 10 нчы көне – бик мөбарәк, олуг көн. Ул Гашурә көне дип атала. Гашурә көнендә ураза тоту да – Расүлебез сәлләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Сөннәте.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мөхәррам аен «Аллаһы ае» дип билгеләве аңа дәрәҗә бирә. Бу сүзләр изгелекләр кылып, гыйбадәтләребезне арттыру өчен җитәрлек сәбәп булырга тиеш.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, берничә көннән мөхәррам аена керәбез, иншәАллаһ. Мөхәррам ае – мөселман дөньясы өчен яңа елның башлануы ул, дидек. Димәк, без тормышыбызны яңадан, яңа биттән башлыйбыз. Яңа ел җиткәч, мөселманнар үзган елга хисап, анализ эшли алалар. Шулай ук киләсе елга планнар төзергә, максатлар куярга да рөхсәт ителә. Һәм шулай ук Аллаһы Тәгаләдән киләсе елга иминлек, бәрәкәт сорарга кирәк. Ә кем өчендер бу ай ниндидер яңа эшләр яки башка мөһим яхшылыклар башлау өчен старт булырга мөмкин. Һәрбер кешегә үз-үзенә хисап бирү мөһим. Тугры хәлифә Гомәр бине әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе: «Сезгә хисап кылынганчы, үз-үзегезгә хисап кылыгыз. Гамәлләрегез үлчәнгәнче, үзегез гамәлләрегезне үлчәгез», – дип әйткән.

[1] Имам әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Айназ хәзрәт Зарипов,*

*Казанның «Апанай» мәчетенең икенче имамы*

*27 июнь вәгазе,*

*мөхәррам аеның 2 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Коръән ятлау фазыйләтләре

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, гыйлем ул – бер диңгездер, аның төбенә төшеп җитү мөмкин түгел. Һәм гыйлем алу юлына баскан кеше аның ахырына ирешмәс. Безнең төп гыйлем чыганагыбыз ул – Китабыбыз, Коръәни Кәрим. Раббыбыз аңа бар әйбер турындагы гыйлемнәрне салган, һәр кагыйдәне, хатаны аңлаткан, һәм һәр кеше аннан үзенә кирәклесен ала. Мәсәлән, фикһ белгече яки мөселман юристлары аннан тыелган һәм рөхсәт ителгән әйберләр турындагы гыйлемне ала. Гарәп теле белгечләре аннан җөмлә төзелешенә, сөйләм матурлыгына караган кагыйдәләрне чыгара. Һәм башка шундый күп мисаллар китерергә була.

Газиз дин кардәшләрем, Коръән ул – Раббыбызның бер рәхмәте, һәм аңа бәйле булган һәр гамәлдә – укыйбызмы без аны, ятлыйбызмы, тыңлыйбызмы яки аятьләре хакында фикерлибезме – барысында хәерлелек бар. Бүген шул хакта искә төшерербез.

## 1. Коръән аятьләрен тыңлау хакында

Коръәнне тыңлауга килгәндә, бу саваплы гамәл күңелләрнең тынычлануының һәм һидаятьнең сәбәбе булып тора. Раббыбыз болай дип әйтә:

فَبَشِّرْ عِبَادِ ﴿١٧﴾ الَّذِينَ يَسْتَمِعُونَ الْقَوْلَ فَيَتَّبِعُونَ أَحْسَنَهُ ۚ أُولَٰئِكَ الَّذِينَ
هَدَاهُمُ اللَّهُ ۖ وَأُولَٰئِكَ هُمْ أُولُو الْأَلْبَابِ ﴿١٨﴾

**«**[Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм!] **Колларымны сөендер. Алар** [дингә кагылган] **сүзне тыңлыйлар,** [яхшы белән иң яхшы арасында сайлыйлар һәм] **аның иң яхшысына ияртәләр. Әнә шуларны Аллаһы** [динен дөрес итеп аңларга] **һидаять итте. Әнә шулар – аек акылга ия кешеләр».**

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:17–18

Аллаһы Тәгалә әйткәнчә, хикмәтле мөэминнең бер сыйфаты ул – башкаларның сүзенә колак сала белү, әмма ишеткәннәрдән иң яхшысын сайлап алу. Ә иң яхшы, күркәм сүзләр ул – Аллаһының Китабы һәм Расүлебезнең сүзләре.

Шулай ук Коръәнне тыңлау Аллаһының рәхмәтен алуның бер сәбәбе дә булып тора. Раббыбыз болай дип әйтә:

وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَأَنصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ ﴿٢٠٤﴾

**«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез** [Аллаһы тарафыннан] **рәхмәт ителерсез».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

Тәфсир галиме шәех Вәһбә әз-Зөхәйли бу аятьне аңлатканда, үз тәфсирендә болай дип язган:

«Коръәни Кәрим укылганда, аятьләрен аңлар һәм нәсыйхәт алыр өчен, аны тыңлагыз. Мәгънәләре хакында фикер йөртер өчен, дәшмичә һәм хошугълык (түбәнчелек) белән тыңлагыз, мәгънәсен аңлау һәм нәсыйхәт ала белү сезне Аллаһының рәхмәтенә ирештерер. Һәм бу калебләре иман нуры белән яктыртылган тәкъва мөэминнәргә генә хас. Бу аятьтән күренгәнчә, Коръән намазда яки намаздан тыш укылганда, аны дәшмичә тыңлау вәҗиб (тиешле) булып тора. Һәм бу барлык хәлләргә караган гомум кагыйдә»[1].

Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә Коръәнне тыңлауның бөек дәрәҗә булуын аңлатты. Хәзрәти Әбү Һөрайра радыяллаһу

1 «Әт-Тәфсир әл-Мөнир», 9/229.

ганһе Расүлебез галәйһиссәламнең мондый сүзләрен тапшырган: «Аллаһының Китабының бер аятен тыңлаган кешегә берничә тапкыр арттырылып әҗер-савап язылыр. Ә Аллаһының Китабының бер аятен укыган кеше өчен ул аять Кыямәт көнендә бер нур булыр»[1].

Шунысын да әйтергә кирәк, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләре белән күрешкәндә, аларны аңа Коръән укырга сорый торган булган. Бу хакта күп кенә хәдисләр тапшырылган.

## 2. Коръәнне уку хакында

Газиз дин кардәшләрем, арабызда кемнәрдер бәлки әле Коръәнне укый белмидер. Ә кемдер укыганда хата ясарга курка. Кемдер диндә беренче адымнарын ясый. Әмма бу юлда күбрәк тырышлык куйган саен, без зуррак әҗер-саваплар алабыз. Арабызда күпләр, бигрәк тә өлкән буын, Коръән укыганда хата җибәрә алам дип борчыла, кайгыра. Борчылырга кирәкми. Чөнки бу эштә тырышлык куйган кешегә савап икеләтә арттырылып бирелә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дигән: «Коръәнне оста укучы күркәм язып торучылар (ягъни фәрештәләр) белән булыр. Ә Коръәнне авырлык белән, төртелеп укучыларга икеләтә әҗер-савап әзерләнгән»[2].

Шуңа күрә, авыр булса да, төшенкелеккә бирелергә кирәк түгел. Хәзрәти Габдуллаһ бине Мәсгуд радыяллаһу ганһе: «Йөрәкләр савытларга тиң, аларны Коръән белән тутырыгыз һәм башка нәрсә белән тутырмагыз», – дип әйткән. Коръәни Кәримдә 16 җирдә Аллаһы Тәгалә безне Коръән укырга өнди.

Авыр мизгелләрдә кеше рухи көч, таяныч эзли, әмма Коръән уку – бар авырлыклардан, авырулардан дәва да, бәрәкәт чыганагы да. Бу хакта изге аятьләр үзләре үк сөйли.

Газиз дин кардәшләрем, кызганыч, бик күп мөселманнарның өйләрендә Коръән китабы гомумән юк, ә кемнекедер бар, әмма ул «матурлык өчен генә»

[1] Имам Әхмәд.

[2] Имам әл-Бохари, Мөслим.

диярсең, укылмыйча китап киштәсендә тузанланып ята. Коръән укуның әһәмияте, саваплары турында искә төшереп китик.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Коръән ул – аны укучы өчен Аллаһы каршында шәфәгать кылучы (яклаучы димәк) һәм аклаучы; һәм аның буенча яшәүчене ул җәннәткә китерер, ә аның буенча яшәмәүчене җәһәннәм утына тартыр» [1].

Янә башка хәдисендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай ди: «… Кешеләр Аллаһының йортларында Коръәнне укырга һәм өйрәнергә җыелгач, аларга рухи тынычлык һәм Аллаһының рәхмәте төшәр. Аларны фәрештәләр әйләндереп алыр, һәм Аллаһы Тәгалә бу кешеләрне Үзе янында булганнар (фәрештәләр) алдында искә алыр» [2].

Коръәнне укырга өнди торган хәдисләр алар бик күп. Әмма һәр укучы да тулы савапка ирешә алырмы соң? Изге Китапны укуга бәйле ниндидер кагыйдәләр, әдәпләр бармы? Әйе, дин кардәшләрем, укыган аятьләребез өчен тулы савап алырга теләсәк, без бу эштә билгеле бер әдәпләрне дә сакларга тиешбез. Мәсәлән, Коръән китабын без бик кадерләп, пакь һәм тәһарәтле булганда гына кулга алып укырга, кыйбла тарафына юнәлеп укырга һәм, әлбәттә, тиешенчә, тәҗвид кагыйдәләрен истә тотып, дөрес итеп укырга тырышырга тиешбез. Коръән мосхафларына, тәфсир китапларына да гади китапларга караган кебек кенә карамагыз.

## 3. Коръәни Кәримне ятлау

Газиз дин кардәшләрем, Коръән аятьләрен ятлау – зур гыйбадәт. Коръәнне яттан белгән кеше Аллаһы каршында бөек дәрәҗәләргә ирешергә мөмкин.

1 Имам әт-Табарани.

2 Имам Мөслим № 2699; Әбү Давыд, әт-Тирмизи, Ибне Мәҗә.

Хәзрәти Әбү Сәгыйть әл-Ходри тапшырган хәдистә болай диелә: «Җәннәткә кергәч, Коръәнне белүчегә: «Укы һәм күтәрел!» – диелер. Һәм ул укыган һәр аяте белән җәннәттәге дәрәҗәләр буенча күтәрелеп барыр, хәтта соңгы аятен укыганчыга кадәр»[1].

Хәдисләр галиме Әбү Сөләйман әл-Хаттаби болай дип язган булган: «Коръән аятьләренең саны җәннәттәге дәрәҗәләр санына тиң. Һәм Коръәнне укучыга: «Күпме аять укысаң, шул дәрәҗәгә күтәрел», – диеләчәк. Һәм Коръәнне тулаем укып чыгучы җәннәттәге иң югары баскычка күтәрелер. Ә аның бер өлешен укучы укыган аятьләре саны буенча күтәрелер. Ягъни укуын кайда тәмамласа, ирешәлгән иң югары дәрәҗәсе шул булыр»[2].

Раббыбыз безгә Үз ризалыгы өчен генә Коръәнне укырга, ятларга һәм аның буенча гамәл кылып яшәргә насыйп итсен!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Хөсәенҗан хәзрәт Дарвоиев,*
*Питрәч районы Яңа Шигали авылының*
*Габдрахман бине Гауф исемендәге мәчетендә*
*Коръән мөгаллиме, Коръән хафиз*

1 Имам Ибне Мәҗә.

2 «Мәгалим әс-Сүнән» (1/289–290).

*4 июль вәгазе,*

*мөхәррам аеның 9 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Гашурә көне

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча мактаулар безне юктан бар кылып, безне нигъмәтләндереп торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә булса иде. Һәм дә Аның хак илчесе, безгә туры юлны өйрәтеп калдырган, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде!

Аллаһының рәхмәте белән һиҗри календарь буенча яңа 1447 елга аяк бастык. Бүген инде мөхәррам аеның 9 нчы көне, димәк, кояш баегач, 10 нчы көне башлана, ул – Гашурә көне.

Берничә мең ел элек нәкъ менә бу көнне Аллаһы Тәгалә Үзенең пәйгамбәрен – Муса галәйһиссәламне – һәм аның халкын Фиргавен кулыннан коткарды.

Без беләбез, сәхабәләр заманында Мәдинә шәһәрендә яшәүче мөселманнарга андагы яһүдиләр белән еш очрашырга һәм аралашырга туры килде. Һиҗрәттән соң, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм яһүдиләрнең Гашурә көнне ураза тотуларын күрде. Ул галәйһиссәлам аларга бу ураза тотуларының хикмәте турында сорау бирде.

Хәзрәти Ибне Габбас радыяллаһу ганһе бу хакта болай дип хәбәр итә: «Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә килеп, андагы яһүдиләрнең Гашурә көнендә ураза тотканын күргәч: «Сез ураза тоткан көн

нинди көн ул?» – дип сораган. Алар: «Бу – бөек көн. Бу көндә Аллаһы Тәгалә Мусаны һәм аның халкын коткарды, Фиргавенне һәм аның гаскәрен батырды. Муса бу көнне Аллаһыга шөкер йөзеннән ураза тотты, шуңа күрә без дә бу көнне ураза тотабыз», – дип җавап биргәннәр. Шуннан соң Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бездә Мусадан (үрнәк алырга) хокуклар күбрәк һәм без сезгә караганда аңа лаеклырак», – дигән һәм сәхабәләргә бу көнне уразада үткәрергә кушкан[1].

Шулай беренче елларда Гашурә уразасы фарыз булган, ләкин соңыннан ул өстәмә ураза булып калган. Хәзрәти Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһе шундый хәдис тапшыра: «Рамазан уразасы фарыз булгач, Гашурә көненең уразасы ирекле булды»[2].

Шулай ук Гайшә анабыз радыяллаһу ганһәдән түбәндәге хәдис тапшырыла: «Дөреслектә, җаһилият чорында кораешлеләр Гашурә көнендә ураза тотканнар, аннары Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Рамазан аенда ураза фарыз булганчыга кадәр бу көнне ураза тотарга кушкан. Соңыннан, Рамазан аенда ураза фарыз булгач, Расүлуллаһ галәйһиссәлам болай дигән: «Гашурә уразасын тотарга теләгән кеше тотсын, ә теләмәгән кеше калдырсын»[3].

Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Гашурә көненең һәм, гомумән, мөхәррам аеның дәрәҗәсе зур булганга күрә, аларны аерым билгеләп, ураза тота торган булган. Мөхәррам ае Рамазан аеннан соң ураза тоту өчен иң хәерле ай булып санала. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дип әйткән: «Рамазан аеннан кала иң хәерле ураза Аллаһының аенда – мөхәррам аенда – тотылган ураза»[4].

1 Имам Мөслим, 1130.

2 Имам Мөслим.

3 Имам әл-Бохари.

4 Имам Мөслим.

Галимебез мөфти Таки Госмани әл-Хәнәфи (хафизаһуллаһ) бу хәдискә аңлатма биреп: «Бу айда ураза фарыз булмаса да, ирекле булса да, аның өчен Аллаһы Тәгаләдән юмарт бүләк бирелә. Югарыдагы хәдис шуны күрсәтә: бу айдагы ураза, башка ирекле ураза белән чагыштырганда, иң зур әҗер-савап китерә. Шул ук вакытта хәдистә мөхәррамда ураза тоткан өчен вәгъдә ителгән әҗерне ай буе ураза тоткан очракта гына алырга мөмкин дип әйтелми. Бу айның һәр көн уразасы өчен әҗер бирелә. Шуңа күрә безгә бу мөмкинлектән тулысынча файдаланырга кирәк»[1].

Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Бу айда һәр ураза көне өчен кеше 30 көн дәвамында ураза тотуга тиң әҗер алачак»[2].

Хөрмәтле дин кардәшләрем, бу хәдисләр безне ураза тоткан көннәр санын арттырырга этәрә һәм мөхәррам аена игътибарлырак булырга өйрәтә. Әгәр дә кемдер мөхәррамның 30 көнен ураза тотса, бу – сөннәт, һәм ул зур әҗер-савапларга лаек булачак.

Шулай ук Гашурә көнендә тотылган ураза узган ел дәвамында кылынган кечкенә гөнаһларның гафу ителүенә сәбәп була ала. Чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Гашурә көнендә ураза тотып, Аллаһы Тәгалә узган елгы гөнаһларны кичерер дип өметләнәм»[3].

Мөфти Таки Госмани әл-Хәнәфи (хафизаһуллаһ) болай дип яза: «Хәдисләрнең берсе нигезендә, Гашурә көнендәге уразаның алдагы яки аннан соңгы көн уразасы белән тулыландырылуы яхшырак. Ягъни ике көн ураза тотарга киңәш ителә: 9 нчы һәм 10 нчы мөхәррам яки 10 нчы һәм 11 нче мөхәррамда. Моның сәбәбе: мөселманнарның ураза тоту рәвеше яһүдиләрнекеннән аерылып тору теләге, чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткәнчә, яһүдиләр Гашурә көнендә генә ураза тотканнар.

[1] «Ислам айлары», 8 б.

[2] Имам әт-Табарани; әт-Таргыйб, т. 2, 114 б.

[3] Имам Мөслим.

Шуңа күрә ул мөселманнарга Гашурә көнендәге уразага тагын бер көн өстәргә киңәш итте»[1].

Аллаһы Тәгаләгә иң якынайта торган гамәлләр ул – фарыз гамәлләр. Адәм баласы өстендә иң беренче үтәргә тиешле булган нәрсә – фарыз гамәл. Беләбез, әгәр дә мөселман фарызны үтәмәсә, күпме генә нәфел, сөннәт гамәлләр, саваплы эшләр эшләмәсен, ул бер фарызны алыштыра алмый. Күпме генә садакасын бирмәсен, ул бер укылмаган фарыз намазын алыштыра алмаячак. Күпме генә мәчетләр салмасын, ул үзенең кылмаган фарыз гыйбадәтен, калдырган биш вакыт намазларын, калдырган Рамазан уразасын берничек тә кайтара алмый. Шуңа күрә, мөселман кешесе иң беренче чиратта үзенең фарызларын үтәүдә тырышлык куярга һәм Аллаһының чикләрен белеп, харамнардан тыелырга тиеш.

Һәм, хөрмәтле дин кардәшләрем, фарызлардан тыш, Аллаһы Тәгалә безгә Үзенә якынаю өчен, гөнаһ-хаталардан арыну өчен, фарыз гамәлләрдә булган кимчелекләрне каплар өчен, нәфел гамәлләр бүләк итте. Әлбәттә, адәм баласы ул гамәлләрне калдырса, гөнаһлы булмый, әмма Кыямәт көнендә аның биш вакыт намазын тикшергәндә, фарызларын тикшергәндә, бик күп кимчелекләр чыгачак. Фәрештәләр: «Раббым, аның шушы намазында кимчелек, Раббым, шушы уразасында кимчелек», – дип санап торганда, рәхимшәфкать Иясе Аллаһы Тәгалә: «Бәндәмнең нәфелләрен күрсәтегез. Фарыздан тыш, өстәмә булган гамәлләре бармы?» – дип сорар. Шуннан соң шушы нәфел гамәлләр белән кимчлекләрне капларлар һәм адәм баласы моңа бик нык шатланыр.

Димәк, өстәмә, нәфел уразаларыбыз булса, фарыз уразабызда булган кимчелекләрне капларлар. Өстәмә хаҗ һәм гомрәләр кылсак, бу фарыз хаҗда булган кимчелекләрне каплар. Биргән садакаларыбыз булса, зәкят биргән вакытта җибәргән кимчелекләребезне каплар.

[1] «Ислам айлары», 9 б.

Дин кардәшләрем, Аллаһы Тәгалә безгә: «Бу – фарыз, бу – харам», – дип кенә әйтмәде, ягъни: «Ак белән кара гына бар», – дип кенә әйтмәде. Алар арасында бик күп төсләр бар әле. Шушы нәфел гамәлләр адәм баласына бик күп файдалар китерә. Фарыз гамәлләрне күпмедер тәртипкә китерергә тырышабыз, әмма безнең әле нәфелләрдә бик күп кимчелекләр бар. Без нәфел гыйбадәтләргә, нәфел уразаларга бик җиңел карыйбыз. Әлбәттә, мөселман кешесе фарыз мәсьәләсендә: «Намазны укыйммы, укымыйммы?» – дип әйтә алмый. Аллаһы бездән сорамады, фарыз – димәк, без укырга тиеш. Уразада да нәкъ шул. Рамазанда ураза йөкләнде, кеше сау-сәламәт икән, ул аны тотарга тиеш. Ләкин ел дәвамында ураза тоту өчен хәерле булган бик күп көннәр бар. Әмма без аларны үткәрәбез дә җибәрәбез. Безнең өстәмә ураза тоту өчен хәерле булган айлар бар: булсын ул шәгъбан ае, булсын ул харам айлар, шәввәлнең 6 көне, булсын ул зөлхиҗҗә аеның уразасы – алар күп, ләкин еш кына без аларны уразасыз үткәреп җибәрәбез. Ниндидер сәбәп табабыз, төрле акланулар аркасында күпме савапны ычкындырабыз.

Хәзрәти Ибне Габбас радыяллаһу ганһе янына бер кеше килеп, ураза тоту турында сораган. Ибне Габбас радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Сиңа бер хәдис сөйлимме? Бу хәдис – мин саклаган бүләкләрнең берсе. Әгәр син Давыд галәйһиссәлам кебек ураза тотарга телисең икән, Давыд пәйгамбәр бер көн ураза тотты, ә икенче көнне ураза тотмады (ягъни көнаралаш ураза тотты). Әгәр син аның улы Сөләйман галәйһиссәлам кебек ураза тотарга телисең икән, ул һәр айның башында, уртасында һәм ахырында өчәр көн ураза тотты. Әгәр син Гайсә галәйһиссәлам ураза тоткан кебек ураза тотарга телисең икән, ул гомере буе ураза тотты. Аның ризыгы – арпа, ә киеме каты йоннан иде. Кайсы урында булганда кич җитсә, шул урында тукталып, таң галәмәте күренгәнче намаз укый иде. Кайда гына туктамасын, анда ике рәкәгать намаз укый иде. Әгәр син аның анасы ураза тоткан кебек ураза тотарга телисең икән, Мәрьям ана ике көн ураза тота, аннары ике көн тотмый иде. Әгәр син кешеләрнең иң яхшысы – Мөхәммәд салләллаһу галәйһи

вә сәлләм – кебек ураза тотарга телисең икән, дөреслектә, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам ай саен өчәр көн ураза тотты. Ягъни ул һәр айның унөченче, ундүртенче һәм унбишенче көннәрендә ураза тоткан һәм: «Ул өч көндә ураза тоту бөтен гомер буе ураза тоту кебек», – дип әйткән»[1].

Газиз дин кардәшләрем, әлхәмдүлилләһ, бүген мөхәррам аеның 9 нчы көне, димәк, иртәгә – Гашурә көне. Без, сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәте буларак, бу көнне кадерлик, кулыбыздан ычкындырмыйк, бу ураза көне. Ураза тотарга ниятлик, гаиләләребезне дә шуңа чакырыйк.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Әхмәт хәзрәт Фәйзулин,*

*Казанның «Иман нуры» мәчетенең икенче имамы*

---

[1] «Тәнбиһ әл-гафилин», 42 б.

# Сорау – җавап

***Сорау:*** ***«Хәзерге мөфтиятләр шәригать буенча законлы көчкә ия түгел, аларга иярергә ярамый, чөнки Россиядә беренче мөфтият патшабикә Екатерина II боерыгы буенча мөселманнарны дәүләт күзәтчелегенә алу өчен төзелгән», – диләр. Бу шулаймы?***

## Җавап:

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

Россиядә мөселманнарның беренче Диния нәзарәте патшабикә Екатерина II нең 1788 елның 22 сентябрендәге Указы нигезендә «Оренбург Мөселман Диния нәзарәте» исеме астында оештырыла.

Көнчыгышны өйрәнүче танылган галим Ренат Беккин Россиядә татар мөфтиятләре тарихы турында болай дип яза: «Әмма мөфтиятнең килеп чыгышы нинди генә булмасын, Россиядә бу институт үз урынын тапканын һәм империя хакимияте, ә бераздан ислам тарафдарлары тарафыннан да файдалы дип табылуын танымый мөмкин түгел. Мөфтият мөселманнарның тормышын күзәтчелектә тоту өчен төзелгән, шуңа күрә баштан ук дин тотучыларның шактый өлеше аны тискәре кабул иткән. Ләкин соңрак Уфадагы Диния нәзарәте карамагындагы җирлектәге мөселман халкының күпчелеген тәшкил иткән татарлар аны үзләренең милли институты итеп кабул итә башлый.

Шунысы игътибарга лаек: XIX гасырның икенче яртысына бу фикер белән Россия империясенең рәсми затлары, аерым алганда, мөселман халкы

күп булган төбәкләр белән идарә иткән кайбер губернаторлар, шулай ук башка түрәләр, мәсәлән, Изге хакимлек Синодының обер-прокуроры К. П. Победоносцев килешә. Алар, Уфада Диния нәзарәте исламны һәм мөселманнарны көчәйтү максатына хезмәт итә дип, аны бетерү яклы була.

Татарларның мөфтиятне колониаль институт буларак түгел, ә үз диннәрен һәм гомумән милли һәм дини үзенчәлекләрен саклап калырга мөмкинлек бирә торган оешма буларак кабул итүе Уфадагы диния нәзарәтенең ни өчен Россиядә, монархия җимерелгәннән соң да, яшәвен (үзгәртелгән рәвештә булса да) дәвам итүен аңлата»[1].

Башкача әйткәндә, тарихи дәлилләр шуны раслый: Диния нәзарәте, мөселманнар өстеннән күзәтчелек итә торган дәүләт органы буларак кына түгел, бәлки татарларның динен һәм милли үзенчәлеген саклый торган институт буларак та кабул ителгән.

Алай гына да түгел, инкыйлабтан соң һәм монархия җимерелгәч, Россиядә дини ирек бирелеп, барлык патша указлары гамәлдән чыгу белән, дин тотучылар мөселманнарның Диния нәзарәте институтын бетерми генә түгел, ә Диния нәзарәтен Эчке Россия һәм Себер мөселманнары Диния нәзарәте итеп үзгәртеп кора. Бөтенроссия мөселманнар корылтаенда беренче мөфти булып күренекле дин галиме Галимҗан Баруди сайлана, ул бу вазифада мөселманнар өчен бик күп файдалы эшләр башкара. Тарихта беренче тапкыр мөфти император тарафыннан куелмый, ә ирекле сайлауларда сайлана.

Танылган суфи галим, шәех Сәйфулла кади Башларов күп еллар Дагстан халык суды мөфтие вазифасын башкара. Дагстан халык суды Дагстан өлкәсе башкаласы Темир-Хан-Шурада төзелә. Аның составы Кавказ Армиясе гаскәрләре белән җитәкчелек итүче командующий тарафыннан расланган. Суд утырышлары карарлары шулай ук өлкә гаскәрләре командующие

[1] «Люди в верности надежные…»: татарские муфтияты и государство в России (XVIII – XXI века). – М.: Новое литературное обозрение, 2022. – 552 б.

тарафыннан да расланырга тиеш була. Дагстан халык суды әдәп-әхлак һәм шәригать буенча эшләрне караган[1].

Шулай итеп, Россия тарихының төрле чорларында күренекле дин галимнәренең һәм рухи остазларның мөфтиләр булып, үз дәрәҗәләре һәм абруе ярдәмендә мөселманнарга зур файда китерүе турында мисаллар шактый.

Шунысы әһәмиятле: шәригатьтә Диния нәзарәтләренең зарурлыгы һәм алар чыгарган фәтвалар һәм карарларга иярү өчен нигез бар. Хәнәфи мәзһәбендә, әгәр дә мөселманнар теге яки бу җирлектә дөньяви кануннар буенча яшәсәләр һәм анда шәригать судлары булмаса, алар үз араларыннан казыйны үзләре сайларга һәм аңа мөселманнар арасындагы бәхәсләрне хәл итү хокукын тапшырырга тиешләр, диелә.

Мәсәлән, Ибне Габидин «Радд әл-мүхтәр»дә Хәнәфи мәзһәбендәге кайбер имамнарның фикерләрен китерә: «Мөселман булмаганнар идарә иткән җирлектә мөселманнарга җомга һәм бәйрәм намазлары үткәрү рөхсәт ителә, ә казый итеп мөселманнар үзләре риза булган кеше сайлана. Аларга мөселманнарның эшләре белән идарә итәрлек мөселман кешесен (вәли) табу мәҗбүри (вәҗиб) булып тора»[2].

Аннары ул имам Камал бине Хумамның «Фәтх әл-Кадыйр» китабыннан өзек китерә: «Әгәр мөселманнарның хакиме һәм алар иярә алырлык кешесе булмаса, <…> мөселманнарга үз араларыннан бер кешене сайлап алу мәҗбүри (вәҗиб), һәм аңа мөселманнарның эшләре белән идарә итү һәм аларның бәхәсләрен хәл итүне йөкләргә кирәк. Һәм ул алар өчен хөкемдар булырга тиеш. Шулай ук алар җомга намазын алып баручы имамны сайларга тиеш».

[1] Халифаева Анжела Курбановна, Джалилов Шамиль Надирович. К 150-летию судебной реформы 1864 года: из истории судебной власти дореволюционного Дагестана // Судебная власть и уголовный процесс. 2014. №3. URL: https://cyberleninka.ru/article/n/k-150-letiyu-sudebnoy-reformy-1864-goda-iz-istorii-sudebnoy-vlasti-dorevolyutsionnogo-dagestana (дата обращения: 28.12.2024).

[2] Ибне Габидин «Радд әл-мүхтәр», Т.16, б. 317 («Дәр әс-Сәлам»).

Хәзерге вакытта да без Россиядә шуңа охшаш вәзгыятьне күзәтәбез: мөселманнар дини оешмалар тирәсендә берләшә, үзләренә имамнар сайлый, ә имамнар Диния нәзарәте рәисен сайлый. Диния нәзарәте җәмәгать намазларын үткәрүне, мәчетләр эшчәнлеген, дини белем бирүне җайга сала, Рамазан аеның башлануын һәм тәмамлануын билгели, фәтвалар бирә, мөселманнарның бәхәсләрен хәл итә, зәкят җыя һәм тарата, хаҗга һәм гомрәгә баруны оештыра, хәләл ризык җитештерүне сертификацияли, шулай ук бу җирлектә яшәүче мөселманнар үз диннәрен тулысынча үти алсын өчен бик күп эшләр башкара.

Моннан тыш, «әт-Татарханийя» фәтвалар китабында болай диелгән: «Әгәр мөселман булмаганнар үзләре мөселманнар өчен казый билгеләсә, һәм мөселманнар бу карар белән килешсә, бу билгеләү дөрес булачак»[1].

Димәк, хәтта дәүләт үзе, мөселманнар катнашыннан башка, мөселманнарның эшләре белән идарә итүчене сайласа (Россия империясендә һәм СССРдагы кебек), ул мөхтәрәм мөселман булса һәм әлеге вазифага лаек икән, аңа иярү рөхсәт ителә.

Без шуны әйтә алабыз: СССР таркалганнан соң 90 нчы елларда Россиядә барлыкка килгән хәзерге Диния нәзарәтләре – дәүләт тарафыннан мөфти билгеләнгән Оренбург Диния нәзарәте яки совет чоры Диния нәзарәтләренең варислары түгел, ә бәлки 1917 елда шәех Галимҗан Барудины ирекле тавыш бирү юлы белән сайлаган беренче Бөтенроссия мөселманнар корылтаеның варислары.

Йомгак ясап, Кәлам Шәриф аятен китерәбез. Бөек Раббыбыз безгә нәсыйхәт бирә:

وَإِذْ تَأَذَّنَ رَبُّكُمْ لَئِن شَكَرْتُمْ لَأَزِيدَنَّكُمْ ۖ

[1] Ибне Габидин «Радд әл-мүхтәр», Т.16, б. 318 («Дәр әс-Сәлам»).

**«Әгәр шөкер итсәгез, һичшиксез, сезгә** [нигъмәтләрне тагын да] **арттырачакмын».**

«Ибраһим», 14:7

Әлеге аятьтән аңлашылганча, без хәзерге Россиядә булган дини ирек дәрәҗәсе өчен Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтле булмасак, имамнарыбызны һәм галимнәребезне хөрмәт итмәсәк, Аллаһы Тәгалә безне әлеге нигъмәтләрдән мәхрүм итәргә мөмкин. Аннан гына ярдәм һәм саклау сорыйбыз!

# Нәрсә?
# Кайда?
# Кайчан?

# ДЕКАБРЬ-ФЕВРАЛЬ

## Казанда «Мәрҗани» мәчетендә Диния нәзарәте пленумы утырышы узды

Җөмәдәл-ахыр аеның 3 нче көнендә (4 декабрь) Казанның «Мәрҗани» мәчетендә Диния нәзарәте пленумы утырышы узды. Анда Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, аның урынбасарлары, барлык имам-мөхтәсибләр, казыйлар, голәмалар, нәзарәтнең структур бүлекчәләре һәм оешмалары җитәкчеләре катнашты. Пленумда Нәзарәтнең үтеп баручы елда башкарган эшчәнлегенә йомгак ясалды.

## Казанда XII Саматов укулары узды

Җөмәдәл-ахыр аеның 3 нче көнендә (4 декабрь) «Мәрҗани» мәчетендә күренекле татар дин эшлеклесе, дин белгече һәм Татарстанның беренче казые Габделхак хәзрәт Саматовка багышланган XII Саматов укулары узды. Әлеге чарада Татарстан хәзрәтләреннән тыш, Россия мөселманнары Дини җыены Мөфтие, Әлбир хәзрәт Крганов, Самара өлкәсе Мөфтие Талип хәзрәт Яруллин, Габделхак хәзрәтнең улы – Когалым шәһәре Җәмигъ мәчете имам-хатыйбы Хәлил хәзрәт Саматов – һәм башкалар катнашты. Алар Габделхак хәзрәтнең  мирасы һәм күпкырлы эшчәнлеге турында сөйләп, аны сакларга һәм өйрәнергә кирәклегенә басым ясады.

## Түбән Кама балалар хастаханәсендә намаз бүлмәсе ачылды

Җөмәдәл-ахыр аеның 4 нче көнендә (5 декабрь) Түбән Кама балалар район хастаханәсендә дәвалау корпусының 1 нче катында намаз бүлмәсе

ачылды. Анда балалары белән хастаханәдә ятучы ата-аналарга да, медицина хезмәткәрләренә дә уңайлы шартлар тудырылган.

## Чистай мөхтәсибәтендә V Мөхәммәд-Закир Камалов (Чистави) укулары узды

Җөмәдәл-ахыр аеның 9 нчы көнендә (10 декабрь) Чистай мөхтәсибәтендә V Республикакүләм фәнни-гамәли конференция – «Мөхәммәд-Закир Камалов (Чистави)» укулары узды. Танылган дин галименең тормыш юлын һәм мирасын өйрәнүгә багышланган чара Россиядә игълан ителгән Гаилә елы, Татарстан мөфтияте тарафыннан игълан ителгән Гаилә һәм хәләл яшәү рәвеше елы кысаларында үткәрелде.

Чистай шәһәренең тарихи зиратында дога уку белән башланган чара Ислам үзәгендә конференциянең пленар утырышы белән дәвам итте. Анда Мөхәммәд-Закир Камаловның (Чиставиның) мирасын өйрәнү һәм саклау эшенә багышланган чыгышлар ясалды. Кунаклар шулай ук Чистай шәһәренең беренче Җәмигъ мәчете – «Нур» мәчетендә булды, Мөхәммәд-Закир Камалов музеен карады.

## Мөфти Малайзиядә «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең күчмә утырышында катнашты

Җөмәдәл-ахыр аеның 10 нчы көнендә (11 декабрь) Куала-Лумпурда (Малайзия) «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең күчмә утырышы узды. Утырышта Азия, Африка һәм Якын Көнчыгышның 32 иленнән, шулай ук халыкара оешмалардан 200 дән артык хакимият органнары вәкилләре, сәясәт, дин һәм җәмәгать эшлеклеләре катнашты. Алар арасында «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов; Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин

һәм «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме әгъзалары булган башка вәкилләр һәм чакырылган экспертлар бар иде.

Камил хәзрәт, утырышта чыгыш ясап, җыелышның мөхтәрәм кунакларын исламны үстерү өлкәсендә Татарстан һәм Диния нәзарәте белән хезмәттәшлеккә чакырды. Ул республиканың чит ил мөселман партнерлары һәм инвестицияләр белән эшли белүен һәм динне ныгыту өчен күп кенә кызыклы проектлар тәкъдим итәргә әзер икәнлеген билгеләп үтте. Камил хәзрәт Татарстанны Россиянең икътисади яктан иң уңышлы төбәкләренең берсе генә түгел, илебезнең ислам үзәге итеп атады һәм ислам финанслары, Коръәнне өйрәнү һәм бастыру, нәшриятчылык, дини-илаһият мирасын саклау, хәйриячелек кебек өлкәләрдәге проектлар турында сөйләде.

## Татарстан мөфтиятенең «Хәләл» стандарты комитеты Фарсы култыгы илләрендә аккредитация алды

Диния нәзарәтенең «Хәләл» буенча стандарты комитеты 2024 елның ноябрендә Фарсы култыгы илләрендә, шул исәптән Согуд Гарәбстанында, Күвәйт, Бәһрәйн, Катар, Гоман һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә аккредитация алды. Аккредитация Фарсы култыгы илләре стандартларына гына түгел, SMIIC таләпләренә дә (Төркиядә Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы каршындагы Стандартлаштыру һәм метрология институты стандартлары) туры килүне раслау процессын җиңеләйтәчәк.

## Кукмара районы Мәчкәрә авылының тарихи мәчете манарасына ярымай куелды

Җөмәдәл-ахыр аеның 11 нче көнендә (12 декабрь) Кукмара районының Мәчкәрә авылындагы тарихи Җәмигъ мәчетендә торгызылган манарага ярымай куелды. Әлеге мәчет 1791–1793 елларда сәүдәгәр Габдулла Үтәмешев

тарафыннан төзелгән һәм төбәк дәрәҗәсендә әһәмиятле мәдәни мирас объекты санала. 2022 елда мәчеттә киң колачлы төзекләндерү эшләре башланды. Хәзер биредә мөстәкыйль туристик маршрут төзелә.

## «Апанай» мәчетенең Коръән буенча онлайн-курсларын тәмамлаган 400 укучыга сертификатлар тапшырылды

Җөмәдәл-ахыр аеның 15 нче көнендә (16 декабрь) Казанда «Апанай» мәчетенең Коръән буенча онлайн-курсларын татар телендә тәмамлаучыларга сертификатлар тапшыру тантанасы узды. Сертификатларны, Татарстаннан тыш, Россиянең төрле төбәкләреннән, шул исәптән, Башкортстан Республикасыннан, Ульяновск өлкәсеннән, Урал һәм Себер төбәкләреннән килгән 400 мөслимә алды.

## Казанда имам-вәгазьчеләр җыены узды

Декабрьдә Татарстан мөхтәсибәтләрендә халыкны ислам диненә чакыру белән шөгыльләнүче имам-вәгазьчеләр җыены оештырылды. Әлеге чарада Татарстанның төрле почмакларыннан 35 яшькә кадәрге актив имамнар катнашты.

## Мөфти мөселман волонтерлары белән очрашты

Җөмәдәл-ахыр аеның 16 нчы көнендә (17 декабрь) Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин мөселман волонтерлары белән очрашты. Казанның «Галиев» мәчетендә узган чарада Диния нәзарәтенең социаль проектларын һәм үз башлангычларын гамәлгә ашыручы активистлар катнашты. Камил хәзрәт волонтерларга үзенең нәсыйхәтләрен җиткерде, төрле социаль чараларны тормышка ашыруга керткән зур хезмәте өчен тирән рәхмәтен белдерде.

## Казанның «Наташа» хосписында намаз уку бүлмәсе ачылды

Җөмәдәл-ахыр аеның 18 нче көнендә (19 декабрь) Казан шәһәренең «Наташа» хосписында рәсми рәвештә намаз уку бүлмәсе ачылды, Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә беренче җәмәгать намазы укылды. Камил хәзрәт гыйбадәт кылу бүлмәсен булдыру өчен тырышлык куючыларга – хоспис җитәкчелегенә һәм хезмәткәрләргә, хәйриячеләргә – ихлас рәхмәтен белдерде. Яңа мосалләгә дини әдәбият бүләк итте.

Намаз уку бүлмәсенең гомуми мәйданы – 80 квадрат метр һәм ул якынча 50 кешене сыйдыра. Намаз уку бүлмәсе белән «Габдерәхим Утыз Имәни исемендәге Ал Таң» мәчете имамы Ирек хәзрәт Җиһаншин һәм имам Рәдиф хәзрәт Гайнетдинов җитәкчелек итә. Алар биредә атнасына ике тапкыр хоспистагы авырулар белән очрашулар үткәрә, Коръән укый, дога кыла.

## «Иман» мәдәният-мәгърифәт үзәге 2024 елга йомгак ясады

Җөмәдәл-ахыр аеның 18 нче көнендә (19 декабрь) Казанның «Апанай» мәчетендә «Иман» мәдәният-мәгърифәт үзәге эшчәнлеге нәтиҗәләренә багышланган чара узды. Анда бигрәк тә белем бирү программаларына, мәгърифәтчелек башлангычларына, нәшрият эшенә һәм рухи традицияләрне пропагандалауга аерым игътибар бирелде.

## Татарстанда Мөселман яшьләре активы слеты узды

2024 елның декабрь уртасында Татарстанда бөтен Россиядән 42 егет һәм кызны җыйган Мөселман яшьләре активы слеты узды. Анда Мәскәү, Екатеринбург, Йошкар-Ола, Оренбург, Саратов, Уфа, Пенза шәһәрләре һәм Пенза өлкәсе, Удмуртия Республикасы, Казан, Иннополис, Әлмәт, Яр Чал-

лы, Арча, Татарстанның Питрәч районыннан 18 яшьтән 35 яшькә кадәрге егетләр һәм кызлар килде. Слет Россия төбәкләрендә актив эшләүче яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирүгә һәм Ватанга мәхәббәт тәрбияләүгә юнәлдерелгән иде.

## Апас мөхтәсибәтендә капиталь төзекләндерүдән соң мәчет ачылды

Җөмәдәл-ахыр аеның 19 нчы көнендә (20 декабрь) Апас районы Идрәс-Тинки авылында капиталь төзекләндерүдән соң тантаналы рәвештә мәчет ачылды. Биредә иганәчеләр һәм халык ярдәме белән идәннәр алмаштырылды һәм җылытылды, намаз уку залы, уку сыйныфы һәм тәһарәтханә җиһазландырылды, мәчет ишегалдында балалар мәйданчыгы ясалды.

## Балтач мөхтәсибәтендә ел йомгаклары ясалды һәм Кариле мәчетенең 30 еллыгы билгеләп үтелде

Җөмәдәл-ахыр аеның 20 нче көнендә (21 декабрь) Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Татарстанның Балтач районына эшлекле сәфәр кылды. Балтач мөхтәсибәтенең Кариле авылы мәчетендә район имамнары җыелышы узды, мөхтәсибәтнең 2024 елдагы эшчәнлегенә йомгак ясалды һәм 2025 елга планнар билгеләнде. Кариле мәчетенең 30 еллыгы билгеләп үтелде. Чара район имам-мөхтәсибе һәм республиканың баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев җитәкчелегендә узды. Камил хәзрәт мөхтәсибәтнең мәгариф, дәгъват, рухи-әхлакый кыйммәтләрне пропагандалау һәм социаль хезмәт өлкәсендәге уңышлы эш нәтиҗәләре өчен рәхмәт белдерде.

## Нәзарәт делегациясе махсус хәрби операциядә катнашучыларга унынчы гуманитар йөкне илтеп тапшырды

Нәзарәт делегациясе махсус хәрби операция зонасына унынчы тапкыр сәфәр кылды. Нәзарәт хезмәткәрләре Луганск юнәлешендәге шефлыкка алынган хәрби бүлекчә солдатларына азык-төлек, аптечкалар, пластырь тибындагы бәйләвечләр, 200/18 терминаторы, рацияләр, автоном җылыткычлар, дымлы салфеткалар, окопта куллану өчен горелкалар, генераторлар илтеп тапшырды. Йөк, солдатларның теләк-тәкъдимнәрен исәп алып, Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды тарафыннан җыелган акчага тупланды.

## Мөфтияттә рухи кыйммәтләрне һәм гаилә традицияләрен саклау мәсьәләләренә багышланган түгәрәк өстәл узды

Җөмәдәл-ахыр аеның 22 нче көнендә (23 декабрь) Нәзарәттә, ТР Иҗтимагый палатасының Россия традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен саклау һәм ныгыту комиссиясе башлангычы белән, «Татарстанның дини һәм иҗтимагый оешмалары: рухи кыйммәтләрне һәм гаилә традицияләрен саклауда социаль технологияләр» дип исемләнгән түгәрәк өстәл узды. Мөфтинең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов, түгәрәк өстәлдә катнашучыларны Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин исеменнән сәламләп, рухият һәм гаилә кыйммәтләрен саклауның һәрвакыт мөселман дин әһелләре игътибар үзәгендә булуын билгеләп үтте.

## Түбән Кама мөхтәсибәтендә төзекләндерүдән соң мәчет ачылды

Җөмәдәл-ахыр аеның 25 нче көнендә (26 декабрь) Түбән Кама мөхтәсибәтенең Колмакчы авылында капиталь төзекләндерүдән соң мәчет ачылды. Әлеге авылда туып үскән Марат Гобәев дуслары һәм җирле халык белән берлектә мәчеттә намаз уку залын, имам бүлмәсен, уку сыйныфын һәм тәһарәтханәне төзекләндергән һәм җиһазлаган.

Хәзерге вакытта Түбән Кама мөхтәсибәтендә 24 мәчет эшли.

## Бөтенроссия «Сәфәр» мөселман форумында бөтен Россиядән 50 мөселман катнашты

Гыйнвар башында Татарстанда Нәзарәтнең БИА теләктәшлегендәге дүрт көнлек «Сәфәр» мөселман форумы узды: ул бөтен Россиядән 50 мөселманны җыйды. Әлеге проектта Мәскәү, Оренбург, Уфадан һәм Самарадан, Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнарыннан 30 яшьтән алып 40 яшькә кадәрге мөселманнар, шул исәптән гаиләле парлар катнашты. «Сәфәр» форумы өммәтне берләштерү, белем алу һәм иманны ныгыту, хәләл ял итү һәм иҗат белән шөгыльләнү мәйданчыгы булып тора.

## Рамазан алдыннан Коръән укырга өйрәнү курслары узды

Рамазан ае башланыр алдыннан, Казанда һәм шәһәр яны мәчетләрендә Коръән укырга өйрәнү курслары оештырылды. Дәресләр Татарстан мөфтияте һәм КИУ каршындагы Госман бине Гаффан исемендәге Коръән хафизларны әзерләү үзәге тарафыннан әзерләнгән махсус программа нигезендә үткәрелде.

## Арча мөхтәсибәтендә Мөфти катнашында Коръәни Кәримне өйрәнү үзәге ачылды

Раҗәб аеның 11 нче көнендә (11 гыйнвар) Арча мөхтәсибәтендә Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашында районның Үзәк мәчете каршында урнашкан Коръәни Кәримне өйрәнү үзәге тантаналы рәвештә ачылды.

Хәзерге вакытта Арча мөхтәсибәтендә 94 мәчет эшли, аларда 138 мөгаллим ислам дине нигезләре буенча белем бирә. Ә Габдулла Тукай исемендәге Мәгърифәт үзәгендә 17 мөгаллим 150 шәкерт өчен дәресләр алып бара.

Гыйнвар аенда Татарстанда балалар һәм яшүсмерләр арасында Коръән уку бәйгеләре узды

Гыйнвар аенда Татарстанда, аерым алганда, Кукмара, Яр Чаллы һәм Бөгелмә мөхтәсибәтләрендә, Казанда балалар һәм яшүсмерләр арасында Коръән уку бәйгеләре узды.

## Әлмәттә I Республикакүләм Ислам китабы фестивале үтте

Раҗәб аеның 12 нче көнендә (12 гыйнвар) Әлмәт шәһәренең Җәмигъ мәчетендә I Республикакүләм Ислам китабы фестивале узды. Мондый чара тәүге тапкыр Әлмәт мөхтәсибәте тарафыннан Татарстан Республикасы Язучылар берлеге белән берлектә оештырылды.

Фестивальдә Татарстанның һәм Россиянең алты нәшрияты катнашты. Иң зур экспозицияләрнең берсе Нәзарәтнең «Хозур» нәшрият йортыныкы иде. Ул соңгы 11 ел эчендә татар, рус һәм гарәп телләрендә нәшер ителгән дини, фәнни-популяр һәм балалар өчен басмаларны тәкъдим итте.

## Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Татарстан Рәисенең Россия мөселманнары Дини җыены башлыгы Әлбир Крганов белән очрашуында катнашты

Раҗәб аеның 14 нче көнендә (14 гыйнвар) Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов Россия мөселманнары Дини җыены башлыгы, Мәскәү шәһәре мөселманнары Диния нәзарәте һәм «Мәскәү мөфтияте» Үзәк төбәге рәисе Әлбир хәзрәт Крганов белән очрашты. Әлеге очрашуда шулай ук Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашты. Әңгәмә барышында милләтара һәм динара татулыкны ныгыту, ислам мәгарифен үстерү өлкәсендәге багланышлар хакында фикер алыштылар.

## «Мәрҗани» мәчетендә Нәзарәтнең Пленум утырышы узды

Раҗәб аеның 15 нче көнендә (15 гыйнвар) Казанның «Мәрҗани» мәчетендә ТР мөселманнары Диния нәзарәте Пленумы утырышы узды. Җыелышта Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, аның урынбасарлары, Баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыев, Татарстанның барлык имам-мөхтәсибләре һәм казыйлары, ТР мөселманнары Диния нәзарәте Президиумы әгъзалары, Голәмалар шурасы әгъзалары һәм мөселман мәгариф оешмалары җитәкчеләре катнашты. Пленум утырышы Диния Нәзарәтенең чираттагы Корылтаена һәм Татарстан Мөфтиен һәм Баш казыен сайлауларга багышланды.

## Казанда дин әһелләре олуг галим Шиһабетдин Мәрҗанине искә алды

Раҗәб аеның 16 нчы көнендә (16 гыйнвар) күренекле дин галиме, мәгърифәтче һәм тарихчы Шиһабетдин Мәрҗанинең (1818-1889) тууына

207 ел тулу уңаеннан, татар-мөселман җәмәгатьчелеге олуг галимне искә алды. Дин әһелләре, татар зыялылары, фән һәм җәмәгать эшлеклеләре, шәкертләр һәм журналистлар Татарстан Мөфтиенең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасары, «Мәрҗани» мәчете имам-хатыйбы Равил хәзрәт Зөфәров, Мөфтинең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов белән бергәләп Казан шәһәренең Яңа бистә зиратында галим рухына дога кылды.

## Мөфти Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә шәкертләре белән очрашты

Раҗәб аеның 16 нчы көнендә (16 гыйнвар) Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан мәдрәсәсе шәкертләре белән очрашты. Анда Россиянең 20 дән артык төбәгеннән укырга килгән 100 дән артык шәкерт катнашты.

Татарстан мөселманнары башлыгы Исламда мәзһәбләрнең әһәмияте һәм динне үстерү юллары, дин галимнәренең мөһим казанышлары турында сөйләде. Коръән, Сөннәт, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм ислам галимнәре тормышыннан мисаллар китереп, шәкертләргә үзенең үгет-нәсыйхәтләрен җиткерде.

## Яшел Үзәндә «Җәмигъ» мәчете янәшәсендә чишмә ачылды

Раҗәб аеның 18 нче көнендә (18 гыйнвар) Яшел Үзән шәһәренең «Җәмигъ» мәчете янында тантаналы рәвештә чишмә ачылды. Анда Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашып, әлеге изге эшне башкаручыларга рәхмәт белдерде, җан ияләренә су эчертүнең саваплы гамәллләрдән булуы, садака җариянең мөһимлеге хакында сөйләде.

Танылган меценат Ильяс Гыймадов тырышлыгы белән булдырылган чишмә бөтен мәхәллә һәм шәһәр халкын эчә торган су белән тәэмин итә.

## Мөфти җитәкчелегендәге Нәзарәт делегациясе махсус хәрби операциягә кайнар нокталарга сугышчылар янына барып кайтты

Гыйнвар аенда Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, аның беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов һәм Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәге казые Марат хәзрәт Мәрданшин, шулай ук Нәзарәтнең башка хезмәткәрләре махсус хәрби операция зонасына чираттагы эшлекле сәфәрен кылды. Бу юлы Нәзарәт җитәкчелеге алгы сызыкта ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең полк имамы, Татарстан Мөфтие ярдәмчесе Мөхәммәд хәзрәт Хәйрулаев хезмәт иткән «Батыр» батальоны сугышчылары, Луганск госпитальләрендә дәваланучы солдатлар янына барды. Полк имамы Мөхәммәд хәзрәт командование ярдәме белән төзегән «мәчет» – блиндаж мосалләне ачуда катнашты, анда сугышчылар белән беренче җәмәгать намазы укыдылар. Хәрбиләр белән очрашу барышында Камил хәзрәт командованиегә һәм мәчет төзелешендә катнашкан һәркемгә, мөселман сугышчыларына яхшы мөнәсәбәт өчен ихластан рәхмәт белдерде.

Бер уңайдан сугышчылар Нәзарәт җитәкчелегенә мәчет өчен «Starlink» иярчен элемтә аппараты алырга ярдәм итүне сорап мөрәҗәгать итте. Бу мәсьәлә шунда ук хәл ителде – хәзрәтләр батальонга җиһазлар сатып алу өчен акча калдырды. Хәзер «Батыр» батальонының «Нургали» мәчете коммуникацияләр белән тәэмин ителәчәк. Димәк, монда мәхәллә солдатлары өчен дистанцион дини укулар оештырырга мөмкин булачак.

Моннан тыш, хәзрәтләр сәфәр барышында алгы сызыкта башка батальонда төзелеп килүче мәчеткә бүләкләр –намазлыклар, ковролиннар, китаплар калдырды, шулай ук башка урындагы батальонга һәм Луганскидагы госпитальгә гуманитар йөк тапшырды.

## Нәзарәттә Рамазан алдыннан оештырылган «Ислам. Беренче адымнар» мәктәбен 200 дән артык кеше тәмамлады

Нәзарәттә «Ислам. Беренче адымнар» мәктәбенең 15 нче сезоны тәмамланды. Курслар Рамазан ае алдыннан, исламда беренче адымнарын ясаучы кардәшләребез, изге ай төгәлләнгәнче, намаз укырга өйрәнә алсын өчен махсус оештырылды. Кыска вакытлы курсларда белем алучылар намаз уку тәртипләрен һәм Ислам нигезләрен үзләштерде. Дәресләрне Татарстан мөфтиятенең волонтер яшьләр хәрәкәте активы алып барды.

«Ислам. Беренче адымнар» проекты Татарстан мөфтияте тарафыннан 2018 елда тормышка ашырыла башлады. Унбиш сезон дәвамында әлеге курсларда 1700 дән артык кеше белем алды һәм намазга басты.

## «Гаилә» мәчетендә махсус хәрби операциядәге сугышчылар өчен 2000 пар йон оекбаш бәйләнде

Казанның «Гаилә» мәчетендә махсус хәрби операциядәге сугышчыларга ярдәм йөзеннән оештырылган «Гаилә җылысы» дип аталган акция тәмамланды. Акция вакытында 2000 гә якын пар йон оекбаш бәйләнде. Мәчет имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин аларны сугышчылар өчен Татарстан Мөфтиенең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасары, «Мәрҗани» мәчете имам-хатыйбы Равил хәзрәт Зөфәровка тапшырды.

## Нәзарәтнең «Каһарман» акциясе кысаларында махсус хәрби операция сугышчыларына тәгәрмәчле мәчет өчен ике автомобиль сатып алынды

Гыйнвар ае ахырында Диния нәзарәте автомобиль сатып алу һәм аны, тәгәрмәчле мәчет ясап җиһазлау өчен, акча җыюны игълан итте. «Каһарман»

хәйрия акциясе кысаларында берничә көн эчендә ике УАЗ автомобиле һәм алардан күчмә мәчет ясау өчен җиһазлар сатып алуга акча җыелды. Акциягә Татарстанның барлык почмакларыннан һәм аннан читтә яшәүче мөселманнар да кушылды.

Күчмә мәчет хәрби-кыр шартларында махсус хәрби операциядәге мөселман сугышчылары өчен кирәк. Тәгәрмәчле мәчет махсус хәрби операциядә солдатларга намаз укуда һәм дога кылуда уңайлыклар тудырачак, шулай ук тиз арада азык-төлек һәм медикаментлар белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтәчәк.

## «Мәрҗани» мәчетендә махсус хәрбия операция сугышчыларына ярдәм итүче волонтерлар белән очрашу узды

Казанның «Мәрҗани» мәчетендә Татарстан Мөфтиенең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасары, имам-хатыйб Равил хәзрәт Зөфәров махсус хәрби операция сугышчыларына ярдәм итүче волонтерлар белән очрашты.

Мәхәллә волонтерлары төркеме Равил хәзрәткә махсус хәрбия операция башланганнан бирле алып барган эшчәнлеге турында сөйләде: алар маскировка ятьмәләре үрәләр, ир-атлар өчен – маскировка халатлары, госпитальләр өчен махсус күлмәкләр, эчке киемнәр тегәләр, оекбашлар бәйлиләр, медицина валиклары ясыйлар. Равил хәзрәт аларга хезмәте өчен рәхмәт әйтте һәм шулай ук мәчеттә гуманитар ярдәмнең ничек җыелуы һәм алга таба алгы сызыктагы сугышчыларның кулларына турыдан-туры илтеп тапшырылуы белән таныштырды.

## Казанда Халыкара хиҗаб көненә багышланган чара узды

Шәгъбан аеның 3 нче көнендә (2 февраль) Казанда Халыкара хиҗаб көненә багышланган чара узды. Аны ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм Татарстан мөслимәләре берлеге уздырды. Әлеге чарада катнашучыларны Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, адвокат һәм юрист Руслан Нагиев, Татарстан Мөслимәләр берлеге җитәкчесе Наилә Җиһаншина һ.б. сәламләде.

Камил хәзрәт, тантаналы чарада катнашучыларны сәламләп, Коръәндә «хиҗаб» термины юк дигән дөрес булмаган фикерне кире какты. Ул Аллаһы Тәгаләнең Коръәндә ике аятьтә мөслимәләргә яулык бәйләргә кушуын, димәк, бу – безнең хокукыбыз гына түгел, ә Раббыбызның боерыгы булып торуын ассызыклап әйтте.

Адвокат һәм юрист Руслан Нагиев яулык бәйләүгә кагылышлы кайбер мәсьәләләрне юридик яктан аңлатты. РФ Конституциясе һәм федераль законнарның дин тотучыларның хокукларын яклавын белдерде. Яулык бәйләргә һәм ата-бабалардан килгән гореф-гадәтләрне сакларга теләүчеләргә шушы хокукый-норматив актларга таянырга киңәш бирде.

## Нәзарәт, Рамазан аена биналарны бизәп куярга чакырып, «Нурлы Рамазан» бәйгесен игълан итте

Татарстан мөфтияте изге Рамазан ае уңаеннан җәмәгать урыннарын бизәү буенча өченче тапкыр «Нурлы Рамазан» бәйгесен игълан итте. Республикада изге ай мохитен тудыру һәм бәйгедә катнашу өчен иҗтимагый, коммерцияле, шәхси, дәүләт, дини оешмалар, физик затлар чакырыла. Моның өчен алар халыкка хезмәт күрсәтү урыннарында – кафе һәм рестораннар, кибетләр һәм сәүдә үзәкләре, салоннар, мәчетләр, уку йортлары кебек биналарга керү урыннарын бәйрәмчә итеп бизәргә тиеш. Иң матур бизәлешкә «ДУМ РТ Хаҗ» рәсми операторыннан хаҗга юллама бүләк ителәчәк.

Бәйгенең калган җиңүчеләрен шулай ук мактау кәгазьләре һәм истәлекле бүләкләр көтә.

2023-2024 елларда бәйгедә барлыгы 79 объект катнашты.

## Нәзарәт МХОда катнашучы сугышчыларга 12 нче гуманитар йөкне җибәрде

Бу юлы Татарстан мөселманнары исеменнән «Тимер» һәм «Батыр» батальоннары, 430 нчы полкы сугышчыларына Арча мөхтәсибәте мөселманнары сатып алган яралы солдатларны эвакуацияләү һәм госпитальгә илтү өчен «Урал» мотоциклы һәм УАЗ 452 автомобиле; блиндажлар өчен җылыткычлар, блиндаж һәм мунча өчен мичләр, маскировка челтәрләре, такталар, автомобильләр өчен тәгәрмәчләр, аптечкалар, дога җыентыклары тапшырды. Азык-төлектән тушенка, ярмалар, шешәләрдә 10 т су һ.б. илтелде. Луганск һәм Антрацит шәһәрләрендәге госпитальләргә медикаментлар, зур подгузниклар, яралылар өчен җөйсез киемнәр, бинтлар, перекись, култык таяклары, юеш салфеткалар һәм азык-төлек, «Хәләл» коры ризык җыелмасы, шулай ук окоп шәмнәре тапшырылды.

## Ак Барс Банкы Цифрлы финанс активлар базасында «сукүк модараба» яңа ислам продуктын эшләтеп җибәрде

Ак Барс Банкы Цифрлы финанс активлары базасында «сукүк модараба» дигән яңа ислам продуктын эшләтеп җибәрде. Бу продукт ышанычлы идарә килешүенә нигезләнгән. Оешмалар сукүк модараба ярдәмендә үз проектларын гамәлгә ашыру өчен инвестицияләр җәлеп итеп, ә инвесторлар ислам хокукы нормалары нигезендә табыш ала алачак.

Финанс продукты Ак Барс Банкының ислам банкингы үзәге тарафыннан эшләнгән һәм Цифрлы финанс активлары (ЦФА) базасында гамәлгә

кертелгән. Шәригать таләпләренә тулысынча туры килгән продукт Татарстан Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы тарафыннан хупланды. Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Ак Барс Банкының Инвестицион бизнес дирекциясе директоры Айдар Мөхәммәтҗановка Цифрлы финанс активлар базасында «сукүк модараба» продуктының шәригать кануннарына туры килүе турында сертификат тапшырды.

## Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды Хиҗаб көненә багышланган чара үткәрде

Шәгъбан аеның 5 нче көнендә (4 февраль) ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды Хиҗаб көненә багышланган чара үткәрде. Тантанада хатын-кызлар, яшүсмерләр, шул исәптән үзенчәлекле балалар тәрбияләүче һәм авыр тормыш хәлендәге күпбалалы гаиләләр катнашты. Кунакларга хиҗабның мөһимлеге турында вәгазьләр сөйләделәр, балалар өчен мастер-класс оештырдылар, «Түбәтәй» кафесыннан өчпочмаклар белән сыйладылар, «Әмирә» кибетеннән һәм башка хәйриячеләрдән истәлекле бүләкләр тапшырдылар.

## Мөфти Камил хәзрәт Татарстан районнарында халык белән очрашты

Февраль аенда Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Татарстан халкы белән күчмә очрашулар уздырды. Аерым алганда, ул Ютазы, Бөгелмә, Питрәч, Түбән Кама, Мөслим һәм Аксубай районнары мөселманнары, Татарстанның көньяк-көнчыгыш казыят имамнары, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларының гаиләләре һәм якыннарын югалтучылар белән очрашты.

Мөхтәсибәтләргә чыгу – Мөфтинең республиканың ерак районшәһәрләрендәге халыкны кабул итү белән бәйле, чөнки Нәзарәткә Камил хәзрәт белән очрашуга нигездә Казан халкы гына килә ала. Мөселманнар

белән очрашуларда Камил хәзрәт Диния нәзарәтенең эшчәнлеге, шул исәптән мәгариф, мәгърифәтчелек, нәшрият, фәнни эшчәнлек өлкәләрендәге хезмәте һәм казанышлары турында сөйләде. Ул Диния нәзарәте һәм аның дини оешмалары алдында торган өстенлекле юнәлешләрне билгеләде, рухи кыйммәтләр хакында вәгазь укыды, нәсыйхәтләрен җиткерде һәм сорауларга җавап бирде.

Камил хәзрәт очрашулар вакытында һәлак булган солдатларның якыннарының кайгысын уртаклашты, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең сугышчыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү юнәлешендәге актив эшчәнлеге турында сөйләде. Татарстан мөфтияте делегацияләренең сугыш хәрәкәтләре зонасына даими рәвештә баруын, сугышчыларга барлыгы 12 гуманитар йөк тапшырылуын әйтте. Моннан тыш, республика мөхтәсибәтләрендә һәлак булган солдатларның гаиләләре белән очрашулар үткәрелә, бу алар өчен зур рухи ярдәм булып тора.

## Яр Чаллы мөхтәсибәтендә махсус хәрби операция зонасына сугышчылар өчен күчтәнәчләр җибәрделәр һәм МХОда якыннарын югалткан гаиләләр белән очраштылар

Яр Чаллы мөхтәсибәте «Тимер» батальоны солдатлары үтенече буенча махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен гуманитар ярдәм җибәрде. Яр Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин җитәкчелегендә мәхәллә халкы һәм битараф булмаган кешеләр сугышчыларга җибәрү өчен 360 банка хәләл тушенка, җылы киемнәр, оекбашлар, юрганнар, пледлар, ике келәм, дога китаплары, сохари, тәм-томнар һәм бер чиләк бал туплады.

Моннан тыш, 8 февральдә Яр Чаллы шәһәренең «Нур-Ихлас» мәчетендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләре һәм якыннарын югалтучылар белән очрашу һәм Коръән ашы оештырылды. Хәзрәтләр Коръән укып дога кылды, нәсыйхәтләрен җиткерде.

## Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәдә татар азаны дәресләренә нәтиҗәләр ясалды

Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәдә татар азаны дәресләренә нәтиҗәләр ясалды: ул азан бәйгесе белән тәмамланды. «Татар азаны мәктәбе» проекты мәдрәсәдә ике ай дәвамында барды. Татар мәкаме белән азан әйтү буенча дәресләр мәдрәсәнең көндезге уку бүлеге шәкертләре өчен офлайн һәм дистанцион форматта үткәрелде. Практикумнарда тәҗвид кагыйдәләрен үзләштерү дәрәҗәсе тикшерелде, дөрес итеп азан әйтү буенча һәр шәкерт белән аерым дәресләр алып барылды.

## Мөфти «Ирек» мәчетендә җомга намазы үткәрде

Шәгъбан аеның 8 нче көнендә (7 февраль) Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Казанның «Ирек» мәчетендә җомга вәгазен укыды һәм җомга намазын үткәрде. Ул үзенең вәгазендә игътибарны шәгъбан аеның фазыйләтләренә һәм Бәраәт кичәсенең мөһимлегенә юнәлтте.

## Ачык телевизион татар вәгазе бәйгесе башланды

«Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе һәм Нәзарәт Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 80 ел тулу, Россиядә һәм Татарстанда – Ватанны саклаучылар елы һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә Каһарманнар елы кысаларында Ватанга мәхәббәт темасына ачык телевизион татар вәгазе бәйгесен игълан итте. Конкурсның максаты – вәгазь жанрын популярлаштыру һәм татар телендә иң оста вәгазьчеләрне ачыклау; вәгазьләрне халыкка үтемле итеп сөйләү үрнәген булдыру; халыкта Ватанга мәхәббәт тәрбияләү.

Иң яхшы вәгазьләр атна саен Татарстан дәүләт телерадиокомпаниясенең «Хәерле көн, Татарстан!» һәм «Яңалыклар» тапшыруларының җомга чыгарылышында күрсәтелә.

## Нәзарәт 2025 елда Рамазан өчен фитр садакасы, фидия һәм нисаб күләмнәрен билгеләде

28 февральдә Рамазан ае башлану сәбәпле, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы һәм Казыйлар шурасы фитр садакасы, фидия һәм нисаб күләме буенча карарлар кабул итте.

Фитр садакасын түләү өчен нисаб – 57 мең сум (көмеш буенча), зәкят чыгару өчен нисаб 720 мең сум (алтын буенча) күләмендә билгеләнде. Фитр садакасының минималь күләме – 200 сум, ә зәкят чыгарырлык байлыгы булган кешеләр өчен – 1100 сум. Моннан тыш, сәламәтлеге аркасында ураза тота алмаучылар һәм аны башка вакытта да, каза кылып үти алмаучыларга тотылмый калган һәр көн өчен 400 сум күләмендә фидия билгеләнде.

## Гыйнвар-февраль айларында Яр Чаллы, Лениногорск, Мөслим һәм Алабуга мөхтәсибәтләрендә спорт чаралары узды

Гыйнвар-февраль айларында Яр Чаллы, Лениногорск, Мөслим һәм Алабуга мөхтәсибәтләрендә спорт чаралары узды. Аерым алганда, Яр Чаллы һәм Лениногорскида чаңгы ярышлары, ә Мөслимдә – мөселман яшьләре арасында спартакиада, Алабугада волейбол турниры үтте.

## Мөфти Рәис белән бергә гомрә кылдылар

Февраль башында Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Рәис Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы делегациясе составында Согуд Гарәбстаны Корольлегендә эш сәфәрендә булды. Алар башта бергәләп гомрә йолаларын үтәде, ә көндез Ислам дөньясы мәдәният министрларының XIII конференциясендә катнашты. Моннан тыш, көн дәвамында эш сәфәре кысаларында очрашулар һәм эшлекле сөйләшүләр дә булды.